ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№8 (332) – АВГУСТ 2019

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан
нәшер ителә

Һәркем өчен программа бар

Харис Якупов: гадилектә – галилек

Бөек үзгәрешләр буыны

WORLDSKILLS: ЯШЬ ПРОФЕССИОНАЛЛАР КАЗАННЫ СӘЛАМЛИ!

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская,
Алёна Кутыркина, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Мәршидә Кыямова, Шаһинур Мостафин,
Луиза Шарова, Әнвәр Шәрипов
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта Казанда WorldSkills 2019 дөнья чемпионатында катнашучы. Алёна Кутыркина фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Татар телендә тираж: 1150 данә,
рус телендә: 2350 данә

Гомуми тираж: 3500 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № О-2268
Басарга кул куелды: 26.08.2019
Басмадан чыкты: 29.08.2019

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

2019 ның ГАҖӘЕП ҖӘЕ

Җәй елына дүрт мәртәбә эзлекле рәвештә алышынып торган климатта яшәүче кешеләрнең күңелен дә даими рәвештә кырып торырга ияләште бугай инде. Көтәсең-көтәсең аны, ә ул... Август та булмасамы... Август дөрес булмаган җәйгә төзәтмәләр кертү вазыйфасын үз өстенә алды, ахрысы.

Шулай итеп, ул безне барлык юнәлешләр буенча да утка тотты: температура, дисеңме, вакыйгалар, дисеңме. Җирле масштабтагы гына түгел, ә дөньякүләм колачтагы чараларга старт биреп тә – бер WorldSkills гына ни тора! 2019 елның августы «Мин күкне сайлыйм!» бәйрәме белән дә кыздырды. 2019 елның Алма спасы Красновидово алмалары белән авыздан сулар китерде. Һава шартлары гөмбә белән аланнарны һәм табыннарны ямьләде – монысы да зур куаныч булды.

Алда әле безне тагын бер зур бәйрәм көтә – Республика көне. Ул җәйне менә дигән күтәренке рухта һәм шаулы салют белән тәмамларга мөмкинлек бирәчәк!

2019 елның җәе, ризасыздыр, җәй күрсәткечләре буенча минус тамгасы белән булса да, иң шәбе һәм гаҗәеп булды, дия алабыз.

СЕЗНЕҢ ҖЫЛЫГА ТИЕНГӘН РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **930 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7076** – татар телендә
Индекс **П7077** – рус телендә

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ

Ф.Х. Якупов, «Деревенский кентавр».

АВГУСТ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

8. Каспий: ресурслар һәм мөмкинлекләр. Төрекмәнбашыда үткән икътисадый форум нәрсәне күрсәтте

10. Күчмә медицина ярдәме. Нинди поликлиникалар иң ерак авылларга барып җитәчәк

12. Бер тәрәзә нуры. Тормыш сыйфатын яхшыртучы программалар

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: **www.protatarstan.ru**

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

24. Яңа традицияләр. Һәр заманның үз Печән базары

28. Җиңү өчен бирелү. Татарстанда дзюдо фәлсәфәсен ничек өйрәнәләр

30. Редакция кухнясы. Мәликә ханым Гыйльметдиновадан – долма

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

36. Кече ватан патриотлары. Рәссам Харис Якупов

42. Каһарманнарыбыз. Гаделлек тантанасы

46. Саксофон һәм керосинка өчен соло. 50 нче еллар Казаны

54. Гомерлек мөһер. Тоткынлыктан кайткан фронтовиклар язмышы турында

60. Беренчеләр чоры. «Икенче Баку» ничек төзелә

70. Бөек күченеш. Шәһәрләр һәм авыллар ничек су төбенә киткән

74. Тарихи сәхифә. Утыз Имәни: милләтнең рух сагында

84. Татар авыллары. Тарихлы Олы Кариле

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

16.08

Виталий Мутко, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары, – Казандагы «Весна» торак комплексын караганда:

– Безнең бурыч – нәкъ менә комплекслы микрорайоннар төзү, бу анда тиешле мохит: балалар бакчасы, мәктәп, уңайлы территория, төзек, матур ишегаллары булсын өчен кирәк. Без «йокы районнары» төшенчәсеннән китәргә тиеш. Теләсә нинди яшьтәге кешеләр өчен дә кулай шартлар тудырылырга тиеш. Бу микрорайонда боларның барысы да игътибарга алынган.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

10.08



Марат Әхмәтов, ТР Премьер-министры урынбасары – ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, – Хөкүмәт йортындагы республика киңәшмәсендә:

– Бөртеклеләргә бәяләр безнең өчен, ихтимал, 2018 елга караганда да кызыксындырырлык булыр. Ил буенча бөртеклеләрнең күчә торган калдыклары, узган елгы егерме миллион тонна янында, ун миллион тонна дәрәҗәсендә бәяләнә. Димәк, мондый күләмнәр базарга басым ясамаячак.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

16.08

Татьяна Ларионова, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, – «Татмедиа» АҖ генераль директоры Андрей Кузьминга биргән интервьюсында:

– Федераль законга бик тә үзгәрешләр кертәсе, дәүләт телләрен өйрәнү хокукын һәм бурычларын урнаштырасы килә. Мондый хәлдә бер без генә түгел. Милли телле барлык республикалар да балаларның дәүләт телләрен белүләре турында борчыла.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Күчмә поликлиника **КАЙСЫ** авылдан старт алды

Кукмарада әбиләрне мобиль хезмәтләргә **НИЧЕК** өйрәтәләр

«Парклар һәм скверлар» программасы Мамадышны **НИЧЕК** үзгәртте

Чүп-чарны **НИЧЕК** җыярга

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

2019 елның
II яртыеллыгына
«Татарстан»
журналына язылу
дәвам итә

Реклама 16+

«Татарстан» журналына ТР буенча язылу индекслары:

П 2381 **татар телендә** 930 сум 00 тиен

П 2378 **рус телендә** 930 сум 00 тиен

«Татарстан» журналына РФ буенча язылу индекслары:

П 7076 **татар телендә**

П 7077 **рус телендә**



ПРЕЗИДЕНТ
МАРШРУТЛАРЫ БУЕНЧА

Татарстан Президентының эш графигы никадәр тыгыз булуын аңлар өчен, бернинди махсус хронометраж үткәрү таләп ителми. Аның сәфәрләре маршрутына күз салу да җитә. Республика, ил, дөнья буйлап туктаусыз йөри ул. Еш кына Рөстәм Миңнеханов иртән нинди дә булса Европа илендә потенциаль инвесторлар белән сөйләшүләр үткәрергә, көндез Россия башкаласындагы мөһим киңәшмәдә катнашырга өлгерә, берничә сәгатьтән соң исә Әлмәттә нефть тармагы үсеше перспективаларын тикшерә... Һәм көн саен диярлек шундый хәл күзәтелә.

Юлда үткән сәгатьләр һәм чакрымнар, мөһим очрашулар, җитди чыгышлар һәм җаваплы карарлар. ТР Президентының соңгы арадагы эш сәфәрләреннән «Татарстан» аеруча әһәмиятлеләрен сайлап алырга тырышты.

РОСТОВ-НА-ДОНУ.
ХЕЗМӘТТӘШЛЕКНЕҢ «ЮЛ КАРТА»СЫ

Фотолар ТР Президенты сайтыннан алынды (Марсель Бадыйкшин)

НӘРСӘ:

Ростов өлкәсенә эш сәфәре

КАЙДА:

Ростов-на-Дону, Азов

КАЙЧАН:

7 август

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:
– Күргәннәребез зур тәэсир калдырды. Бу «Платов» халыкара аэропорты да, без аның белән килүгә таныштык, яңа «Ростов Арена» стадионы да, транспорт чишелешләре дә. Аэропортка килгәндә, монда уйланылып эшләнгән һәм гамәлгә ашырылган нәрсәләр күп. Без аларны игътибарга алдык.

ТУЛЫРАК:

Ростов-на-Дону шәһәрендә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Ростов өлкәсе губернаторы Василий Голубев алты елга якын гамәлдә булган Татарстан Республикасы һәм Ростов өлкәсе арасында сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, социаль һәм мәдәни хезмәттәшлек турындагы килешүне гамәлгә ашыру чаралары Планын имзаладылар. План, аерым алганда, инвестицияле климатны яхшырту сферасында тәҗрибә алмашуны, кайбер конкрет проектларны тормышка ашыруны (шул исәптән дәүләти-шәхси партнерлык нигезендәгеләрен дә), инновацияләр сферасында, мәгариф һәм фәнни тикшеренүләр өлкәсендә хезмәттәшлекне киңәйтүне күз уңында тота.

Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, төбәкләр үзара файдалы хезмәттәшлек юнәлешләренә ия. Ростов өлкәсе һәм Татарстан Республикасы арасындагы товар әйләнешенең гомуми күләме 9 млрд сумнан артып китә, бу әле чик сан түгел.

Азовта Рөстәм Миңнеханов «Ай-Пласт» компаниясенең яңа җитештерүен эшләтеп җибәрү тантанасында катнашты. Компания сәүдә базарына Россия өчен уникаль булган кайбер продукцияләрне чыгара, бу пластик материаллардан ясалган транспорт әрҗәләре, сәнәгать төргәкләре, каты коммуналь калдыкларны җыю савытлары кебек продукцияләргә карый. Азовтагы «Ай-Пласт» җитештерүе – Россия Федерациясе территориясендә компаниянең сан буенча бишенче мәйданчыгы (заводлар шулай ук Түбән Камада, Владимир өлкәсендә эшли, тагын берсе Тубыл шәһәрендә ачылачак). Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, «Ай-Пласт» компаниясенең инвестицияле проекты Татарстан һәм Ростов өлкәсе арасындагы хезмәттәшлекне киңәйтүгә зур өлеш кертә. Ростов өлкәсе губернаторы Василий Голубев, үз чиратында, әлеге проектны гамәлгә ашыру турындагы килешүнең ел ярым элек имзалануы турында искә төшерде һәм инде бүген җитештерүнең эшләп китүе турында әйтте.

Ростов өлкәсенең Законнар чыгару залында Рөстәм Миңнехановның төбәктә яшәүче татар җәмәгатьчелеге белән очрашуы да узды. Татар телен саклап калу, татар башкаручыларының һәм ансамбльләренең Ростов өлкәсенә гастрольләрен оештыру мөмкинлекләре турындагы сораулар буенча фикер алышулар үтте. Көньяк Сабантуйны оештыру турында да сүз булды – икенче елга ул Ростов-на-Дону шәһәрендә уздырылачак.

Василий Голубев, Ростов өлкәсе губернаторы:
– Имзаланган документ – безнең хезмәттәшлекнең тәгаенләнгән «юл карта»сы.Татарстаннан өйрәнер нәрсәләребез шактый, шул исәптән бизнесны үстерү динамикасы, яңа мәгълүмати технологияләрне кертү буенча да. Безнең өчен яңа үсеш зоналарын, яңа икътисадый территорияләрне төзү, шәһәрләрнең тарихи үзәкләрен төзекләндерү турында законнарны эшләү тәҗрибәсе дә актуаль.

ТӨРЕКМӘНБАШЫ. КАСПИЙ КӨЧЕ

НӘРСӘ:

Беренче Каспий икътисадый форумы

КАЙДА:

Төрекмәнбашы, Төрекмәнстан

КАЙЧАН:

12 август

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:
– Каспий – куәтле логистика үзәге, аның аркылы биш Каспий буе иленә гаять зур куллану һәм сату күләмнәре уза. Мин логистика маршрутларын эшләүне беренче чираттагы мәсьәлә дип саныйм. Икенчесе, әлбәттә, – Иран, Казахстан һәм Үзбәкстан кебек илләрнең гаять зур базарлары. Ә алар аркылы – башка илләр дә.Бу Россиядә җитештерелгән продукцияне таныту да, әлеге зонада урнашкан илләрдән продукция, чимал кертү дә. Потенциал гаять зур.

Фото: ТР Президенты сайты (Марсель Бадыйкшин)

ТУЛЫРАК:

Беренче Каспий икътисадый форумында Россия делегациясен РФ Премьер-министры Дмитрий Медведев җитәкләде. «Каспий диңгезе: халыкара икътисадый хезмәттәшлекне ныгыту файдалары» дип аталган Халыкара конференция форумның төп вакыйгасы булды. Углеводород чималыннан һәм башка табигый ресурслардан бергәләп нәтиҗәле файдалану Каспий төбәгенә кергән барлык илләр икътисадының да сыйфат ягыннан үсеше өчен зур әһәмияткә ия, дип билгеләп үтте Төрекмәнстан Президенты Курбангулы Бирдемөхәммәдов конференцияне ачу тантанасында. Якларның хезмәттәшлеге, аның сүзләренә караганда, тигез хокуклы һәм нәтиҗәле партнерлык принципларына таянырга тиеш.

Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Дмитрий Медведев, якын араларда Мәскәү Каспий диңгезенең хокукый статусы турындагы конвенцияне ратификацияләп бетерәчәк, дип белдерде. Документны бер ел элек Иран, Төрекмәнстан, Россия, Казахстан һәм Азәрбайҗан имзалаган иде. Билгеләп үтелгәнчә, Россиянең Каспий төбәге илләре белән тышкы сәүдә әйләнеше үсешкә бара, ләкин үзара файдалы хезмәттәшлекнең потенциалы тагын да зуррак – РФ әлеге төбәк илләре белән тышкы сәүдә әйләнешен берничә тапкырга арттырырга ниятли.

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов мәртәбәле кунакларга һәм форумда катнашучыларга «Turkmen sahrasy-2019» халыкара күргәзмәсендә Татарстан предприятиеләре экспозициясен күрсәтте. Ул «Татнефть» компаниясе эшкәртмәләре, медицина модификациясендәге «Ансат» вертолеты, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге МВ-500 җиңел моторлы очкычы турында сөйләде. Форум кысаларында шулай ук Курбангулы Бирдемөхәммәдовның Рөстәм Миңнеханов белән очрашуы узды. Яклар икътисад һәм мәгариф өлкәләрендәге хезмәттәшлек мәсьәләләрен тикшерделәр.

Исегезгә төшереп үтик,Төрекмәнстан делегациясенең күптән түгел генә Татарстанга булып узган сәфәре вакытында «КАМАЗ» автомобильләрен Төрекмәнстанга сату (114 йөк машинасыннан торган беренче партия бу илгә килеп җитте инде), «Татнефть» ГАҖнең төрекмән нефть табу һәм нефть эшкәртү компанияләре белән уртак эшен дәвам итүе турындагы килешүләргә ирешелде. Яшел Үзән суднолар төзү заводы А145 проекты буенча ясалган тизйөрешле беренче пассажир судносын бу илгә озатты һәм суднолар төзү өлкәсендә хезмәттәшлекне дәвам итү турында сөйләшүләр уздырды. Татарстанның «МВЕН» фирмасы МВ-500 самолетлары белән тәэмин итү һәм аларны җитештерүне локальләштерү буенча эшен башлап җибәрде. «КЭР-холдинг» компаниясе «Төрекмәнгаз» Дәүләт концернының газ-турбина двигательләрен капиталь ремонтлау буенча уздырылган халыкара тендерда отты. Казанда җитештерелә торган медицина билгеләнешендәге «Ансат» вертолетларын Төрекмәнстанга сатуны оештыру буенча эш алып барыла. Әлеге планнарның барысы да диярлек Беренче Каспий икътисадый форумы барышында меморандум килешүләре белән ныгытылды.

БЕЛЕШМӘ:

Татарстанда 1000 гә якын төрекмән даими яши. Хәзерге вакытта өч меңгә якын Төрекмәнстан гражданы ТР белем бирү учреждениеләрендә укый. Бөтендөнья Татар конгрессы мәгълүматларына караганда, Төрекмәнстанда 15 меңнән артык татар гомер кичерә.

ТӘТЕШ.
ЯКЫНДАГЫ МЕДИЦИНА

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Президенты:
– Ел дәвамында бар халыкка медицина тикшеренүләре уздырып бетерәчәкбез, күчмә поликлиникаларда эшләүче табиблар – Казанның иң яхшы белгечләре. Шуңа күрә халык әлеге кайгыртучанлыкны һәм игътибарны тояр, дип уйлыйм.

НӘРСӘ:

Тәтеш районына эш сәфәре

КАЙДА:

Тәтеш, Бакырчы авылы

КАЙЧАН:

13 август

Марат Садыйков, ТР сәламәтлек саклау министры:
– Күчмә поликлиникалар Татарстанның төньяк-көнчыгышы, көньяк-көнчыгышы һәм үзәк өлешләре буенча йөриячәк. Мондый поликлиникаларның үткәрү сәләте – көненә – 70–100 кеше.

Фото: Александр Ефремов

ТУЛЫРАК:

Тәтеш районында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов күчмә поликлиника эше белән танышты. Ул теләсә нинди юлларда йөри ала торган автомобиль базасында ясалган һәм иң ерак авыл торак пунктларына кадәр барып җитәргә сәләтле. Комплекс хәтта район үзәгенә кадәр дә яхшы юллар белән бәйләнмәгән иң ерак авылларда яшәүче гражданнарга медицина тикшеренүләре үткәрергә мөмкинлек бирә.

– Ел дәвамында бар халыкка медицина тикшеренүләре уздырып бетерәчәкбез, күчмә поликлиникаларда эшләүче табиблар – Казанның иң яхшы белгечләре. Шуңа күрә халык әлеге кайгыртучанлыкны һәм игътибарны тояр, дип уйлыйм, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Бүген иң мөһиме – профилактика һәм төрле авыруларны алдан кисәтү. Әйе, авылда ФАПлар эшли, анда беренчел ярдәмне күрсәтәләр, шунда ук диспансерлаштыруның беренче этабын узарга була, әмма медицинаның барлык мөмкинлекләре анда юк. Хәзер исә без медицина ярдәмен тагын да якынрак, нәтиҗәлерәк итәбез. Безгә профилактика эшен системага салырга кирәк.

ТР сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков хәбәр итүенчә, республика буенча барлыгы дүрт мобиль медицина комплексы эшләячәк. Халыкны терапевт, невролог, уролог, хирург, акушер-гинеколог, офтальмолог кебек белгечләр кабул итәчәк. Комплекслар тиешле барлык диагностика һәм лаборатория җиһазлары белән тәэмин ителгән.

Шул ук көнне Татарстан Президенты районда яңа модульле фельдшер-акушерлык пункты һәм күпфункцияле үзәктә – Тәтешнең Вахитов урамындагы авыл клубында булды, Бакырчы авылындагы борынгы «Хәят» чишмәсен карады. Хәзерге вакытта чишмә янындагы территорияне төзекләндерү-матурлау эшләре тәмамланып килә. Чишмә буенча яктырткычлар куелган, җыйнак кына ял итү урыны ясалган, коесы яңартылган.

Бакырчы авылы янындагы күпьеллык үләннәр утыртылган басу Рөстәм Миңнехановның Тәтеш муниципаль районы хуҗалыклары җитәкчеләре һәм җирлек башлыклары белән очрашу урынына әверелде. Урып-җыю кампаниясенең барышы белән Тәтеш муниципаль районы башлыгы Рәмис Сафиуллов таныштырды.

БЕЛЕШМӘ:

Күчмә медицина комплексы «КАМАЗ-65225» (6х6) автомобиле һәм изотермик күпсекцияле фургон базасында эшли. Анда теркәлү бүлмәсе һәм халыкны кабул итү өчен алты кабинет урнаштырылган. Медицина хезмәткәрләрен күчмә медицина комплексы урнашкан урынга Ford микроавтобусларында алып киләләр. Беренче мобиль комплекс Казанның «7 нче шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССУ карамагына тапшырылды, ул инде республиканың Идел аръягы районнарына хезмәт күрсәтә. Тагын өч шундый күчмә комплекс биреләчәк. «Күчмә поликлиника» комплекслары ерак торак пунктларда яшәүчеләр өчен комплексны диспансерлаштыру, функциональ диагностика уздыру, белгечләр тарафыннан тикшеренүләр үткәрү максатында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов күрсәтмәсе буенча сатып алынды.

Автор:
Ксения Сёмина

ҺӘРКЕМ ӨЧЕН ПРОГРАММА БАР

«Безнең бурычыбыз – Татарстанны һәркем рәхәтләнеп яшәрлек, һәркем килеп күрергә омтылырлык территориягә әйләндерү», – диган иде интервьюларының берсендә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов. Дәүләт программалары исә – татарстанлыларның тормыш сыйфатын яхшыртырга тиешле инструмент. Татарстанда бүген үзенең 34 дәүләт программасы гамәлгә кертелә, ул шулай ук Россия Федерациясендәге 23 дәүләт программасында һәм 7 федераль максатчан программада да катнаша.



БЕР ТӘРӘЗӘ НУРЫ

«Күпфункцияле үзәк (КФҮ) һәркем үзенең теләсә кайсы соравына квалификацияле ярдәм алырлык урынга әйләнергә тиеш», – дип белдергән иде бервакыт РФ икътисадый үсеш министры Максим Орешкин, КФҮ челтәрен төзү һәм үстерүнең беренче чиратта төбәк проекты булуын искәртеп. Бу юнәлештә Татарстанның алга китеше сизелә, бигрәк тә зур шәһәрләрдә. Без исә мондый үзәкләрдә, торак пунктның географик, демографик һәм башка үзенчәлекләреннән бәйсез рәвештә, кешеләргә һәрвакыт ярдәм күрсәтеләсенә инанырга булдык.

КФҮнең Кукмара филиалы вәкилләре халыкны график буенча кабул иткән авыл советы бинасына мин һәм белгеч **Рифат Мотыйгуллин** бер үк вакытта килеп җиттек. Территориаль аерымланган структура бүлекчәсенең (ТАСБ) эш көннәре һәм сәгатьләре биредә һәркемгә мәгълүм. Кабинет ишеге төбендә бер әби көтә иде.

– Миңа улым телефон алып кайтты, – ди ул зур сумкасыннан смартфонны табып алып. – Аның белән табибка чиратка язылып була, диде. Мин карт бит инде, ничек языласын белмим. Күршеләрем сезнең консультация бирүегезне әйтте. Булыш инде миңа, улым…

– Сезгә дәүләт хезмәтләре порталында теркәлергә кирәк. Әйдәгез тырышып карыйк, – ди Рифат. Бер 10 минуттан соң пенсионер әбине терапевтка язды тагын үзе.

– Әй, улым, безнең өчен бу бик авыр шул, миңа иртүк хастаханәгә барып, талон алу җиңелрәк, – ди әби, смартфонын сумкасына сала-сала.

– Бу баштарак кына катлаулы һәм озак кебек. Аннары күнегәчәксез. Барып чыкмаса, тагын бирегә килегез, – ди Рифат. – Без Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (ЕСИА) теркәлергә дә, салым бурычларын тикшерергә дә булышабыз…

Әби илһамланып китә:

– Килермен дә әле, улым, сез хастаханәгә караганда якынрак бит!

Әбидән соң чит ил паспорты юллап бер кыз килде.

– Без иске үрнәктәге чит ил паспортын ясый алабыз. Ризамы шуңа? – ди Рифат. КФҮнең Кукмара филиалы аша биометрик паспортны ясатып булмый әлегә*, әмма консультант ярдәмендә Федераль миграция хезмәте идарәсенә чиратка язылып була.

– Әйе. Сезгә документларны тапшырырга да бер айдан паспорт алырга мөмкин, диделәр.

– Дөрес әйткәннәр. 4 фотосурәт һәм документлар пакеты кирәк. Гаризаны биредә яза аласыз, дәүләт пошлинасын янәшәдәге почтада түләрсез. Яңа паспортны бирегә 30 көн эчендә ясап китерәчәкләр.

Территориаль аерымланган структура бүлекчәсендә кабул итү вакыты тәгәлләнгәч, без Рифат белән Кукмарага, «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәге» Дәүләт бюджет учреждениесе филиалына киттек.

Халыкка хезмәт күрсәтә торган кайбер үзәкләрдәге кебек мохиткә әлегәргә әзерләнәм. Чират, эсселек, озак көтүдән усалланган халыктыр инде монда да…

Әмма Кукмара күпфункцияле үзәгендә нәкъ киресенчә: якты, уңайлы, һәм, иң мөһиме – ялыктыргыч чират юк.

Стильле кызгылт-сары галстуклы матур униформа кигән консультант Эльмира киңәш сорап килүчегә «үзмәшгуль» сыйфатында теркәлү этаплары турында сөйли, «Минем салымнарым» кушымтасын куярга ярдәм итә һәм керем турында мәгълүматның шуның аша тапшырылуын аңлата.

* Сигез шәһәрдәге КФҮ офисында исә мондый хезмәт бар: Түбән Кама, Яр Чаллы, Яшел Үзән, Лениногорск, Әлмәт, Бөгелмә, Чистайда, Казанның «Идел буе» КФҮндә.

Автор фотолары

Айнур Мөхәммәтшин

– Физик затлар белән эшләсәгез, салым – 4 процентны, юридик затлар белән эшләсәгез, 6 процентны тәшкил итәчәк, – дип аңлата консультант.

Сүз уңаеннан, дәүләт органнарыннан (бигрәк тә федераль органнардан) җавап алу тизлеге консультантның компетентлыгына, аның кабул ителә торган документларны никадәр тәфсилләп тикшерүенә бәйле. Шунлыктан Кукмарада да, башка КФҮ филиалларында да хезмәткәрләрне укытуга зур игътибар бирелә. Күп консультантларның юридик белеме яки Росреестрда, кадастрлар палатасында һ.б. эшләү тәҗрибәсе бар.

Ул арада исә Эльмира инде икенче берәүгә җир кишәрлегенә милек хокукын теркәү өчен дәүләт пошлинасын түләргә ярдәм итә. Җир кишәрлеген сатып алу өчен гаризаны да биредә үк язып була. КФҮ белгечләре аны үзләре башкарма комитетка тапшырачак, карар 7 көн эчендә кабул ителә. Биредә төзелеш башлауга гариза биреп һәм ризалык алып, аның башлануы һәм тәмамлануы турында белдерү кәгазен дә алып була. Тагын әле, Кукмарадан чыкмыйча гына, мәсәлән, Казанда сатып алынган фатирга милек хокукын теркәргә дә мөмкин. Күп очракларда берничә хезмәткә бер генә гариза язарга кирәк.

– Хәзер кадастр исәбенә кую, хокукларны дәүләт теркәве, шулай ук Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан (ЕГРН) белешмәләр алу буенча хезмәтләргә ихтыяҗ аеруча зур. Икенче урында – Россия гражданы паспортын алыштыру, теркәлү, юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне, КФХларны теркәү, алар турында мәгълүмат бирү, төрле белешмәләр алу, машина йөртү таныклыгын алыштыру. Хосусый торак төзелешенә, җир кишәрлекләренә бәйле хезмәтләргә дә ихтыяҗ зур, – ди КФҮнең Кукмара филиалы җитәкчесе **Айнур Мөхәммәтшин.**

– Быел бигрәк тә кишәрлекләрне һәм торак йортларны «дача амнистиясе» буенча гадиләштерелгән теркәү хезмәте популяр, ул 2021 елга кадәр озайтылды. 8 сентябрьдә сайлауда яшәү урыныннан башка җирдә тавыш бирү өчен таныклык алуга гаризаларны актив кабул итәбез. Яңа хезмәт тә пәйда булды – аучылык ресурсларыннан файдалануга рөхсәт бирү. Паспорт һәм аучылык билеты гына кирәк.

Кукмара филиалына күп эш йөкләнгән. Аның хезмәткәрләре график буенча Территориаль аерымланган структура бүлекчәләренә бара, районда исә алар 18 (1 мең авыл кешесенә бер ТАСБ ачыла). Филиалда 182 төрле хезмәт күрсәтелә. Исәпләүләр буенча, быел һәр айда 2,7 мең хезмәт күрсәтелгән. Эш күп булса да, филиал белгечләре һәрвакыт яхшы кәефтә һәм – монысы иң мөһимедер – үз эшен яратып башкара.

– Алар барысы да бик әйбәт, – дип хезмәткәрләрнең әле берсенә, әле икенчесенә күрсәтә талон буенча үз чиратын көтеп утыручы Рәзидә апа. – Һәрчак булышалар. Бушлай бит әле, җитмәсә! Аллаһ аларга исәнлек бирсен…

БАЛАЧАК, ҮСМЕРЧАК, «ЯШЬЛЕК»

«Парижга кадәр Мамадышны барып күрегез», – дип үзгәртәсе килә популяр гыйбарәне. 2015 ел Татарстанда парклар һәм скверлар елы дип игълан ителгәннән һәм республикада яшел зоналарны төзү, реконструкцияләү, төзекләндерү процессы башланганнан бирле, шәһәрдә һәр елны тылсымлы үзгәрешләр күзәтелә. Мамадыш – республиканың «Парк һәм скверлар» проектлары нәтиҗәсендә үзгәргән дистәләрчә торак пунктларыннан берсе.

Нократка коя торган Ушма буе ярларына барып тоташкан «Яшьлек» скверына без синоптиклар фаразлаган яңгыр башланыр алдыннан барып җиттек. Болытлы көн пейзажны тагын да матурайтып күрсәтә. Агач шәһәрчекле, сукмаклы, фонтанлы, амфитеатрлы, спорт мәйданчыклы һәм воркаут зоналы сквер үзе бер бәләкәй шәһәргә охшаган. Анда уенга мавыккан балалар хакимлек итә.

Зур агач замокта патша кызлары мәш килә. Алар искиткеч тизлектә манара баскычларыннан йөгереп менә дә, торбадан шуып төшеп, кабат эчкә керә. Кызларның берсе симез җирән песине әсирлеккә ала. Песи нишләткәнгә дә риза булып йөри.

Рюкзак аскан өч малай агач атларга атланган. Бу вакытта эшчеләр паркка щитларны ташый башлады, Яшьләр көне уңаеннан аларны җирле граффити-рәссамнар бизәячәк һәм заманча сәнгать мәйданчыгы пәйда булачак икән. Малайлар, уйнаудан туктап, рюкзакларыннан алма чыгара, ашыйашый щитларны куйганны күзәтә. Мөгаен, Марк Твен койма буяганны карап торган Том Сойерны шулай күз алдына китергәндер.

Кечерәк өч сабый – әллә кисмәк, әллә туп өстендәге Мюнхгаузеннар. Чәчен толымлап үргән кызчык иң өскә үрмәли һәм, офыкка карап торганда, Пеппи Озын Оекны хәтерләтә башлый. Әниләре килеп җитә: яңгыр килә, кайтырга вакыт. Балалар эшлекле кыяфәт белән локацияләрен үзгәртә. Яңгырга кадәр бөтен аттракционга кереп чыгасы бар бит әле, алар исә уйный башлады гына…

Әниләре Еленадан бирегә никадәр еш килүләре белән кызыксынам.

– Яңартылган скверда әле без беренче тапкыр. Бу искиткеч мәйданчык. Без ел саен Мәскәүдән туганнарыбызга кунакка кайтабыз. Тагын кая барып була соң? Нократ буенда рәхәт, тик балалар ярты сәгатьтән соң анда туя. Ә моннан исә алып чыгып китеп булмый. Мин, гомумән, Мамадышны яратам, ул матур, пөхтә. Һәрвакыт нindидер яңалык пәйда була, шунысы күңелгә рәхәт. Беләсезме, бу урында нәрсә иде? Сазлык! Хәзер исә шундый шәп парк, – дип сөйли Елена.

Парк сукмаклары буйлап Су Анасы, Шүрәле, Кызыл Башлык

Автор фотолары

һәм башка әкият геройларының агач сыннары урнаштырылган. Алар янәшәсендәге зур кублардагы Сергей Есенин һәм Лев Толстой портретлары кызыклы диссонанс тудыра.

Эшчеләр бәйрәмгә әзерлекнең чираттагы фазасына күчә: паркта лампалар кабына. Иртәгә амфитеатр сәхнәсендә неон кошлар яктысында рэпер-хитмейкер чыгыш ясаячак, скейт-парк территориясендә исә берсеннән-берсен уздырырга тырышып экстремаллар ярышачак... Барысының да кәефе шулкадәр шәп булачак ки, катнашучы һәм кунакларга салкын да, яңгыр да, җил дә комачауламаячак. Яшьләр эшләре буенча министр Дамир Фәттахов киләчәк һәм Мамадышта яшьләр үзәге ачуда булышырга вәгъдә бирәчәк. Программаны алып барган популяр шоумен Айрат Зәһриев исә үз Инстаграмында болай дип язачак: «Мин #Мамадышның гөрләп үсүенә һәм алга баруына сөенәм. Моны хәтта безнең бүгенге скверыбыз да дәлилли – элек сазлык булган җирдә стритбол, бию, воркаут, йога һәм башка спорт&иҗат мәйданчыклары гөрли, #яшьләр аларның файдасын күрә. Һәм алар шунда шөгыльләнә дә бит, мәйданчыклар БУШ ТОРМЫЙ, моның өчен шәһәр хакимиятенә, бүгенге программаны оештырган өчен @molodoi_mmd һәм @elmira_ahmet респект һәм алкышлар. Без яшь чакта мондый мөмкинлекләр булса, минем дә күп кенә дусларым ялгыш юлга кереп китмәс иде...»

«Без төп төзекләндерүне тәмамладык, база булдырдык, хәзер шунда дөрес локаль тормыш башланырга тиеш», – дигән иде бервакыт журналистларга Татарстан Президенты ярдәмчесе Наталия Фишман, Казандагы яңартылган җәмәгать урыннарына килүчеләргә төрле хезмәтләр күрсәтә торган бизнесны күз алдында тотып. Районнарда хәл башкачарак. Мамадышның кояшлы көндә дә, яңгыр яуганда да балалар уйный торган «Яшьлек» скверына карап, биредә тормыш «кайный» дип әйтеп буладыр.

Скверга калкулык ягыннан да кереп була. Риваять буенча, әлеге калкулыкка, иң беренче булып, Мамадыш шәһәренә нигез салучы карт менгән. Моның өчен сквер янәшәсендәге Давыдов урамын аркылы чыгып, баскычтан өскә күтәрелергә кирәк. Чынлыкта исә бу баскыч – 2018 елда «Парк һәм скверлар» архитекторлар төркеме концепциясе буенча яңартылган бульвар. Ярты юлны менгәч – түгәрәк мәйдан, аның үзәгендә көмешсыман алмагач сыны тора. Ул шома металл шар белән икегә аерылган. Постаментына: «ЧАЭС ликвидаторлары истәлегенә» дип язылган. Тагын да биектәрәк – Мамадыш өчен әһәмиятле мәдәни объект, җирле Эйфель манарасы. Шәһәр символын күптән түгел яңартканнар һәм ул хәзер милли татар мәдәниятенә хас яңа төсләр белән баетылган. Манараның күзәтү мәйданчыгыннан сквер да, Нократ та бик яхшы күренә. Бульварның икенче башында исә, калкулык түбәсендә – Совет урамы, ул хәзер киң колачлы итеп реконструкцияләнә. ■


Фото: Михаил Баранов (Яндекс.Фото)

Бүгенге сквер территориясе реконструкциягә кадәр

СӘЛАМӘТЛЕККӘ – МИЛЛИАРДЛАР

Экология темасы һәрчак актуаль булып кала, чөнки һәркемнең көндәлек тормышына кагыла. Социаль җаваплы компанияләр әйләнә-тирә мохитне саклауга аерым игътибар бирә. «Нефть», «нефть эшкәртү» һәм «экология» кебек төшенчәләрнең бер-берсе белән ни дәрәҗәдә яраша алуы, табигатьне саклау чараларының кайсылары нәтиҗәлерәк булуы, дәүләт һәм эре сәнәгать компаниясенең үзара эш механизмнары турында «Татарстан»га «Татнефть»нең уникаль бизнес-проекты – «ТАНЕКО» АҖнең әйләнә-тирә мохит бүлеге башлыгы Зилә Вәлишина сөйләде.

Фотолар «ТАНЕКО» АҖнән алынды
Реклама

Бервакыт ул үзе өчен табиб-гигиенист профессиясен сайлый. Химия, анатомия, физиология, клиник дисциплиналар буенча гына түгел, җитештерү технологияләрен дә тирән белүне таләп итү торган эшне. Табибларның, технологларның барысы да җитештерүдә сәнәгать гигиенасы, хезмәт медицинасы табибы күргәннәрне күреп бетерә алмый: кешегә һәм аның сәламәтлегенә тәэсир итәргә мөмкин булган химияне һәм физиканы. Кешене, ул яши һәм эшли торган мохитне саклау механизмнарын (төшенчәнең киң мәгънәсендә) күрү, аңлау һәм эшләтеп җибәрүне. Зилә Рәшитовна фикеренчә, куплаган кешеләрнең сәламәтлеген һәм тормышын саклау мөмкинлеге – эшчәнлегеңне багышларлык хезмәт. ТР Президенты Указы буенча аңа «Татарстан Республикасының атказанган экологы» дигән мактаулы исем бирелде.

– Бүген эре бизнесның экологияне, әйләнә-тирә мохитне яхшыртуны кайгыртырга тиешлеге турында барысы да сөйли. Бу бик абстракт төшенчәләр. Сез шундый эре нефть эшкәртү комплексының экологы буларак үзегезнең төп бурычыгызны нидә күрәсез?

– Бурыч гади – абстракт төшенчәләрдән гамәлләргә күчү. «ТАНЕКО» кебек предприятиене төзегәндә дә шулай булды. Бүген республика, «Татнефть», Түбән Кама шәһәре җитәкчелегенең җитештерүләрне кешеләр өчен максималь дәрәҗәдә, иң беренче чиратта, экология һәм сәнәгый иминлек ягыннан куркынычсыз итү өчен булдыра алганның барысын да эшләве бар кешегә дә мәгълүм. Һәм бүген «ТАНЕКО»га нефть эшкәртү технологияләре буенча гына түгел, әйләнә-тирә мохитне саклау технологияләре буенча да тәҗрибә алу максатында илебезнең төрле почмакларыннан һәм чит илләрдән тулы бер делегацияләр килә. 2018 ел өчен генә дә комплексның табигатьне саклау эшчәнлегенә киткән чыгымнары 4 миллиард 492 миллион сумны тәшкил итте. Әлеге чыгымнарга табигатьне саклау объектларын: чистарту корылмаларын, су әйләнеше системаларын, һаваны чистарту системаларын һәм башкаларны төзү һәм эксплуатацияләү керә.

Бары тик бер генә мисал. Күкерт кушылмаларын һавага чыгару – нефть эшкәртүнең авырткан урыны. «ТАНЕКО»ны төзегәндә күкерт кушылмаларыннан котылуның иң нәтиҗәле ысулы кулланылды. Бу күкерт кушылмаларыннан алга таба файдаланып булырлык продукт җитештерү. Элементар күкертне чыгару тирәнлеге – 99,6 (!) процент. Күкертнең калган өлешен тотып алу өчен җайланмада койрыкта калган газларны чистартып бетерү дә каралган.

Бүген комплекс эшчәнлегенең мөһим аспекты – ягулыкның экологик чиста төрләрен сату хисабына Россия шәһәрләрендә экологик вазгыятьне яхшырту. Безнең Евро-5 дизель ягулыгы танылу яулады. Быел Евро-5 экологик классына туры килүче автомобиль бензиннары җитештерә башладык. Югары сыйфатлы ышанычлы нефть продуктлары җитештерүчесе абруен формалаштыру һәм аны югалтмау «ТАНЕКО»ның стратегик максаты.

Февральдә Владимир Путинның Татарстанга визиты вакытында видеоэлемтә буенча «ТАНЕКО»да сыйфатлы һәм экологик бензин җитештерүенә рәсми старт бирде. Әлеге җитештерүнең ачылышы берничә ел элек анонсланган иде. Ул вакытта Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов хаклы рәвештә «бу бернинди өстәмәләрсез югары сыйфатлы ягулык җитештерелә торган иң заманча завод» дип билгеләп үткән иде.

Түбән Кама нефть эшкәртүчеләрнең төп майлар җитештерүе белән берләштерелгән комбинацияле гидрокренинг җайланмасын эшләтеп җибәрүгә бәйле хезмәтләренең мантыйкый дәвамы менә шундый була. Әлеге җайланманы эксплуатациягә кертү белән, берничә ел элек Евро-5 дизель ягулыгы, РТ, ТС-1 маркалы авиация керосиннары эшләнә башлый. Узган елда гына да комплекста уникаль үзлекләре белән аерылып торучы ике миллион тонна ярым дизель ягулыгы җитештерелде.

– Экологик проектлар икътисадый яктан нәтиҗәле була аламы?

– Тагын берничә сан китерергә рөхсәт итегез. Бер кубометр техник суның кыйммәте 10 сум тора, шул ук күләмдәге пычратылган суны чистартуның бәясе – 130 сум. Беренче карашка, чиста суны сатып алу, пычрагын түгү җиңелрәк кебек. Ләкин «Татнефть» өчен «зыян салма» принцибы беренчел. Табигатькә зыян китермә, кешегә зыян китермә… Шуңа күрә «ТАНЕКО»да чистартылган су Чулман елгасындагы суга караганда чистарак. Экология чараларыннан икътисадый нәтиҗәлелек акчаларда да, алтын белән санаганда да юк. Ул кешенең сәламәтлегендә чагыла. Ә кеше сәламәтлеге күпме тора?

– Аңлашыла ки, «ТАНЕКО» экология җаваплылыгы дәрәҗәсен алга таба күтәрү өчен нон-стоп режимында үзкөйләү механизмын үстерә бара. Бу яктан караганда, компания белән дәүләтнең үзара хезмәттәшлеген Сез ничек итеп күрергә теләр идегез? Дәүләтнең табигатьне саклау сферасында көйләү чараларын бары тик каттыйландыра гына баруы аңлашыла…

– Законнарның үтәлешен саклау – дәүләтнең нигезе. Закон актларының аңлаешлы, логик яктан дөрес булуы – икенче мәсьәлә. Чөнки карарларның, күрсәтмәләрнең бер үк пунктларын төрлечә аңлатып булу мөмкинлеге эшкә комачаулык китерә.

«Татнефть» һәм «ТАНЕКО» иң яхшы технологияләрнең шактые буенча бүгенге көндә Россия казанышларын узып китте. Бүген бездә калдык суларны чистартуның экологик нәтиҗәлелеге, һавага чыгарылган матдәләрнең, калдыкларның барлыкка килүенең чагыштырма күрсәткечләре дөнья казанышлары дәрәҗәсендә.Шулай да безнең барлык эшчәнлегебез табигатьне саклау буенча федераль, республика ведомстволарының җентекле игътибар үзгендә. Үземнән шуны әйтә алам: белемле белгечләр, кайда гына эшләсәләр дә, һәрвакыт кирәкле.

– «ТАНЕКО»ның баш экологы буларак, Сезнең өчен комплексның табигатьне саклау эшендә нәрсә мөһим нәтиҗә булды һәм якын киләчәктә нинди проблемалар хәл ителергә тиеш?

– Пычратуларны булдырмый калу буенча куелган гаять зур хезмәтнең нәтиҗәсе булуы мөһим. Җитәкчелек, коллегалар, партнёрларның экология сорауларында бер команда булуы мөһим. Якын араларга һәм киләчәккә бурыч – төзелгән барлык объектларны, шул исәптән табигатьне саклауга караганнарын да, тиешле халәттә тоту. Бу бер вакыт «зыян салма» дип кабул ителгән сәясәтебезне без «ТАНЕКО»ны алга таба үстерүдә дә кулланырга ниятлибез дигәнне аңлата.

– Нефть, нефть эшкәртү һәм экология – үзара ярашучы төшенчәләрме?

– Барысы да әлеге тармакта эшләүче кешеләрнең мөнәсәбәтенә бәйле. Безнең компаниядә һәр хезмәткәр диярлек күпмедер дәрәҗәдә эколог. Шуңа күрә туган йортыбыз – Җир турында кайгырту, аны ярату безгә һәм киләчәк буыннарга сәламәт һәм бәхетле яшәргә мөмкинлек бирәчәк.

«ТАНЕКО» әзер продукцияне агызганда һәм саклаганда инновацияле ысуллар куллана. Нефть продуктлары салынган барлык резервуарлар да – йөзә торган понтоннар белән, ә тимер юл һәм автомобиль цистерналарына нефть продуктларын агыза торган эстакадалар – нәтиҗәлелеге 99 процентттан артык парны рекуперацияләү булган җайланмалар белән җиһазландырылган.

Евро-5 стандартлы дизель ягулыгы куллану зарарлы газлар аша атмосферага күкерт окисен чыгаруны 5300 тоннага кыскарта.

Компаниянең дус-тату коллективы «ТАНЕКО» АҖнең баш экологы Зилә Рәшитовна Вәлишеваны «Татарстан Республикасының атказанган экологы» дигән мактаулы исем бирелүе белән чын күңелдән котлый һәм аңа ныклы сәламәтлек, һөнәри эшчәнлегендә яңадан-яңа уңышлар тели. «ТАНЕКО»ның казанышларында, хөрмәтле Зилә Рәшитовна, һичшиксез Сезнең өлешегез һәм уртак эшкә керткән фидакарь хезмәтегез зур!

TANECO

Татарстан Республикасы, Түбән Кама ш., «ТАНЕКО» АҖ
Тел.: (8555) 49-02-00
www.taneco.ru

ЕГЕТ ҖАНЛЫ НЕФТЬЧЕ

Татарстан – Россиянең иң тотрыклы һәм икътисадый яктан нәтиҗәле эш алып бара торган төбәкләреннән берсе. Әлеге алдынгылыкның нигезендә – республика халкының күп еллык тырыш хезмәте. «Татнефтепром-Зүзәйнефть» АҖ генераль директоры, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, чын профессионал дәрәҗәсенә лаек затларның иң күренекле вәкилләреннән берсе, үз төбәгенең патриоты, сайланган хезмәт юлына һәрчак тугры Шамил Яһүдин июль аенда II дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнде.

Сугышның бар авырлыкларын җиңеп, җиде балага олы юлга тормыш биргән чын хезмәтчәннәр гаиләсендә тәрбияләнеп үсә ул. 1976 елда Казан дәүләт химия-технология институтын тәмамлагач, Шамил Яһүдин Нурлат разведка-бораулау идарәсенә автомобиль-трактор цехы механигы булып эшкә керә. Ул үз эшендә иң яхшылардан булырга хыялланып, намус белән, тырышып хезмәт куя. Шуннан бирле тормышының нефть чыгару тармагы белән тыгыз бәйләнеп, киләчәктә аңа иң яхшы кече нефть компанияләреннән берсенең язмышы өчен хәлиткеч карарлар кабул итәргә насыйп булачагын яшь белгеч күз алдына да китермәгәндер.

Егерме елдан артык вакытны эченә алган һөнәри үсеш баскычларыннан соң, ул «Зүзәйнефть» нефть-газ табу идарәсе базасында төзелгән «Татнефтепром-Зүзәйнефть» акционерлык җәмгыятен җитәкли. Әлеге җәмгыять Нурлат районында (Зүзәй һәм Мамык авылы янында) югары күкертле, парафинлы һәм үтә үзле нефть ятмаларын эшкәртә. Шамил Габделхәй улы җитәкчелегендә компания базар икътисадына җайлашты, дөнья дәрәҗәсендәге югары технологияләр һәм стандартлар кертте. Узган елларда предприятие Татарстан һәм Россиянең иң яхшы кече нефть компанияләренең берсе статусын яулап, эш даирәсен киңәйтте һәм потенциалын арттырды.

Хезмәт казанышлары дәүләт дәрәҗәсендә күп тапкырлар билгеләп үтелсә дә, Шамил Яһүдин, ирешелгәннәр белән канәгатьләнеп, туктап калучылардан түгел. Аны җаваплылык хисе һәм якташларының тормышын тагын да яхшырту омтылышы йөртә. Шамил Габделхәй улының туган ягы – Аксубай районы авылларында, шулай ук Нурлат һәм Яңа Чишмә районнары салаларында яңа социаль объектлар барлыкка килә һәм яңа проектлар тормышка ашырыла, ә халык безнең мөрәҗәгатьләрне ишетерләр һәм хупларлар дип өметләнә ала. Компания җитәкчесенең уңышлы башлангычы белән «Татнефтепром-Зүзәйнефть» АҖнең хәйрия эшчәнлеге күркәм традициягә әверелде, язмышның төрле сынауларына дучар булган күп гаиләләргә әлеге эшчәнлек кысаларында ярдәм күрсәтелде. Предприятиенең Болгар каласын һәм Зөя шәһәр-утравын торгызу кебек республика өчен әһәмиятле проектларны хуплап каршы алуы да гаҗәп түгел.

Шамил Яһүдин башлаган эшләр барысы да үсештә. Моннан егерме ел элек «Татнефтепром-Зүзәйнефть» Нурлат районының «Сөлчә» хуҗалыгына кураторлык итә башлый. Нефтьчеләр ярдәме белән алдынгы җитештерү базасы булдырыла, авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү, сөт һәм сөт продуктлары җитештерү җайга салына, терлек суючу цехы, ит продуктлары җитештерү цехы, икмәк пешерү цехы төзелә. Шамил Яһүдин ярдәме белән предприятие кризис елларын уңышлы уздыра. Мөстәкыйль «Нурлат сөте» ҖЧҖ предприятиесе буларак үзгәртелеп, хуҗалык бүген дә республиканы сыйфатлы продукция белән тәэмин итә; салымнар, кредитлар һәм хезмәт хакы буенча бурычлары булмаган оешма эш белән тәэмин итә торган җирле эре ширкәтләрдән санала.

Шамил Яһүдин турында сөйләгәндә, аны «егет җанлы нефтьче» дип атыйлар. 2000 нче еллар башында аның инициативасы белән Мамык авылында «Ягуар» спорт клубы оештырыла. Самбо, дзюдо, көрәш буенча тренерлар тырышлыгы нәтиҗәсендә монда берничә Россия, Европа һәм дөнья чемпионы тәрбияләнгән. Нурлат яшьләренең тулы бер буыны бушлай, димәк, һәркем өчен ачык дәресләр аша спорт өлкәсендә бик шәп эзерлек алды. Россиянең ат спорты тармагында «Ягуар» әле ат үрчетү үзәге буларак та билгеле. Биредә саф инглиз токымлы йөздән артык менге ат үстерделәр. Чабышкылар бүген районның горурлыгы булып тора, ат чабышларын сөючеләр өчен аларның исемнәре бик яхшы таныш. Алар арасында – Шамил Яһүдин хуҗалыгында туган Реал Лемон һәм Ричмонд Хилл да бар. Бу өлкәнең күп белгечләре нәкъ менә Нурлатта вакытта чабышкы буларак атказанган Балетмейстерны да яхшы хәтерли. Үз вакытында ул Татарстанның Зур бүләген (Дерби) яулады, ә 2013 елда илнең төп ярышында (РФ Президенты призына чабышлар) җиңүче булды. «Ягуар»ның башка чабышкылары да билгеле, әйтик, Атлантик Уэйв, Грандис. Голден Каскад, Роял Вуд кебек айгырлар. «Ягуар» спорт клубы Краснодар краенда филиалын ачты, анда белгечләр бу чабышкыларның нәселен үрчетү һәм селекцияләү белән шөгыльләнә. Шунда ук саф гарәп токымлы атлар да үрчетәләр.

Шамил Габделхәй улы Яһүдинның уңыш сере бик гади: ул республика белән бер сулышта яши, хакимият вәкилләре һәм гади кешеләр белән бер үк дәрәҗәдә үзара ышаныч һәм ихласлылык белдереп сөйләшә ала, шул рәвешле ике арада бик кирәкле һәм мөһим бәйләнеш барлыкка килүгә булыша. Хәзерге вакытта Татарстан Республикасының V чакырылыш Дәүләт Советы депутаты, Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты әгъзасы булган Шамил Габделхәй улының бу сыйфаты аеруча әһәмиятле. Һөнәри өлкәдәге, оештыру эшендәге һәм гади тормыштагы үзенең бай тәҗрибәсен Шамил Яһүдин Татарстанның үсеше өчен башкарыла торган һәр хезмәтендә файдалана.

Фото «Татнефтепром-Зүзәйнефть» АҖнән алынды

Реклама

МАКТАУЛЫ ИСЕМ – ЛАЕКЛЫ БЕЛГЕЧКӘ

«Гасыр проекты» – Татарстан АЭС төзелеше ябылганнан соң, төзүче-атомчы Рәшит Габделхаковка квалификациясенә лаеклы эш озак кына табылмый тора. Әмма бүген аның хезмәт юлында – тормышка ашырылган дистәләгән мөһим объект. Лаеклы мактау, дан да килде.

2019 елның августында **Рәшит Сәмим улы Габделхаковка** «Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе» дигән мактаулы исем бирелде, редакция аны да, «Татнефтехиммонтаж» идарәче компаниясенең бөтен коллективын да ихлас котлый. Татарстанның санап үтелгән барлык мөһим объектлары нәкъ менә шушы компания тырышлыгы белән сафка бастырыла.

Ул 1964 елның 14 июлендә Ульяновскида туа. «Җылылык һәм атом электростанцияләре төзү» белгечлеге буенча Мәскәү инженер-төзүчеләр институтын тәмамлап, 1986 елда хезмәт эшчәнлеген башлый. Татарстан АЭС төзелеш идарәсендә мастер, эшләр башкаручы, «Камгэсэнергострой» участок башлыгы булып эшли.

2000 нче еллар тирәсендә, дәүләт дефолттан чыккач, аның куркынычсызлык күзлегеннән караганда бик ышанычлы объектлар төзү өлкәсендәге тәҗрибәсенең Түбән Камадагы берничә гигант төзелештә җитәкче вазыйфаларда кирәге чыга. 2014 елның июненнән Рәшит Сәмимович «Татнефтехиммонтаж» Идарәче компаниясе» ҖЧҖдә баш инженер вазыйфасында эшләп, республика өчен гаять әһәмиятле объектларны сафка бастыруда катнаша. 2016 елдан ул – «Татнефтехиммонтаж» идарәче компаниясе» генераль директорының гомуми төзелеш мәсьәләләре буенча урынбасары.

«ТНХМ» ИК» ҖЧҖ генераль директоры Сергей Зотов урынбасарыннан канәгать:

– Рәшит Сәмимович бик зур эш тәҗрибәсенә һәм оештыру сәләтенә ия. Аның җитәкчелегендә комплекста – төзелеш мәйданчыгын әзерләүдән башлап объектларны файдалануга тапшыруга кадәр – зур күләмдә төзү-монтаж эшләре башкарылды. Белгеч объект төзелешенең тулы процессын, заказчылар, генераль подрядчылар һәм проект институтлары белән эшләүнең барлык нечкәлекләрен белә.

Төзелеш өлкәсендә киң техник белемгә ия булып, Рәшит Сәмимович остаз һәм укытучы сыйфатында аларны яшь белгечләргә дә тапшыра, төзелеш өлкәсендәге белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең белемнәрен тикшерү буенча квалификация комиссияләрендә әгъза булып тора.

Хезмәттәшләре әле Рәшит Габделхаковның кешеләр белән мөнәсәбәтләрдә әдәплелеген һәм подрядчы оешмалар белән нәтиҗәле бәйләнешләрне җайга сала белүен дә билгеләп үтә. Ә бу – республика нефть химиясе тармагындагы мөһим объектларның кыска вакыт эчендә кулланышка тапшырылуына гарантия дигән сүз.

2002–2004 елларда Рәшит әфәнде «Татнефть» ГАҖ майлар заводы, окисьләштерелгән юл битумы, түбә ябу һәм төзелеш өчен битумнар эшләп чыгару җайланмасы (Австрия проекты, «Битурокс» процессы) һәм Түбән Кама нефть эшкәртү заводы төзелешендә катнаша.

Рәшит Габделхаковның хезмәт юлында шулай ук «Оргсинтез»да бисфенол һәм поликарбонат җитештерү, «ТАНЕКО»да күкерт җитештерү җайланмалары төзелеше дә бар.

Бүген Рәшит Габделхаков җитәкчелегендә Әшәлчә ятмасындагы өч җылылык үзәге (Төньяк Әшәлчә, Зур Кәминкә һәм Әшәлчә-2) төзелеше тәмамланган.

Шулай ук «УПСВН Кармалка» үтә үзле нефть эшкәртү җайланмасы сафка бастырыла. Әлмәт газ эшкәртү заводын төзү һәм реконструкцияләүдәге яңа объектлар – эшкәртелмәгән газ җайланмасы һәм факел җайланмасында эшләр ахырына якынлаша.

Сәнәгать объектлары белән бергә мәдәни әһәмияткә ия объектлар төзүдә дә катнашуын искә алырга мөмкин. 2008 елда Казан епархиясе бинасы реконструкцияләнде, шуның өчен Рәшит Габделхаков Казан архиепископы Анастасийның Мактау кәгазе белән бүләкләнде. Быелтыр Болгарда мәйданчыкны сайлаудан башлап файдалануга тапшыруга кадәр Рәшит Сәмимовичның турыдан-туры катнашында «Болгар цивилизациясе музее» комплексы функцияләрен дә колачлаган Елга вокзалы бинасы төзелде, ул Татарстанның Мәдәният министрлыгы карамагына сыйфатның барлык стандартларына туры китереп тапшырылды. Ә башкача мөмкинме соң? Рәшит Сәмимович үзе дә РФ Ностроой реестрында тора, төзелеш контроле буенча җаваплы зат һәм вәкил ул. Төзелеш өчен вакытның кысанлыгына һәм бихисап күп бурычлар куелуга карамастан, җитәкче кеше эшчеләрнең иминлеген төп мәсьәлә дип саный. Ул сәнәгать куркынычсызлыгы һәм хезмәтне саклау өлкәсендә белемнәрне тикшерү буенча аттестация комиссиясе рәисе дә булып тора.

Рәшит Габделхаков үз эшләре белән Татарстан Республикасының чәчәк атуына һәм тотрыклы үсешенә саллы өлеш керткән шәхесләрдән. Ике тапкыр (2011, 2015 елларда) Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының Мактау грамотасына, Татарстан Хөкүмәтенең Рәхмәт хатына (2017 ел) лаек булуы һич тә юкка гына түгел.

Управляющая компания
ТНХМ
ТАТНЕФТЕХИММОНТАЖ

Реклама   Фото «ТНХМ» ИК» ҖЧҖнән алынды

ЧҮП-ЧАР БЕЛӘН НИШЛӘРГӘ?

Бүген Россиядә чүплекләр 4 миллион гектар мәйданны били. Бу территорияне Нидерландлар яки Швейцария кебек илләрнең мәйданы белән чагыштырырга була. Асылда илне әлегә бик зур, бик иркен булуы гына коткара. Татарстан башкаласы турында сөйләсәк, Казанның чүп полигоннары, санитар зоналарны исәпкә алып, йөзләгән гектар мәйданга җәелгән. Хуҗалык әйләнешеннән чыгарылган бу территорияләр торак комплекслары, балалар мәйданчыклары, парклар һәм җәмәгать урыннары була алыр иде...

ТЕЛӘК КЕНӘ БУЛСЫН

Бер ел элек Казанда коммуналь калдыкларны аерып җыю белән бәйле сынау проекты старт алды.

Бүген исә республика башкаласында каты коммуналь калдыкларны аерып җыю өчен 1133 мәйданчык әзерләнгән. Бу чүп мәйданчыкларының гомуми саныннан 64%ны тәшкил итә. Аларда 4873 контейнер урнаштырылган.

Шәһәрдә чүп үткәргечле 464 йорт кала. Шуларның 165ендә халык тышкы контейнерлар файдасына карар кабул итте – бу йортлар өчен ел ахырына кадәр 23 яңа мәйданчык төзү планлаштырыла.

Тулаем алганда, эре идарә компанияләренең 97% йортында, шулай ук «Весна», «Арт-Сити», «Светлая долина», «XXI гасыр», «Салават күпере» һәм башка торак комплексларында калдыклар аерып җыела, туплана һәм чыгарыла.

Калдыкларны аерып җыю системасы көндәлек тормышның мәҗбүри элементына әверелеп бара. Бу мәсьәләне хәл итүдә Казанның күпчелек халкына муниципалитет актив ярдәм итсә, ишегалларында калдыкларны аерып җыю өчен контейнерлары булмаган кешеләр нишләргә тиеш?

Казанлыларга чүп-чарны аерып тапшырырга мөмкинлек бирә торган хезмәтләр турында Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесенең торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча урынбасары Искәндәр Гыйниятуллин сөйли:

– Хәзер Казанда экологик хәрәкәт көчәя һәм чүпне сортларга аеру өчен мөмкинлекләр арта бара. Эшкәртү өчен чүп-калдыкларны тапшырып була торган вариантлар берничә.

Беренчедән, бу – «ЭкоЛогик Казан» хәрәкәте активистлары оештыра торган күчмә пунктлар. Якынча айга бер тапкыр алар, халыктан чүп-чар җыя-җыя, билгеле бер маршрут белән шәһәрне йөреп чыга. Аларның сайтында һәм социаль челтәрләрендәге сәхифәләрендә волонтерлар оештыра торган барлык акцияләр турында мәгълүмат бар.

Икенчедән, Казанда халыктан икенчел чимал җыю өчен 40 тан артык павильон урнаштырылган, аларда кабул ителә торган чүп-калдыкларның исемлеге шактый киң. Монда пыяла, пластик, металл, алюминий, катыргы һәм макулатура тапшырырга мөмкин. Өстәвенә, андый урыннарга икенчел чимал тапшыру бераз акча эшләп алу ысулы да әле ул. Сездә эшкәртүгә яраклы икенчел чимал булса, эшмәкәрнең аны җыеп эшкәртү пунктына илтеп бирү мөмкинлеге бар. Нәтиҗәдә, һәркем отышта кала.

Өченчедән, мондый акцияләр вакыт-вакыт төрле компанияләр һәм эре сәүдә үзәкләре тарафыннан үткәрелә. Теләк булганда, бу акцияләр турында мәгълүмат алуның кыенлыгы юк.

Моннан тыш, күп казанлыларга билгеле «Игелекле эшләр көне» фонды кирәкмәгән кием-салым, аяк киеме, китаплар, уенчыкларны хәйрия максатында кабул итә. Шуңа күрә артык әйберләрне чүплеккә ташлыйсы урынга әлеге фондка, Калинин урамындагы 3 нче йортка илтеп бирергә була.

Гомумән, теләк булса, икенчел чималны теге яки бу күләмдә кабул итә торган урыннарны табарга мөмкин ул. Һәм бу сервисларның саны акрынлап арта бара. Өстәвенә, Казан ишегалларының яртысыннан артыгы ПЭТ-тара җыю өчен челтәрләп ясалган контейнерлар белән җиһазландырылган. Сүз уңаеннан, казанлылар аларга ияләште инде. Пластик чүпләрне дә, ПЭТ-шешәләрне дә шунда салалар. Халык өчен бу контейнерлар бик уңайлы булып чыкты, чөнки пластик күп урын ала һәм бик тиз җыела.

ҮЗГӘРЕШЛӘРГӘ – УҢАЙЛЫ РИТМДА

Чүп-чарны аерып җыеп ятсак, кухняның яртысы шуңа күмелеп бетәчәк, дигән фикер яшәп килә. Тормышта исә бу алай түгел. Иң мөһиме – җыйнаклык. Чүп чиләгенә өстәп, берничә пакет (макулатура һәм пластик өчен) алырга һәм эшкәртелә торган барлык калдыкларны шунда салырга була. Макулатура, тетрапак, алюминий банкалар һәм пластик шешәләр кысылган, изелгән хәлдә бик аз урын ала. Үзгәрешләргә таба уңайлы ритмда, кабаланмыйча, ашыкмыйча хәрәкәт итәргә генә кирәк.

Әйе, бүген сортларга аеру һәм бушату-төяү станцияләренең гамәлдә булганнары үзләре дә чүп-чардан икенчел чималны аера ала. Тик бөтен проблема шунда ки, барлык калдыклар да бер чиләккә эләгүгә, бу чималның сыйфаты сизелерлек кими. Азык-төлек калдыкларын шул ук макулатура белән катнаштыруга, кәгазь эшкәртү өчен яраксызга әверелә. Текстиль һәм пластик белән дә шул ук хәл. Нәтиҗәдә, икенчел чималның сыйфатын арттыру чыгымнары шактый күбәя. Ә чүпләрне аерып җыю вакытында чиста икенчел чимал барлыкка килә. Бөтен–

Фото: Александр Ефремов

Статистика буенча, һәрбер шартлы зат елына 350–500 кг чүп-чар «җитештерә».

эш безнең ике минут вакытыбызга һәм кухнядагы ике өстәмә пакетка гына килеп терәлә.

ЭКОЛОГИЯ ФӘНЕ БЕЛЕМ БИРҮДӘН БАШЛАНА

– Казанда бүген укучыларның экологик белемен арттыру юнәлешендә дә актив эш алып барыла, – дип сөйли Искәндәр Гыйниятуллин. – Шәһәрнең барлык мәктәпләрендә дә чүп-калдыкларны аерып җыю өчен – савытлар, ә мәктәп яны ишегалларында махсус контейнерлар урнаштырылган. Мәгариф идарәсе торак-коммуналь хуҗалык комитеты белән берлектә балаларга экологик тәрбия бирү программасын эшләде. Мәктәптән кайткач, балаларның: «Әти-әни, ә сез бер тонна кәгазь җитештерүгә 10 тонна су кирәклеген беләсезме? Әйдәгез, макулатура тапшыра башлыйк! Бер батарейка 20 квадрат метр җирне, 300–400 литр суны пычрата яки бер керпене үтерә икән. Аларны болай чүп чиләгенә генә ташларга ярамый», – дип әти-әниләрен өйрәтүе турында казанлылардан хәзер еш ишетәбез. Чүп-чарның тиешсез урынга эләккән файдалы нәрсәләр булуын һәм аларга тагын бер гомер бирергә мөмкин икәнен балаларның мәктәп яшеннән үк аңлый башлавы чын-чынлап сөендерә.

Моннан тыш, гомуми белем бирү учреждениеләре бүген батарейкалар җыюда да катнаша. «Duracell Россия» ҖЧҖ үз инициативасы белән республикада инде эштән чыккан химик ток чыганакларын җыюны оештырды. Моның өчен 2,5 меңнән күбрәк махсус савытлар куйды. Эшне Казаннан башладылар. Хәзер башкаланың барлык мәктәпләрендә дә шундый тартмалар тора. Үзләре җыя да, үзләренең эшкәртү предприятиесенә алып та китәләр. Батарейкаларны җыю өчен мондый тартмаларны Казанның эре сәүдәкүңел ачу үзәкләрендә дә күрергә мөмкин.

ШЕШӘ=ШЕШӘ+СУ

Казан Башкарма комитеты бүген икенчел чималны эшкәртү мәсьәләсендә гражданнарның теләсә нинди тәкъдимнәрен кабул итәргә әзер. Ә андый тәкъдимнәр, Искәндәр Әнвәрович сүзләренә караганда, шактый күп:

– Икенчел чимал җыю павильоннары челтәрен киңәйтүне дәвам иткән эшмәкәрләрдән безгә көн саен диярлек тәкъдимнәр килә. Аларга бу эш өчен муниципаль җирләрне бирү үтенече белән гаризалар юллый. Без моны гадиләштерелгән тәртиптә эшлибез. ПЭТ чимал җыю өчен челтәр контейнерлар урнаштыру турында мөрәҗәгатьләр күп. Икенчел чималны эшкәртү эшен башларга әзер эшмәкәрләрдән дә мөрәҗәгатьләр бар. Бизнесын ишегалларында ПЭТ-шешәләр җыюдан башлаган эшмәкәр күптән түгел безгә янә мөрәҗәгать итте. Хәзер ул пластикны эшкәртү системасы һәм аннан яңа шешәләр ясап, аларга су тутырып сатуны гамәлгә кертү турында бизнес-план әзерләгән. Кыскасы, проектлар күп. Һәм Башкарма комитетта шундый мөрәҗәгатьнең һәркайсы тикшерү уза. Әлбәттә, барысы да безнең көчтән килми, әмма нәтиҗәле башлангычларны хуплыйбыз һәм бик теләп хезмәттәшлек итәбез.

АЛДАН АЕРЫП ҖЫЮ – МӘСЬӘЛӘНЕ ЧИШҮГӘ АЧКЫЧ

Казанда калдыкларны аерып җыю эшен бүген республикада сортировкалауны мәҗбүри кертү турында анык канун булмау тоткарлый. Андый канун кабул ителү казанлыларга калдыкларны аерып җыю өчен түләүдә ташлама да кертергә мөмкинлек бирер иде. Килешәсездер, андый ташлама бер дә начар түгел.

Шулай да кешеләрдә яңа гадәт формалаштыру – зур эш. Әйе, без эшкәртергә өйрәнмәгән калдыклар да бар әле. Әмма бу – вакыт мәсьәләсе генә. Иң мөһиме, яхшы ният урнашып килә, ә чүп-чар – урыныннан кузгалып. Хәерле сәгатьтә! T



Рәсми расланган үрнәк нигезендә шәһәрдә 17 яңа контейнер мәйданчыгы төзелгән инде. Ел ахырына кадәр тагын 40 мәйданчык урнаштыру планлаштырыла, шул исәптән – чүп үткәргечләрдән баш тарткан 23 йорт өчен. Шулай итеп, аларның яңа мәйданчыкларның гомуми саны 57 гә җитәчәк.

КАЗАНДА ЕЛ САЕН 500 000 ТОННАДАН АРТЫК КӨНКҮРЕШ КАЛДЫКЛАРЫ «БАРЛЫККА КИЛӘ».

Шәһәр халкы 1,2 млн кешене тәшкил итә. Шулай итеп, һәр казанлы бер ел эчендә уртача 417 кг чүп-чар чыгарып ташлый дигән сүз. Дүрт кешедән торган гаилә ел саен ике тоннага якын чүп ташлый.

Чүп-чар нәрсәдән гыйбарәт:

- 30% пластик һәм полимерлар
- 25% азык калдыклары
- 20% кәгазь, катыргы, төрле полиграфия материаллары
- 8% текстиль һәм агач
- 6% себереп җыелган пычрак, тузан, грунт
- 5% пыяла банкалар һәм шешәләр
- 3% металл банкалар, капкачлар
- 3% башка калдыклар – резина, таш, керамика.

КАЗАН ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ЕЛ САЕН 4,6 МЕҢ ТОННА КАБАТ ЭШКӘРТҮ ӨЧЕН ИКЕНЧЕЛ ЧИМАЛ ҖЫЕЛА, ШУЛАРДАН:



1 175 тонна ПЭТ-шешәләр
Җыелган пластикны чыгару өчен 490 тимер юл вагоны яки 30 товар поезды кирәк. Җыелмаган очракта, бөтен пластик Түбән Кабан күле өслеген, Болакны һәм Черек күл бакчасын бер катлам итеп каплап бетерә алган булыр иде.



2 771 тонна макулатура
Икенчел куллануга җибәрелгән макулатура 47 107 агачны саклый. Бүген Казанның төзекләндерелгән 15 иң зур паркында һәм скверында якынча шул хәтле сандагы агач үсә.

300 тонна пыяла шешә
Халыктан җыелган, 0,5 л сыйдырышлы шешәләрне тезеп чыксак, сызыкның озынлыгы 52 км 702 метр булыр иде. Бу исә – Казаннан Яшел Үзәнгә кадәр ара дигән сүз.

www.protatarstan.ru
Поиск...
Подписка!
РУС | ТАТ
ТАТАРСТАН
Иҗтимагый-сәяси басма
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Яңа Кырлайда кунакта
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
07 июля 2019
05 июля 2019
Тынгы бирмәс хәтер уты
Түбән Урас: рәхим итегез яки гаҗәса өтиськом*!
Казан ханлыгының олуг сәете
Алтын Урданы ни өчен
Кыл өстендәге гомер:
Ул балаларга Россияне ача
Реклама 16+

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Печән базарында **НИЛӘР** сатыла

Татарстанда дзюдо фәлсәфәсен **НИЧЕК** өйрәнәләр

Редакция кухнясы **НИЛӘР** белән сыйлый

ҺӘР ЗАМАННЫҢ – ҮЗ ПЕЧӘН БАЗАРЫ

Бер ун ел элек: «Печән базарына бардым әле», – дисәләр, гаҗәпләнер идек. Бүген исә аңлашыла: сату-алулы, җырлы-биюле, мастер-класслы, гомумән, татарларны бергә җыючы бер зур чара ул. Быел да, җиденче ел рәттән, башкалабыз үзәгендә, Печән базары узды.



Автор:
Руфия Фазылова

ФЕСТИВАЛЬ, МАРКЕТ?!

Печән базарын Габдулла Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасы аша күзалларга була. XVIII гасырдан алып 1932 елга кадәр сәүдә, җәмәгать һәм мәдәният үзәге булган ул. Гел шул урында җыелгач, халык хәтта шундагы мәчетне дә Печән базары мәчете (хәзерге Нурулла мәчете) дип йөртә башлаган. Яңалык түгел, һөнәрчелек, сәүдә итү эше – татарның канында. Моның белән бергә безнең халык мәгърифәтне үстерүне дә алгы планга куйган. Печән базары менә шуларның барысын да берләштергән.

Нәкъ 81 елдан соң, ягъни 2013 елда, Печән базары яңадан торгызыла. Эшнең башында Бөтендөнья татар яшьләре форумы торганлыгын да әйтергә кирәк. Ул вакытта, Тукайның вафатына 100 ел тулу уңаеннан, базар апрель аенда Париж Коммунасы урамында үтә. Шагыйрьләр өчен ачык микрофон, зур булмаган милли әйберләр сату ярминкәсе оештырыла. Аннан соң Печән базары елдан-ел зурая бара. Катнашучылар саны да артканнан-арта.

Яңадан Тукайга әйләнеп кайтсак, әлбәттә, ул замандагы кебек бүген базарда печән, салам сатмыйлар. Иярле атлар да юк. Биредә сату-алудан тыш, төрле остаханәләр, мастер-класслар оештырылган. Шулай ук төрле темага караган дискуссияләрдә катнашып, тыңлап була. Чара күбрәк Европа илләрендә уза торган фестивальләрне хәтерләтте. Оештыручылар үзара сөйләшкәндә дә аны «фестиваль», «маркет» дип атый. Ягъни XX йөз башындагы базар түгел бу.

Быел Печән базары башка еллардан үзгәрәк булды. Беренчедән, ул ике көн барды. Икенчедән, урынын алыштырды. Моңа кадәр Черек күлдә, Мәрҗани, Насыйри урамнарында уза иде. Бу юлы халык Камал театры каршына җыелды.

Фото: Мингалиева Саидә

– Быел үзгәрешләр шактый, – дип сөйләде чараны оештыручыларның берсе Ләйлә Гайнуллина. – Мәйданчыклар, остаханәләр күбрәк, каллиграфиягә зур урын бирелде. Узган ел остаханәләр, нигездә, балалар өчен иде, быел исә зурлар өчен дә бар. Алар рәсем, каллиграфия, төрле кул эшләре белән шөгыльләнә ала. Камал театры каршындагы мәйдан зуррак булганлыктан, быел сәүдә рәтләре дә озынрак, остаханәләргә дә урын иркенрәк…

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: ризык сата торган һәр эшмәкәрнең лицензиясе бар. Һәм биредә сәүдә итү өчен алдан теркәлеп, документларны тәртипкә китерергә кирәк. Шулай булмаса, сата алмыйсың. Мин рәтләр буйлап йөргәндә, ирле-хатынлы Гәрәевлар белән таныштым. Кукмарадан килгәннәр икән. «Кечкенә банкаларга бал тутырып килдек, сатуга куеп булмасмы икән?» – дип оештыручыларны эзләп йөриләр иде. Тик кукмаралылар теләгенә ирешә алмады: урын юк, диделәр. Яңа танышларым: «Киләсе елга алдан теркәләрбез», – дип кайтып китте.

МАТУРЛЫКТАН КҮЗЛӘР КАМАША

Узган саннарыбызның берсендә милли дизайнерлар турында язган идек. Бизәнү әйберләре, милли бизәкле сөлгеләр, аш-су кирәк-яраклары, күн сумкалар… Ниләр генә юк хәзер. Печән базарына баргач, фантазиянең чиксез икәнлегенә тагын бер кат инанасың. Татарча, гарәпчә язулы, матур теләкле тәбрикләмәләр, шамаилләр, милли бизәкле ручкаларга кадәр бар. (Хатын-кызлар өчен күлмәк, бизәнү әйберләре турында әйтеп тә тормыйм.)

Кеше күп булган җиргә, нәрсә эшлиләр икән монда, дип барып карасам, күн браслетларга исемнәрен яздырып алалар икән. Оста – Марат Бәйрәмгулов, аның белән дә тиз генә сөйләшеп алдым.

– Бу кадәр чират җыелыр дип уйламаган идем, – диде Марат. – Кемдер бүләккә дип якыннарының исемен яздыра, үзләренә эшләтүчеләр дә күп. Кыскасы, сорау зур.

– Исемнәрне менә шулай чокып ясау белән ничек шөгыльләнә башладың? – дим.

– Бу мин уйлап тапкан яңалык түгел. Әби-бабайлар да шулай эшләгән. Элеккеге эшләр кире кайта бит хәзер…

Алкаларның, калфакларның, брошьларның күплегеннән, төрлелегеннән күзләр камаша. Беренчесе – агачтан, пыяладан, тукымадан, чын ташлардан… ниндие генә юк. Бәяләре дә сыйфатына карап – 100 сумнан алып 2 меңгә кадәр.

САН:

Камал театры каршында узган Печән базарына ике көн эчендә

20 000

кеше килгән.

Калфаклар да ничек эшләнүгә карап: гади чигелешләре 400, 500 сумнан башлап, энҗе, сөйлән белән эшләнгәннәре 2 мең сумга кадәр. Брошкалар да, сыйфатына карап, 100 сумнан башлана.

«Дөньядагы иң яхшы әтигә!», «Никах – бәхет капкасы», «Аллаһка шөкер!», «Улыгыз туу белән!», «Син – күземнең нуры!» дигән язулы тәбрикләмәләр, милли бизәкле конвертлар, рамкага куелган рәхмәт сүзләре – мондый матур сүзләр йөрәккә май булып ята. Кара, заманча да, милли дә, иң мөһиме – татарча да, дип уйлап куйдым. Боларның барысын да Айгөл Шәрәфиева уйлап тапкан икән. Белеме буенча филолог булса да, берничә ел элек дизайнерлык эше белән шөгыльләнә башлаган.

– Бер-бер артлы балалар тапкач, эшкә чыга алмадым, – диде Айгөл. – Өйдә утырганда, акмаса да, тамар, дип, башта визиткалар ясадым. Әле тагын ирем белән фотога төшерү белән дә мавыгабыз. Кыскасы, иҗади гаилә без. Эзләнә торгач, менә шундый тәбрикләмәләр ясап карау идеясе туды. Хәзер интернет бар бит, безнең кебек кешеләр өчен сәүдә мәйданы ул. Сатып алучыларыбыз күбәйде.

Айгөл Печән базарында беренче тапкыр катнаша икән. Әлеге чараның узасын интернеттан укып белгән. Оештыручылар белән элемтәгә кереп, теркәлү узган. Монда килүенә чиксез куанган ул.

– Печән базарын оештыручыларга зур рәхмәт! – диде Айгөл. – Безнең кебек эш башлаучыларга үз-үзеңне таныту өчен бер дигән форсат бу! Тәбрикләмәләрне яратып алалар. Визиткаларыбызны да таратабыз. Бу чарадан соң безнең продукцияне сатып алучылар тагын да артыр, дип уйлыйм.

ТАМАК ЯГЫН КАЙГЫРТЫП

Халыкка нәрсә кызыклырак икән дип, чатырлар, иҗат мәйданнары тирәсен махсус карап йөрдем. Ни хикмәт, бөтен җирдә кеше. Берәүләр, азык-төлек чатырлары янында сыр, казылык сатып ала, пылау, баллы ризыклар белән сыйлана. Икенчеләре дискуссия барган мәйданда бәхәс тыңлый. Өченчеләре мастер-классларда (печенье кебек ризыкларны бизәү, чәчәкләр ясау, сәйлән белән эшләү) катнаша.

Ризык сата торган чатырлар янына баргач, өстәлгә тезелгән сырларга күзем төште. Барысының да каплары вакуумлы. Исемнәре дә кызык: «Янмас», «Каймаклы», «Татлы»...

Татарча исем кушып сыр ясаучылар Түбән Кама районының Борок авылыннан килгәннәр. Ирле-хатынлы Чулпан һәм Рамил Миңнебаевлар. Сыр ясау белән икенче ел шөгыльләнәләр икән.

– Печән базарында сыр сатучылар булмаган икән әле, – диде Чулпан. – Без – беренче! Оештыручылар шулай диде.

– Сезне бирегә махсус чакырдылармы? – дим.

– Юк, үзем интернеттан күреп, теркәлү уздым. Казанда беренче тапкыр гына сәүдә итмибез. Эшкуарлар өчен уздырыла торган төрле чараларда катнашканыбыз бар. Бүгенге чара исә үзгә – миллилек сизелеп тора. Сатып алучылар да гел татарча сөйләшә.

– Сырларыгыз ничә төрле?

– 20 гә якын төре бар. Халык, нигездә, бер ун төрлесен яратып ала.

– Бөтен исемнәре дә татарчамы? – дим.

– Әйе, күбрәк татарча. Безнең продукция хәләл һәм натураль.

– Эшчеләрегез бармы?

– Юк, ирем белән икәү генә эшлибез. Сөтне авыл фермасыннан сатып алабыз.

– Сыр ясарга кайдан өйрәндегез? – дим.

– Интернеттан. Башта үзебез өчен эшләп карадык. Әйбәт килеп чыкты. Аннан Мәскәүгә курсларга барып укып кайттым. Шулай ук Кырымга барып, сыр ясаучылар белән аралашып, эш тәҗрибәләрен өйрәндем.

Миңнебаевлар тагын виноград үстерә, аннан шәраб тә ясый икән. Күп итеп кош-корт асрыйлар, инкубаторлары да бар. Төрле өлкәдә үзләрен сынап карый торгач, сыр ясауга тукталганнар. Сырны сыер, кәҗә сөтеннән ясыйлар. Лимон, борыч кушылган, татлы сырлар – җаның нәрсә тели, шундые бар.

– Әлеге кадәр заказларны телефон, интернет аркылы алдык. Тиздән Түбән Камада кибет ачарга җыенабыз, – диде хуҗабикә.

Тагын бер сөйкемле кыз белән таныштым. Алсу Ишмөхәммәтова тортлар, чизкейк, капкейк, төрле десертлар белән сату итә. Яшь ана берничә ел инде шулай



өендә тәм-томнар пешерә икән. Печән базарына алдагы елларда да сәүдә итәргә килгән булган. Быелгысы турында менә нинди фикерләр әйтте:

– Камал театры каршында урын күбрәк, монысы иң зур плюсы дип саныйм. Быел реклама яхшы булдымы, кеше күбрәк.

– Сату барамы соң? – дим.

– Бара, Аллага шөкер. Кичә алып чыккан барлык тәм-томнар да сатылып бетте. Бүген дә күп калмады инде.

АКЫЛЛЫ БУЛЫЙМ, ДИСӘҢ...

Печән базарында кесә калынлыгы буенча гына түгел, кызыксыну буенча да үзеңә туры килгән өлкәне табарга була иде. Мисал өчен, экскурсияләр. Ике көндә дә булды алар. Аерма шунда гына: төрле кешеләр төрле сәгатьтә алып барды. Лилия Кәлимуллина рус телендә үткәрсә, калган экскурсоводлар – музыкант Рәдиф Кашапов, Татарстан дәүләт архивы җитәкчесе урынбасары Илдар Шәфыйков, артист Фәнис Җиһанша, Ислам мәдәнияте музее директоры Илнур Низамиев фәкать татар телендә генә алып бардылар. Экскурсияләр бушка иде, шулай да теләгән кеше күпмедер сумма аерым әрҗәгә салды. «Бу хәйрия чарасы булып барачак», – дип аңлаттылар. Маршрут – Камал театры яныннан башлап, Мәрҗани, Каюм Насыйри урамнары аша Тукай урамына кадәр. Экскурсоводлар шул чорга караган утарлар, йортлар турында сөйләп барды. Иске Казан тарихы белән таныш булмаган һәркем өчен бик файдалы иде ул.

Шулай ук бәхәс, фикер алышу мәйданнары да эшләде. Биредә тарихчылар, урбанистика белгечләре, лингвист, социолог, психолог, сәясәт белгечләре төрле темаларга лекцияләр укыды. Соңыннан фикер алышулар узды. Шәхсән миңа журналист Ян Гордеевның Куйбышев сусаклыгычы төзү нәтиҗәсендә су астында калган татар авыллары язмышы кызык тоелды.

– Бу безнең халык өчен зур фаҗига булган. Кешеләрнең психологиясенә, киләчәгенә нык тәэсир иткән, – диде ул.

Яшьләр «Нигә татар егетләре өйләнми» дигән дискуссия мәйданын да яратты. Ара-тирә бәхәскә дә керделәр, елмайдылар, кул чаптылар. Ислам фәне белгече Резеда Сафиуллинаның бер фикере истә калды:

– Безнең балалар ярата белми, – диде ул. – Чөнки алар үзләре ярату күрмәгән. Совет чорында әти-әни көн-төн эштә булган, баласына вакыты калмаган. Ана назын, мәхәббәтен күрмәгән шул балалар бүген гаилә корды. Алар ничек ярата алсын? Безгә яратырга өйрәнергә кирәк...

«Гыйлем» проекты, «Ихсан» үзеге дә үзенең мәйданчыкларын булдырган иде. Биредә ата-аналар, балалар фән дөньясы белән таныштылар.

Күптән түгел эшли башлаган Татар китабы йорты да үзенең мәйданчыгын булдырган иде. Башта танылган шәхесләр җыелган халыкка татар классик әсәрләрен укыды, аннан «Әбүгалисина» интеллектуаль квизы үтте. Ә кичке якта яшь шагыйрьләр шигъри баттл, ярыш оештырды. Шунда ук китап сату да оештырганнар иде.

– Татар китабын алмыйлар, дияргә яраталар. Әмма тәҗрибә күрсәтте: китапка сорау бик зур, – диде Татар китабы йортының җитәкчесе, шагыйрә Луиза Янсуар.

...Бер заман бардым
Печән базарына,
Шунда мин таптым азык язарыма.
Иртә берлән кайнамакта бу базар,
Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр

– дип язган Тукаебыз. Печән базарыннан кайткач, сүзне кайдан башларга белми тордым. Андагы лекция укучы, мөгаллим, артист, сәүдәгәр – һәркайсы белән рәхәтләнеп милләт, яшәебез турында сөйләшеп була. Мондый аудиторияне көн дә күрә алмыйсың. Шуңа да базарга килгән кешеләр үзара рәхәтләнеп татарча аралашты, таныштылар. Йомгаклап бер фикерне җиткерәсем килә: Печән базары елга ике көн генә түгел, ешрак оештырылсын иде. Күпләр менә шушы фикерне әйтте.

БУ КЫЗЫК:

Печән базарына үз кружкасы белән килгән кешегә кофе алганда ташлама ясалды. Бу кулланылган пластик савыт-саба өелеп тормасын өчен шулай алдан уйланылган булган. Шул рәвешле, Печән базарында экология проблемасы да искә төшерелде.

МАКСАТ – ТӘНҺӘМ РУХ КАМИЛЛЕГЕ

«Кемнәндер яхшырак булырсыңмы син, юкмы – анысы мөһим түгел. Кичәгегә караганда бүген яхшырак булырсыңмы – менә шунысы мөһим», – дигән кайчандыр дзюдога нигез салучы Дзигоро Кано. 60 елдан артык инде Татарстан спортчылары даими рәвештә тәннәрен генә түгел, ә рухларын да камилләштерә барып, остаз юлыннан китә.

ТАТАРСТАНДА – ЯПОНИЯ УТРАУЧЫГЫ

10 августта Россиядә Физкультурачылар көнен билгеләп үттеләр. Татарстан дзюдоистларының төп базасы – яңартылган «Батыр» спорт комплексына сугылып чыгарга менә дигән форсат булды.

Бинаның заманча дизайнында бамбук кәүсәләре шәйләнә. Бу әлеге спорт төренең туган ягы Япония булуына ишарә. Спорт комплексының тышкы ягы гына түгел, эче дә күз явын ала. Зал идәннәре резин амортизаторлар белән җиһазландырылган – тренировкалар вакытында имгәнү очракларын киметү өчен шулай эшләнгән. Кардиозал тулысынча җиһазландырылган, бинаның инфраструктурасы яңартылган. Картинаны заманча яктырту җиһазлары тулыландыра, алар өч режимда эшли: тренировкалар, ярышлар һәм видео төшерү өчен. Иркен заллар буйлап экскурсияне Татарстан Республикасының Дзюдо федерациясе башкарма директоры Александр Тарасов үткәрә.

– Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм ТР Спорт министрлыгы ярдәме белән 2019 ел Татарстан дзюдосы өчен истәлекле булды, – дип сөйли Александр Иванович. – Капиталь ремонттан соң, «Батыр» ачылды. Хәзерге көндә ул тренировкалар өчен Россиядәге иң яхшы спорт комплексы.

Тренировкалар залының түшәме астында – Россия Президентының көндәшен күтәреп салган мизгел сурәтләнгән. Мәгълүм булганча, Владимир Путин әлеге спорт төрен аеруча ярата. Президент үзе әлегә «Батыр»да булырга өлгермәгән, шулай да аның турында ишетеп белә һәм Татарстанда дзюдоны популярлаштыру эшенә югары бәя бирә.

ҖИҢӘР ӨЧЕН БИРЕЛҮ

– Хәзерге вакытта Татарстанда дзюдо белән 5,5 меңнән артыграк кеше шөгыльләнә. Без 6 яшьтән кабул итәбез, балаларны, классларга берләштереп, дзюдо турындагы иң кызыклы мәгълүматларны җиткерәбез. Уен рәвешендә алар үзләренең беренче мәтәлчекләрен ата, тәннәрен язу күнекмәләрен башкара, һәм без аларга иң гади хәрәкәтләрне күрсәтәбез. Шуннан соң нәниләр башлангыч әзерлек төркеменә күчә. Сүз уңаеннан, спортның бу төре белән теләсә кайсы яшьтән шөгыльләнә башларга була. 40та да, 50дә дә, 60та да бу организмга файда гына китерә, кардиотренировкалар сәламәтлек өчен файдалы, ә спарринг тизлекне, җитезлекне, көчне һәм, әлбәттә, стратегик фикерләүне яхшырта, – дип аңлата Александр Тарасов.

Көнчыгышның барлык хәрби сәнгать төрләрендәге кебек үк, дзюдо нигезендә дә тирән фәлсәфә ята. Аңа нигез салучы Дзигаро Кано шулай бервакыт кышкы бакчада кар явуны күзәтеп торган. Шунда бер агачның каты ботагы кар авырлыгыннан сынып төшкән, ә нечкә һәм сыгылмалысы, бөгелеп, өстенә өелгән карны коеп төшергән. Дзюдоның асылы – «җиңәр өчен бирелү». Һөҗүм итүченең энергиясен файдаланып, ыргылыш ясарга, авырттыргыч яки тынсыз калдыру алымын кулланырга була.

– Татарстан дзюдосы максатларының берсе – тәнне генә түгел, рухны да камилләштерү. Дзюдо федерациясендә без кеше үзен масштаблы спорт җәмгыятьчелегенең бер өлеше итеп тойсын өчен барлык шартларны да тудырабыз. Даими күнекмәләр һәм әлеге көрәшнең фәлсәфәсе

Фотолар Татарстан Республикасының Дзюдо федерациясеннән алынды

Реклама

аша безнең спортчылар физик яктан да, акыл ягыннан да үсешкә ирешә, – дип билгеләде республиканың Дзюдо федерациясе башкарма директоры.

РОССИЯ МИЛЛИ ҖЫЕЛМА КОМАНДАСЫНЫҢ РЕЗЕРВЫ

Шунысы кызык: безнең дзюдо көрәшчеләре татар милли көрәшеннән нәрсә дә булса аламы икән?

– Әзерлек барышында без башка көрәшләрнең күп элементларын кулланабыз. Дзюдодагы кебек үк, милли көрәштә дә күп кенә матур алымнар бар, мәсәлән, бөгелүле ыргылыш, – дип җавап бирә әңгәмәдәшебез.

РФ Хөкүмәте карарына ярашлы, милли җыелма команданың резервын әзерләү өчен Татарстан дзюдосы төп спорт төре булып тора. «Батыр» спорт мәктәбе эшләгән вакытта гына да Олимпия уеннарында катнашучы, 2013 елгы Бөтендөнья җәйге Универсиадасының ике призеры, халыкара классы 8 спорт мастеры, 70тән артык СССР һәм Россия спорт мастеры әзерләнгән.

2018 елның гыйнварыннан Татарстан җыелма командасын Россиянең атказанган тренеры Владимир Драчко җитәкли. Элегрәк юниорлар җыелма командасының тренерлар штабы башлыгы Лондон-2012 Олимпия уеннары чемпионнарын әзерләүгә өлеш керткән.

– Бер елдан артыграк элек без Владимир Яковлевич белән бергәләп бирегә Мәскәүдән килдек. Һәм шуны әйтәсем килә: Казан Россиянең спорт башкаласы дигән исемгә тулаем лаек. Физик культураның популяр булуы дөнья аренасына чыгардай көчле спортчыларны күреп алырга һәм әзерләргә мөмкинлек бирә, – ди Александр Тарасов.

НӘТИҖӘЛӘР КҮРСӘТӘБЕЗ

Заманча спорт комплексында шөгыльләнү өчен барлык шартлар да тудырылган. Нәтиҗәләр дә – шуннан. Хәзерге вакытта»Батыр»-да тәрбияләнгән 7 спортчы Россия җыелма командасы составында Татарстан данын яклый. Аэлина Мәҗитова быел көз Польшада юниорлар арасында узачак Европа кубогына әзерләнә. Ә Тулада Европа кубогында алтын яулаган Александра Заһирова Казахстанга дөнья беренчелегенә җыена. Шулай ук республиканың җыелма командасына резерв әзерләүче булып Яр Чаллының «Олимп» мәктәбе тора. 2018 елның октябрендә Канкунда дзюдо буенча Гран-прида алтын алган Нияз Билаловка зур өметләр баглыйлар. Хәзерге вакытта ул Россиянең Олимпиада җыелма командасы составына сайлау узарга әзерләнә.

– Тренерлар составын әзерләүгә аерым игътибар бирәбез. Тренерның бурычларына күнекмәләр планын эшләү белән техниканы булдырудан тыш, стартка әзерлек, ярдәм итү, киеренкелекне йомшарту, спортчының сәламәтлеген кайгырту да керә, – дип аңлата Александр Тарасов.

Республика милли җыелма командасын спортчылар әзерләүгә Константин Толмачев («Олимп», Яр Чаллы), Елена Антонова, Марат Гәрәев («Батыр», Казан), Рәфис Әхмәтгәрәев («Оргсинтез» Олимпиада резервы училищесы, Казан), Диана Фазылова, Зөлфия Гарипова, Анжелика Ходайбиргәнова («Ак Барс» көрәш мәктәбе, Казан), Дмитрий Баранов («Тасма», Казан) һәм башкалар зур өлеш кертә. Татарстанда дзюдоны үстерүгә генераль спонсорлар – «Татнефть» ААҖ генераль директоры Наил Мәганов, КАМАЗның генераль директоры Сергей Когогин һәм «Крэт» компанияләр холдингы зур өлеш кертә.

ЧИКЛӘРНЕ УЗГАН ДЗЮДО

Җәй көннәрендә яшь дзюдоистларны залларда күрү мөмкин түгел диярлек – күбесе Россия буенча уку-күнекмәләр алу җыеннарында, Татарстанның спорт лагерьларында. Сентябрьдә аларны Владивостокта Дзигаро Кано исемендәге халыкара турнир һәм Алматада дөньякүләм шәхси команда беренчелеге көтә. Үсмерләр һәм юниорлар командалары өчен көзен Идел буе федераль округы беренчелегенә сайлаулар башлана, аның нәтиҗәләре буенча Россия беренчелеге командасы формалаштырыла. Ел саен гомуми белем бирү мәктәпләре базасында дзюдо секцияләре ачыла. Узган ел Нурлатта беренче дзюдо бүлекчәсе ачылган, ә Буа белән Бөгелмәдәге спорт мәктәпләренең дзюдо бүлекчәләре яңа заллы булган. Лаеш районының Каип авылында шулай ук яңа спорт комплексы төзелгән, анда районның балалар дзюдо үзәге эшен башлаячак. «Чикләрсез дзюдо» программасы буенча да эш бара, Татарстанда ишетү сәләте чикләнгән спортчылар өчен дәресләр үткәрелә. Республиканың Дзюдо федерациясе чакыруы буенча көз көне Казанга дүрт тапкыр Европа һәм дөнья чемпионы Хазрет Тлецери киләчәк. Алга таба Япониядән килгән һәм дөньякүләм танылган дзюдо осталары белән очрашулар, мастер-класслар көтә.

Журнал
ТАТАРСТАН
Обращение
к народам всего мира
Татарстан
ТАТАРСТАН
ЖИЗНЬ
и история РКП(б)

САРЫК ИТЕН – ЯШЕЛЧӘ БЕЛӘН

Корбан бәйрәме узып китте. Нәкъ шушы чорда, елга бер тапкыр булса да, бик күпләр сарык итен авыз итеп карый. Ни өчендер соңгы елларда сарык ите ашамый башладык. Югыйсә, әле егерме ел элек кенә ул иң киң кулланыла торган ризыкларның берсе иде, бигрәк тә җәй айларында. Күпләр сарык итенең аерым бер тәмен яратмый.

Шулай да ел әйләнәсе диярлек аны әле ашаучылар да бар икән. Шуларның берсе – «Ярдәм» милли ислам хәйрия Фондының укыту-тернәкләндерү үзәге директоры Мәликә ханым Гыйльметдинова гаиләсе. Ул сарык итеннәнниләр генә әзерләми! Шул исәптән долма да.

ДИЕТИК РИЗЫК

Мәликә ханымны республикада күпләр белә. Хәер, Россиянең башка шәһәрләрендә яшәүчеләр өчен дә бу исем яхшы таныш. Мәликә ханым – Россиядә беренчеләрдән булып күрү, ишетү буенча инвалидларны ислам нигезләренә өйрәтү һәм Коръән укыту өчен методика төзегән мөгаллимә. Моннан тыш, 10 авыру баланы тәрбиягә алып, аларны аякка бастыручы (әле дә дәвам итә) ана да.

– Безнең балаларның һәркайсында берничә төрле диагноз, – диде Мәликә ханым. – Аларга теләсә нәрсә ашатып та булмый, шуның өчен нигездә диетик ризыкларга өстенлек бирәбез. Ә сарык ите диетик ризыклар исемлегенә керә. Тиз пешә, әллә ничә төрле итеп әзерләп була. Долманы аеруча яраталар...

Мәликә ханым балалары белән Теләче районының Иске Җөри авылында яши. «Ярдәм» фонды балалар өчен зур йорт сатып алган. Йокы, уен бүлмәләре, уен мәйданчыгы, ванна, мунча – барысы да махсус балалар өчен дип эшләнгән. Ун баланы үстерешергә матди яктан «Ярдәм» фонды да ярдәм итә. Мәликә ханым ул малай-кызларны рәсми рәвештә опекунлыкка алган ана. Сырхауханәләргә йөртү, табиблар белән сөйләшү, балаларны төрле күңел ачу үзәкләренә алып бару, укыту, өй эшләрен тикшерү – барысы да аның җилкәсендә.

Шулай сөйләшә-сөйләшә эшкә керештек. Унике бала анасы (үзенең ике баласы зур инде, гаиләләре бар) иң беренче булып ит турады. Хәер, турады дип әйтү

Автор:
Руфия Фазылова

Фото: Александр Ефремов

МӘЛИКӘ ХАНЫМ ГЫЙЛЬМЕТДИНОВАДАН ДОЛМА РЕЦЕПТЫ:

Кирәк булачак (8 порция өчен):

1. Сарык ите – 1 кг
2. Бәрәңге – 0,8 кг
3. Кызыл борыч – 1 баш
4. Сары (яшел) борыч – 1 баш
5. Кишер – 2 баш
6. Помидор – 2 баш
7. Кәбестә – 0,3 кг
8. Баклажан – 1 баш
9. Сельдерей – берничә кузак
10. Укроп – бер бәйләм
11. Петрушка – берничә сабак
12. Борыч – чама белән
13. Тоз – чама белән
14. Паприка (төелгән кызыл борыч) – тәменчә
15. Зәйтүн мае – 100 г

бик үк дөрес булмас, бүлгәләде. Зур кисәкләргә аптырап карап торуымны күргәч:

– Ит пешкәч кечерәя ул, әле изелеп тә китә, – диде Мәликә ханым.

Шуннан хуҗабикә зур кәстрүл төбенә зәйтүн мае агызды. Бактың исә, алар көнбагыш маен бөтенләй кулланмый икән. Гомумән, гаилә дөрес тукланырга тырыша.

Итне кәстрүл төбенә тезгәннән соң, хуҗабикә аның өстенә тоз, борыч сипте.

– Ит өстенә яшелчәләрне катлы-катлы итеп куячакбыз. Һәр катка тоз, борыч сибәргә кирәк, – дип аңлатты.

Шуннан әрчелгән бәрәңгеләрне икегә ярып, ит өстенә куйды. Аннан чират кишергә җитте. Мәликә апа уртача зурлыктагы кишерне биш-алты кисәккә бүлде дә кәстрүлгә салды.

– Ваграк итсәң ярамыймы? – дигән булам.

– Кирәк түгел. Ул бит пешә. Долманы бер әзерләп караган кеше гел пешерәчәк. Ни өчен дигәндә, ит, яшелчәләрне турар өчен унунбиш минут вакыт җитә. Шуның белән шул. Кәстрүл капкачын томалап куясың да сәгать ярым пешерәсең. Бутыйсы да юк, ачып та карарга кирәкми. Рәхәтләнеп башка эшләрне карый торасың. Мин танышларыма да әйтәм: гаиләле кеше өчен долмадан да җиңелрәк, тизрәк, тәмлерәк әзерләнә торган ризык юк. Бөтен кешегә дә җитә, иң мөһиме – туклыклы.

Мәликә ханым яшелчәләре шулай бер-бер артлы – баклажан, борыч, помидор – турап, кәстрүлгә озата барды. Иң өске катка кәбестә тезде. Тоз-борыч сипкәннән соң, яшел укроп, петрушка кебек тәмләткечләрне турап салды. Аларны да зур итеп бүлгәләде.

– Булды, капкачны ябабыз да үзе пешеп утырачак, – диде хуҗабикә. – Шунысын да әйтим, плитәгә куйгач та, ун минут тирәсе каты утта пешереп алабыз. Шул рәвешле ит кызып өлгерә, ә аннан соң инде талгын утка куябыз.

– Су салырга кирәкмиме? – дим.

– Юк, кирәк түгел. Ит яшелчәләр согында пешә. Шуңа күрә ул файдалы да, тәмле дә була, менә күрерсез.

ҖИСЕМЕНӘ ТУРЫ КИТЕРЕП...

Мәликә ханымны унбиш еллап беләм. Әле ул вакытта «Сөләйман» мәчете Левченко бистәсендә урнашкан иде. Сукыр, чукрак балалар өчен дәресләр, лагерьлар оештырып йөрде. Бер сөйләшүдә ул: «Эх, шәһәр үзәгендә мөмкинлеге чикле кешеләр өчен бер тернәкләндерү үзәге булдырасы иде», – диде. Шул вакыт кем уйлаган теләкләр якын арада кабул булыр дип.

– 2013 елда, «Ярдәм» мәчете ачылганда, укыту-тернәкләндерү үзәге болай ук киң массаны колачлар дип уйламаган да идек, – ди Мәликә ханым. – Эш тәҗрибәм сукырлар белән башланган иде. Тик тора-бара шуңа инандым: башка төр гарипләр дә ярдәмгә мохтаҗ. Яшьме ул, картмы, алар өйдә бикләнеп ятарга мәҗбүр.

«Ярдәм» фондының укыту-тернәкләндерү үзәге авыруларны дингә, милләткә бүлми. Монда төрле кешеләр килә. Бер айлык дәвалау курсларын узып, аралашып, бер ай яшәп китәләр. Үзәк хәтта юл бәясен дә үзе түли. Исеменнән күренгәнчә, монда ярдәмгә мохтаҗ булган һәркемгә ярдәм итәләр. Ел саен алар меңәрләгән мохтаҗ гаиләләргә, ятимнәргә, студентларга хәйрия кысаларында азык-төлек, кием-салым бирәләр.

– Сез бит башта сукырлар белән эшли башлагансыз. Ни өчен нәкъ менә бу төр авырулар игътибарыгызны җәлеп итте? – дим.

– Сукыр бала тәрбияләүче бер ана мөрәҗәгать итте. Сау балалар дин сабакларын теләсә кайда өйрәнә ала, менә безнең кебекләргә андый мөмкинлекләр юк, диде. Шуннан эзләнә башладым. Баксаң, Луи Брайль системасы буенча Татарстанда беркайда да Коръән укырга өйрәтмиләр. Алынырга булдым.

Санаулы вакыт эчендә күрмәүчеләр белән эшләү методикасы яза ул. Аны соңрак китап итеп бастыралар. Шуннан ишетмәүчеләр белән дә эшли башлыйлар. Бүген «Ярдәм» мәчетендә хәтта җомга вәгазе дә сурдотәрҗемә (ишетмәүчеләр өчен ишарәләр теле) белән укыла. Шул исәптән Гает намазлары да. Чукраклар имам сөйләгән вәгазьне дә тулысынча аңлап кайтып китә икән.

«Ярдәм» мәчете кебек иман йортлары республикада, хәер, Рос-

1. Итне кисәбез!

2. Турыйбыз!

3. Кишерне бүләбез!

4. Борычны кисәбез!

5. Турыйбыз!

6. Помидорны кисәбез!

7. Турыйбыз!

8. Бүләбез!

9. Ваклыйбыз!

10. Май агызабыз!

сиядә дә бүтән юк. Монда сау-сәламәт кешеләр белән бергә коляскада йөрүче, сукырлар, гомумән, бүтән авыруларны да күрергә була. Алар үзара аралаша, хәл белешә. Һәм бу шулкадәр табигый ки, әйтерсең бөтен җирдә шундый хәл күзәтелә. Әйе, «Ярдәм» мәчете гыйбадәт урыны гына түгел, үзенә бер социаль үзәкне яки шифаханәне хәтерләтә ул. Аерма шунда гына: биредә тән белән җанны да дәвалыйлар.

«СИН ДӨНЬЯДАГЫ ИҢ ӘЙБӘТ ӘНИ!»

Әйткәнемчә, Мәликә ханым ун баланы тәрбиягә алган. Аларның икесе бүген инде гаилә корган. Калган сигезе үзе белән. Беренче карашка ялгыз хатын-кызның (Мәликә ханымның ире вафат). бу адымы кемнәргәдер бик үк аңлашылып бетмәскә дә мөмкин. Гомер көзенә кергәндә, балаларың, оныкларың белән нигә рәхәтләнеп яшәмәскә?

– Бу ашыгыч карар түгел иде, – ди Мәликә ханым. – Еллар буе үземне, якыннарымны әзерләдем. Яшермим, тәрбиягә бала алырга телим дигәч, үз балаларым каршы килде. Тынычлыгың кадерле түгелме, диделәр. Аннан соң, минем өчен моның ни дәрәҗәдә мөһим икәнен аңладылар. Оныклар белән тәрбиягә алган ул-кызларым бер яшьтәрәк. Алар бик тату, бер-берсенә «апам», «абыем», «энем», «сеңлем»диеп эндәшә.

– Ә ни өчен авыру балаларны алдыгыз? – дим.

– Сау балаларны болай да алалар, ә авырулар бирәүгә дә кирәкми. Хәйрия чаралары белән еш йөргәч, андый нарасыйларның ничек яшәгәнен күрә идем. Әйе, аларны анда ашаталар, киендерәләр. Тик адәм баласына бу гына җитми бит. Наз турында гына әйтмим, аерым мөнәсәбәт күрсәтүне күздә тотам. Мин, мәсәлән, бер балама 20 тапкыр операция ясаттырдым. Безгә килгәндә ун баламның һәркайсы, ничә яшьтә булуына карамастан, памперста иде. Ягъни йомышларын да мөстәкыйль үти алмыйлар. Кашык тотып ашау турында әйтеп тә тормыйм. Менә шул балалар бүген үзләре ашый, эчә, йөгереп йөри, мәктәптә укый, концертларда чыгыш ясый. Наз, мәхәббәт, әлбәттә, медицина ярдәме белән аларны аякка бастырдык. Тормышымдагы иң зур нәтиҗә – шушы балаларым.

Мәликә ханым тәрбиягә алган балаларның барысы да гомуми белем бирү мәктәбендә укымый, махсус мәктәпкә укучылары да бар. Акыл үсешләре, мөмкинлекләре төрле икән.

– Иң мөһиме – алар барысы да мөстәкыйль, – ди Мәликә ханым. – Беренче чиратта мин шуның өчен куанам. Тагын әле аларны фатирлы да итәсебез килә. Гаилә корган Настя белән Фәриткә торак мәсьәләсе артыннан йөрибез. Тәрбиягә бала алгач, шуңа инандым: ятим балаларга закон буенча тиешле фатирны алу өчен «җиде кат сират күпере кичәргә» кирәк икән.

Җыясы документларның очы-кырые юк.

– Инде ул-кызларыгыз үсеп килә, тагын тәрбиягә бала алырга теләк юкмы? – дим.

– Башта андый теләк бар иде, ләкин туктап калдым, – ди Мәликә ханым. – Унсигез яшькә кадәр балаларны үстердең дә, чыгарып җибәрдең түгел бит. Алар һаман да минем балалар. Мәсәлән, Настя белән Фәрит гаилә корды, ләкин атна саен бездә алар. Шулар өчен кайгырып, борчылып торам. Иң кечкенә улыма сигез яшь. Әле аларны аякка бастырасы, кеше итәсе бар. Әлбәттә, башка балаларга дә ярдәм итәсем килә, тик бө-

11. Тезәбез!

12. Тоз сибәбез!

13. Борыч өстибез!

14. Бәрәңге куябыз!

15. Кишер салабыз!

16. Борыч куябыз!

17. Тезәбез!

18. Помидор өстибез!

19. Кәбестә тезәбез!

20. Тутырабыз!

«Ярдәм» милли ислам хәйрия Фондының укытутернәкләндерү үзәге директоры Мәликә ханым Гыйльметдиновада кунакта.

тен ятим авыру баланы мин генә тәрбияли алмыйм. Ни әйтсәң дә, яшь тә бара бит.

Мәликә ханым телефонын ачып, балалары вотсап аша аңа язган хәбәрләрне укыды. (Үзең тудырган балалардан да мондый сүзләр ишетмисең, билләһи). «Әнием, мин синең йөзеңә беркайчан кызыллык китермәм, менә күрерсең...», «Әнием, син дөньядагы иң матур, иң әйбәт Әни...», «Әни, мин сине беркайчан ташламаячакмым...», «Әни, минем өчен синең бәхетле булганыңны күрүдән дә зуррак шатлык юк...»

Күзгә яшьләр тулды. Мәликә ханым да нечкәреп китте.

– Мине сагынып көтеп торалар, өйгә һәрчак ашыгып кайтам, – диде ана кеше.

«КӨНГӘ 1500 КЕШЕ АШАТТЫК»

Мәликә ханым малай-кызлары турында шулкадәр яратып сөйли ки, икенче темага сорау бирсәң дә, сүз үзеннән-үзе шул балаларга барып тоташа. Шулай да «Ярдәм» фондының укытутернәкләндерү үзәге директоры белән бүтән тема турында да сөйләштек.

«Ярдәм» мәчете инде ничәнче ел ураза тотучыларга көн саен ифтар уздыра. Махсус чатырларга 1 мең 200 кешелек табын әзерлиләр. (Кайчагында күбрәк тә була). Моннан тыш, сәхәргә дә 300ләп кеше килә. Тагын Корбан бәйрәмендә өч көн дәвамында корбан ашы үткәрәләр.

– Быел да Корбан ашына халык күп килде, – диде Мәликә ханым. – Хәтта зур чират барлыкка килде. Әлбәттә, кайнар аш бөтен кешегә җитте. Тагын волонтерларыбыз 2 меңнән артык кешегә корбан ите таратты.

– 2 мең кеше – мохтаҗлармы? – дим.

– Әйе, мохтаҗлар күбрәк тә була. Ел дәвамында исемлек төзибез. Анда гарипләр, ялгыз әбибабайлар, күп балалы гаиләләр, гомумән, авыр хәлгә калган гражданнар керә. Бу исемлек елдан-ел зурая.

– Ә шуның кадәр корбан ите каян аласыз? – дим.

– Җыела. Беренчедән, «Ярдәм» мәчете каршында корбанга дигән малларны сату, шартына туры китереп сую оештырылган. Корбан чалдырган кешеләр, шәригать кануннары буенча, өчтән берен мохтаҗларга бирә бит. Менә шул өлешне күбрәк мәчеттә калдыралар. Кайберәүләр, малны суеп, дога кылганнан соң, итне бөтенебелән мохтаҗларга таратырга кушып китә. Икенчедән, өч көн дәвамында, һәр теләгән кеше, чалдырган корбан итен мәчеткә алып килә. Без аларны аннан соң менә шулай исемлек буенча таратабыз.

Безнең дә корбан итеннән әзерләгән долмабыз әзер булды. Мәликә ханым кәстрүлнең капкачын ачып җибәрде. Шундый хуш ис таралды ки, язып аңлата торган гына түгел. Карап торырга да бик аппетитлы күренә, шулпасы да бар. Хуҗабикә долманы башта зур бер тәлинкәгә салды.

– Яшелчәләрен бутап тормыйм, аерым-аерым торгач матуррак, – диде.

Шуннан Мәликә ханым барыбызны да табын янына чакырды. Авыз итәбез... Теленңне йотмалы! Һич арттыру түгел. Аеруча сарык итен яраттык. Ул изелеп, бик тәмле пешкән. (Бер ят тәм дә юк.)

– Моннан соң сарыкны фәкать шулай әзерли башларга кирәк, – диештек.

– Учакта да пешерергә була, ялкында тагын да тәмлерәк килеп чыга ул, – дип елмайды Мәликә ханым. ■

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Рәссам Харис Якуповны шәкертләре **НИЧЕК** искә ала

50 нче еллар Казаны **НИЧЕК** яши

Бүләкләр каһарманнарны **НИЧЕК** эзләп таба

«Икенче Баку» **НИЧЕК** төзелә

Шәһәрләр һәм авыллар **НИЧЕК** су төбенә киткән

КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ

ҮЗ АРАБЫЗДАН ЧЫККАН МАҺИР РӘССАМ

Габдулла Тукай үз заманында татарның профессиональ рәссамнары барлыкка киләчәгенә өметләнеп: «Өмет юк түгел әле... Үз арабыздан да маһир рәссамнар чыгар», – дигән. Тукай ялгышмаган. Революциядән соң татарның горурлыгы булган рәссам-осталар үсеп чыга. Шундыйларның берсе – СССРның халык рәссамы, Россия сәнгать академиясе академигы, милли республикалар һәм төбәкләр арасыннан «РСФСРның халык рәссамы» исеменә беренче лаек булган кеше, Бөек Ватан сугышы ветераны Харис Якупов.

Автор:
Мөршидә Кыямова

НИ УЛ ИЛҺАМ?

1919 елның салкын декабрендә Казан каласында гади эшче гаиләсендә туган Харис Якупов кечкенәдән милли тәрбия алып үсә. Бала чагыннан ук рәсем ясарга хирыс була. Татар мәктәбен тәмамлый, уку дәверендә татар әдипләре җитәкләгән әдәбият түгәрәкләренә йөри, сүз аһәңен, тел тәмен тоярга өйрәнә. Казан сәнгать училищесында белемен чарлый. Ә аннан соң армия хезмәте Бөек Ватан сугышына ялганып китә... Хәер, монысы турында соңрак.

«Рәссам илһамланучы түгел, ә илһамландыручы». Харис Якуповның хөрмәт иткән рәссамы Сальвадор Далиның әлеге фикере белән күпләр килешмәскә дә мөмкин. Ничек инде рәссам үзе илһамланмыйча гына башкаларны сокландырырлык әсәрләр иҗат итә ала ди? Харис Якуповны да замандашлары, укучылары киң эрудицияле, гүзәллекне тоючы, тирән белемле, акыллы шәхес, тырышлык үрнәге иде, дип бәяли.

Харис Якупов 25 ел дәвамында Татарстан рәссамнар берлеген җитәкли, республика рәссамнарын үстерүгә, аларның иҗатын дөньяга танытуга зур көч куя, шул ук вакытта үзе дә күләмле әсәрләре белән таныла.

Харис Якупов рәислек иткәндә Татарстанның тасвири сәнгате СССР һәм дөнья күләмендә танылуга ирешә. Аның актив җитәкчелегендә Татарстанда безнең горурлыгыбыз булган рәсем сәнгате фонды төзелә.





Рауза Солтанова, сәнгать фәннәре докторы:

– Харис Якупов – тасвири сәнгать өлкәсендә абруйлы шәхес. XX гасырда Николай Фешин, Павел Беньков, Бакый Урманче кебек үк дан казанган рәссам. Сугыштан соңгы чорда иҗат иткән тематик хезмәтләре, тарихи һәм портрет жанрындагы картиналары белән ул дөнья күләмендә танылды.

Рәссам XX гасырда Татарстанның үткәнен, тарихи вакыйгаларын күләмле әсәрләрдә чагылдырды. 1960 нчы елларда эшчеләр, колхозчыларны оста итеп сурәтли алды. Колхозларның күтәрелеш темасына алынып, гади колхозчыларны каһарман дәрәҗәсенә күтәрде. Питрәч районының Шәле авылына багышланган сериясен генә алыйк, анда чын хезмәт, җир кешеләренә мәдхия җырлана.

1970 нче еллардагы картиналары нефтьчеләрне, «КАМАЗ» төзүчеләрне сурәтләде. Катлаулы, күп фигуралы композицияләре һәм зур форматларда иҗат итүе белән рәссам тамашачыны таң калдырды. Аның картиналарына конструктив төгәллек, бөтенлек, монументальлек хас. Геройларны ачык, калку итеп (кино сәнгатенә хас булганча зур планда) күрсәтү сәләтенә ия иҗатчы ул. Шул ук вакытта лирик рухтагы, дөнья сурәтен тарайтыбрак, психологик яктан нечкә итеп, детальләп язган картиналары да җитәрлек.

Педагог буларак та танылды, яшьләргә карата да игътибарлы, ихтирамлы булды Якупов. Казан сәнгать мәктәбендә укытты. СССР сәнгать академиясенең Казандагы остаханәсен җитәкләде. Укучылары шактый күп. Мәскәүдә кандидатлык диссертациямне яклаганда, ул, чын күңелдән сөенеп, миңа үзенең җылы бәяләмәсен язып биргән иде.

«БЕЗДӘ МОНДЫЙ РӘССАМНАР ЮК!»

Олы юбилей елында, аның да ноябрь аенда, республиканың Сынлы сәнгать дәүләт музее Халыкара VI Казан сәнгать белеме укуларын, Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясен оештыра. Анда реалистик сәнгать теориясе һәм тарихы, аның хәзерге торышы һәм үсеш перспективалары мәсьәләсе каралачак. Әлеге укулар СССРның халык рәссамы, Россия сәнгать академиясенең хакыйкый әгъзасы Харис Якуповның 100 еллыгына багышлана.

2007 елда Казан халыкара мөселман киносы фестиваленә дөньякүләм танылган француз актеры Катрин Денёв килгән

иде. Катрин ханым сәнгать галереясын карарга теләк белдергәч, аны Харис Якуповның шәхси күргәзмәсенә алып баралар. Франция кунагы татар сәнгатькәренең әсәрләрен күргәч, сокланыуын яшерми: «Бездә мондый дәрәҗәдәге рәссамнар юк!..» – дип куя. Шундый бәягә лаек булу үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Милләттәшебезнең дөньякүләм дәрәҗәдә иҗат иткәнлегенә саллы дәлил бу. Тирәнрәк уйлап карасаң, гомумкешелек кыйммәтләре дигән олы төшенчә үз асылыңны, халкыңны, аның аерым затларын яратудан, телеңне, сәнгатеңне, моңыңны сөюдән оеша, шуннан башлана бит...

ПРОФЕССИОНАЛЬ ОСТАЛЫК ДӘРЕСЕ

Рәссам, Бакый Урманче исемендәге премия лауреаты **Булат Гыйльванов** та кайчандыр Харис агада белем алган, иҗади осталыгын камилләштергән.

– Харис Габдрахманович Якуповны мин бала чагымнан ук беләм. Минем «Татарстан рәссамнары» дигән җыентыгым бар иде. Анда Харис Габдрахмановичның картиналары да. Алар башкаларныкыннан аерылып тора. Аларда төгәллек, ачыклык бар. Әле дә хәтерлим: рәсем сәнгате мәктәбендә, башка рәссамнар белән бергә, республикабызның әйдәп баручы рәссамы буларак, Харис Якупов та безне котларга килә икән, дигән хәбәр таралды. Мин аны күреп, төсмерләп алдым. Ул безне котлады, аның белән якыннан аралашырмын, бергә эшләрбез, ул минем остазым булыр, дип уйламаган идем дә әле ул вакытта.

Петербургның сәнгать академиясен тәмамлагач, Татарстанга кайттым. Берникадәр вакыттан соң стажер сыйфатында Казандагы рәссамнар академиясенең иҗат остаханәсенә чакырдылар. Аның җитәкчесе Харис Якупов иде.

Мин аңардан күп нәрсәгә өйрәндем. Ул гыйлемле кеше иде. Остазыбыз булса да, укучылары белән үзен коллега кебек тотты. Безгә күбрәк төпле киңәшләрен бирә, фикер алышабыз. Эскизлар дәрәҗәсендәге композицион табышларга карата аңлаешлы һәм төгәл итеп үз фикерен аңлата белә иде. Композиция җәһәтеннән, болар безгә яхшы мәктәп булды. «Рәссам үз һөнәренең остасы булырга тиеш. Шуннан соң гына иҗади эзләнүләр белән шөгыльләнергә мөмкин». Бу – остазыбызның бер сабагы. Бездә һәрвакыт иҗади мохит хөкем сөрде. Педагог буларак, ул безгә картинаның никадәр катлаулы организм икәнен төшендерде. Ният туу, башкару, картинадагы элементларның үзара бәйләнеше, образларның гәүдәләнүе, боларның барысына да ничек ирешергә? Остаханәбездә нәкъ менә шундый мәсьәләләрне күтәрә идек. Бай тормыш тәҗрибәсенә ия шәхес белән аралашу без, яшьләрнең, тормышында, һичшиксез, үз эзен калдырды.

Бүген еш кына рәссамнардан Харис Якуповның авангардчыларны өнәп бетермәвен ишетергә туры килә. Үз вакытында, реализм тарафдары буларак, республиканың милли сәнгать үсешенә комачаулады, «неформаль» юнәлешләрне, эзләнүләрне тыя иде, диләр. Бу, чыннан да, шулай идеме дигән соравымны әңгәмәдәшем рәссам Булат Гыйльвановка та бирдем.

– Шәхсән мин бу сыйфатын тоймадым. Аның мөнәсәбәте һәркемгә бертөрле иде. Реализм хезмәтләренә дә, формаль булмаган юнәлештәгеләргә дә ул бертигез карады. Һәммәсен рәсем тексты итеп бәяләде. Тасвири сәнгать, композиция төшенчәсен яхшы аңлаучы, сыйфатлы, төпле мәктәпкә ия шәхес иде бит ул. Тагын бер сокландырган сыйфаты – олы яшенә җиткәч тә, Харис Якупов тере зиһенле булды, хәтере бик яхшы иде. Рәссамнар тормышыннан төрле хәлләрне искә төшереп, кызыклы вакыйгалар сөйләп ала. Бөтенесенең исем-фамилиясен генә түгел, хәтта әтиләренең исемнәрен дә хәтерли. Аның бу сыйфатына бик соклана идем. Һәрвакыт рәссамнарга тулы исемнәре белән атап эндәште. Бу минем өчен профессиональ осталык дәресе генә түгел, ә тормыш мәктәбе дә булды. Минем рәссам буларак формалашуымда аның роле зур. Безнең милли сәнгатьне Харис ага үз иҗаты белән генә түгел, ә оештыру сәләте ярдәмендә дә югары күтәрде. Рәсем сәнгате фонды, сәнгать академиясе оешу аның фидакарьлеге, тырышлыгы белән бәйле.

ИХТЫЯР КӨЧЕ

Татарстан Рәссамнар берлеге рәисе **Зөфәр Гыймаев** та рәссамны олы ихтирам белән искә ала:

– Харис Габдрахманович белән мин сәнгать училищесында таныштым. Аның улы Фәрит белән бергә укыйбыз, ә ул безнең училищега килә иде. Фәриткә әйткән сүзләре истә калган: «Һәр эшне ахырына кадәр, җиренә җиткереп башкарырга кирәк. Ихтыяр көченә ия булу сорала. Ярты юлда тукталырга ярамый». Шул чакта ул мине үрнәк итеп китерде.

Аннан соң без Фәрит белән бергә Ленинград сәнгать академиясенә укырга кердек. Харис Якупов Казанда иҗат остаханәсе ачкач, без әлеге студиянең берен-

че шәкертләре булдык. Аның иҗат остаханәсендә өч ел эшләдек. Аннан Репин дачасында да күп иҗат иттек.

Гомеренең соңгы елларында ул миңа үзенең китабын бүләк итте. Зур рәссам булып истә калды. Ул тырышып йөрмәсә, Казанда зур остаханә дә булмас иде. Татарстан рәссамнары аңа моның өчен бик рәхмәтле.

МАТУРЛЫКНЫ КҮРСЕННӘР ӨЧЕН...

Харис Якупов турында материал әзерләгәндә, олуг рәссамның улы, шулай ук танылган рәссам Фәрит Якупов белән дә очраштык. Легендар әтисе турындагы җылы истәлекләрен бик җанланып сөйләде ул.

– Безнең әти гади хезмәт кешеләрен хөрмәт итә иде. Ул, беренчеләрдән булып, аларны үз картиналарында чагылдырган рәссам. Питрәч районы Шәле авылы хезмәтчәннәренә багышланган зур картиналарын халык аеруча үз күрде, яратып кабул итте. Шулай бервакыт әти Шәле авылы янында сазлыклы күлне ясап утыра икән. Ә аның янынннан иртәнге савымга сыер савучылар узып бара: «Харис абый, ничек инде син бу сазлыкны ясыйсың? Монда ис килә бит, озынборыннар мыжлый». Әти аларга карап елмайган гына. Ә беркавым вакыттан соң, сыер савучы апалар өйләренә кайтканда, этюдны күреп ах иткәннәр. «Аһ, нинди матур! Кызганыч, бу матурлыкны монда яшәүчеләр күрми!» – дип көрсенеп куйган алар. Шулвакыт әти үз хезмәтен хатынкызларның берсенә бүләк иткән. Картинаны күреп, авыл кешеләре сокланган, нинди матур табигать кочагында яшәүләрен аңлаган.

Күренекле рәссамнар турында китаплар, аларның иҗатларын чагылдырган альбомнар дөнья күрә башлагач, әти аларга акчасын җәлләмәде. Тиз арада аның гаҗәеп бай китапханәсе барлыкка килде. 1960 нчы еллардан башлап, гомеренең соңгы көннәренә кадәр импрессионистлар, постимпрессионистлар Моне, Дега, Ренуар, Гоген аның яраткан рәссамнары булды. Соңрак әле ул Пьер Боннарны үз итә башлады. Кыйммәт бәягә аның альбомнарын сатып алды. Ни хикмәттер, француз милләтеннән булган Пьер Боннарны ул «татар рәссамы» дип атады.

25 ел Рәссамнар берлеге рәисе булып тору СССРда рекордлы күрсәткеч иде. Ул төркемнәргә бүленүдән бик курыкты. «Төркемчелек» башланса, берлекнең дә, иҗатның да үләчәген белә иде.

Безнең нәсел рәссамнарга бик бай, берсендә санап утырган идем: 16 кеше исәпләп чыгардым. Шәхсән мин үзем бала чакта дөньяда рәссам һөнәре генә бар, дип белә идем. Урамда күргән һәр кеше өенә кайта да рәсем ясый башлый кебек тоела иде миңа.

Әти үзенә дә, башкаларга карата да үтә таләпчән булды. «Минем Шәлеләрем» картинасын ясаганы хәтердә. Әлеге автобиографик картина Третьяков галереясына эләкте. Шулай бервакыт унарлаган этюд эшләрен каршысына куеп, киндергә масштаблы әсәрен яза. Әни тыныч кына төшке аш әзерли... Шулвакыт әти ярсып пумаласын идәнгә ташлады, урындыкка утырды да, битен учлары белән каплап, авырсынып кына:

– Миннән рәссам чыкмас... – диде.

Без әни белән бер-беребезгә сәерсенеп карап куйдык. Бу вакытта бит инде ул СССРның халык рәссамы, дәүләтнең өч премиясе лауреаты һәм башка күп кенә дәрәҗәле бүләкләргә ия иде!

Тирә-юньдәгеләргә Харис Якупов иҗатта һәрчак уңыш казанып, иминлектә генә яшәүче кебек күренгәндер. Әмма рәссамның ара-тирә үз-үзен «ашавын», үтә таләпчәнлеге нәтиҗәсендә ярсуларын якын кешеләре генә белгән. Һәр иҗатчының илһамчысы булган кебек, Харис Якуповның да бердәнбер мәхәббәтен, тугры дусты, киңәшчесе, сердәше, өч улының әнисен беләбез. Ул да – татар дөньясында танылган кылкаләм остасы, Татарстанның халык рәссамы Рушания Якупова.

ӘДӘБИЯТКА МӘХӘББӘТ

Харис Якупов әдәбият өлкәсенә дә зур өлеш кертте. Бер татар рәссамының да алай ике юнәлештә эшләгәне билгеле түгел. Күпсанлы очерклары, истәлекләре, сәяхәтнамәләре, юлъязмалары бар – ул төрле жанрларда яза. Заманында Һади Такташ, Гадел Кутуй белән аралашуы, әдәби түгәрәкләргә йөрүе, татар мәктәбендә белем алуы аны публицист итеп үстергән. Үз чорының һәйбәт документалисты дәрәҗәсенә күтәрә.

«Әдәбият белән рәсем сәнгате арасында нык бәйләнеш бар, – ди Харис Якупов. – Бәлкем миңа да «китап җене» кагылгандыр. Шулай икәнен яхшы беләм, чөнки еш кына үземнең дә кулга каләм аласым килә. Картиналарда гына бөтен сөйләргә теләгән әйберне, тормыш хәлләрен күрсәтеп бетереп булмый бит. Мәсәлән, сәнгать, чит илләргә барып күргәннәр һәм Ватан сугышы турында. «Фронт язмалары» буенча Казандагы оптика-механика заводының әдәбият сөючеләре белән очрашканда миңа бирәү: «Сез нәрсәне өстен күрәсез, китапнымы, әллә картинанымы?» – дип сорау бирде. «Әгәр дә әсәр югары дәрәҗәдә иҗат ителгән булса, минем өчен – барыбер. Ләкин рәссамнар әсәрендә образлар бик аңлаешлы булып күз алдында калалар. Ә әдәбиятта һәм музыкада алай ук түгел, шуңа күрә рәсем сәнгате үзенчә өстенлек алып тора», – дидем мин аңар».

Истәлекләрен ул татар телендә дә бәян итеп калдырган. Фәрит ага миңа бүләк иткән «Рәсем – мәхәббәтем минем» китабында кылкаләм остасы үз чорының даһиларын тасвирлый, алар турындагы истәлекләре белән уртаклаша. Үзенең татар сәнгатенә, әдәбиятына мөнәсәбәтен дә белдерә.

«Рәссам белән тамашачы» арасында мөнәсәбәт һәр гасырда катлаулы булган. Күпләр аңламыйлар, бәлки аңлыйсылары да килмидер: чын рәсем сәнгате – ул бөек һәм катлаулы фән. Математика, физика, астрономия, космонавтика һ.б. шикелле үк... Һәрбер профессиональ рәссам кебек, миңа да шушы хакыйкатькә төшенергә һәм үземә дөрес сукмак сайларга кирәк иде. Мин яшьтән үк зур сәнгать белән очрашырга юл эзләдем. Рәсем сәнгате дөньясында авырлыклар да, шатлыклар да күп булды. Иҗат өлкәсендә уңышка ирешү өчен зур тазалык, түземлек һәм теләк бик тә кирәк...», – ди автор.

Тагын бер танылган рәссамыбыз Лотфулла Фәттахов Якуповлар гаиләсендә 13 яшьтән яши, бергә укыйлар, тора-бара ул аларның кияве дә булып куя. Болардан тыш, ике рәссамны иҗади хезмәттәшлек тә бәйләп тора. Аларның бергәләп язган «Татарстан АССРны төзү декретына кул кую» картинасы өчен СССРның Дәүләт бүләге тапшырыла. Харис Якупов күп кенә данлыклы шәхесләр белән аралаша, алар турында яза, истәлекләр калдыра, мөхтәрәм чордашлары белән хезмәттәшлек итә.

«Рәсем – мәхәббәтем минем» китабындагы хатирәләрне дәвам итик:

«Бервакыт университет янында Нәҗип Җиһанов белән очрашабыз. Ерактан ук миңа: «Беләсеңме, Муса турында Мәскәүдән яңа хәбәрләр килә, ул хыянәтче булмаган, мин ул гайбәткә һич вакытта ышанмый идем, чөнки Мусаны яхшы беләм. Киресенчә, ул татар әсирләре белән берлектә фашистларга каршы көрәшкән һәм аның башын кисканнәр... Әйдә, син Мусага багышланган картина яза башла һәм берәр скульпторга аның сынын ясарга киңәш ит, ә мин опера яза башлыйм», – диде Нәҗип Гаязович. Бу сөйләшү 1952 еллар башында барды бугай. Ике елдан соң «Хөкем алдыннан» дигән зур әсәремне мин эшләп бетердем һәм күргәзмәләрдә күрсәттем».

Кылкаләм остасының «Хөкем алдыннан», «Иреккә очу», «Бәби туе», «Иделдә яз», «Татарстан алтыны», «Габдулла Тукайга истәлек», «Күчле кешеләр» һ.б. әсәрләре Татарстан рәсем сәнгатенең алтын фондын тәшкил итә.

1976 елда Харис Якуповның «Чаллы чибәрләре (КамАЗ)», шулай ук «Алдынгы терлекчекөтүчеләр Н.Җиһаншин һәм Г. Шакировлар» исемле картиналары Россия Федерациясенең И.Репин исемендәге премиясенә лаек дип табыла.

Харис Якуповның әсәрләре бүгенге көндә Мәскәүнең Третьяков галереясында һәм Шәрекъ халыклары сәнгате дәүләт музеенда, Татарстан республикасының музей һәм галереяларында, АКШ, Бөекбритания, Франция, Италиядә саклана. Татарстан Республикасы Дәүләт сынлы сәнгать музее Харис Якупов әсәрләренең иң зур коллекциясенә ия, аның эшләре Казан шәһәренең «Хәзинә» милли сәнгать галереясында да даими күргәзмәдә тора. Кызганыч ки, 2005 елда Татарстанның беренче Президенты карары белән ачылып, 6 залга урнаштырылган галерея, бүгенге көндә инде бер залда гына калган...

Харис Якупов иҗаты энциклопедияләрдә һәм белешмәлекләрдә, Татарстан һәм Россия сынлы сәнгате буенча фундаменталь хезмәтләрдә, монографик альбомнарда һәм каталогларда яктыртылган. Харис Якупның «Фронттагы зарисовкалар», «Рәссам булу җиңелме?», «Рәссамның Европа тирәли сәяхәте» дигән китаплары да останың гаҗәеп бай, киңкырлы иҗат дөньясын тулыландыра һәм ачып бирә.

Ветеран рәссам республика сәнгатен үстерү җәһәтеннән гаҗәеп күп масштаблы гамәлләр башкарды. Нәкъ менә аның энергиясе һәм абруе нәтиҗәсендә, аның турыдан-туры катнашында Казанның иң матур биналарының берсен – генерал А. Г. Сандецкийның элеккеге резиденциясен Хөкүмәт Карары белән ТАССР сынлы сәнгать музее итеп ачу мәсьәләсе хәл ителә. Рәсем ясаучылар, графиклар һәм скульпторлар өчен остаханәләр ачыла, республика рәссамнар берлегенең күргәзмә залы төзелә. Алда билгеләп узганча, илдә, Казанда беренчеләрдән булып СССР сәнгать академиясенең иҗади остаханәсе оешты-

рыла, аны да озак еллар Харис Якупов үзе җитәкли.

Рәссам үзенең тормыш һәм иҗат кредосы принципларына гомере буена тугрылык саклый. Бөек остага искиткеч тыйнаклык, күңел күтәренкелеге, кешеләргә карата җылы, игътибарлы мөнәсәбәт хас иде, ди замандашлары.

«Мин сәнгать училищесының бишенче курсыннан армиягә киттем. Кайтырга бер ел калгач, Бөек Ватан сугышы башланды. Ул чакта без геройлар идек. Кыр сумкасын, альбомны, карандашларны, көндәлек дәфтәр әзерләп куйдым. Немецлар мөмкинчелек бирсә, ясарга дип инде. Сугышта бик зур әйберләр ясап булмый. Альбомнар күбрәк тә буласы иде дә, немец танкистлары безнең машинаны яндырдылар. Шунда бер альбом янды», – ди рәссам үзенең истәлекләрендә.

«КҮҢЕЛЕМДӘ САКЛАНЫРЛАР»

Харис Якупов – 1943 елның октябреннән 1 нче Украина фронтында. Сугышчан хезмәтләре өчен медале, Кызыл Йолдыз һәм II дәрәҗә Ватан сугышы орденнары белән бүләкләнә ул.

Сугыштан соң ун ел узгач, үзенең «Фронт зарисовкалары. Рәссам язмалары»нда болай дип язган:

«Мин дүрт ел сугыштым. Минем рәсемле өч поход альбомым сакланып калды. Алар фронт тормышының авыр шартларында, сугыш арасында, су басу көннәрендә, нигездә, артиллерия снаряд гильзасыннан ясалган коптилка янына утырып, «үзебез өчен» башкарылган. Әлеге рәсемнәр сугыш юлларында күргән һәм үткәннәрнең ачык дәлиле булып тора. Аларда минем дусларым вә кардәшләрем, алар һәрвакыт минем күңелемдә сакланырлар».

Ул бөтен җирдә һәм даими рәвештә рәсем ясаган. Күпчелек рәсемнәре гади карандаш, сирәк очракта тушь, күмер, кайчагында акварель белән башкарылган. Шулай итеп, кәгазьдә вакытлар узгач булачак картиналар өчен әзер эскизлар, композицияләр барлыкка килә башлый.

Ә Бөек Ватан сугышы чорын искә алып, кылкаләм остасы үзе түбәндәгеләрне сөйли:

«Кызганычка каршы, көрәштәшләремнең күпчелек портретын саклап кала алмадым. Баштарак, сержант сугышта кирәксез эш белән шөгыльләнә, димәсеннәр өчен, мин аларга рәссам икәнлегемне әйтмәдем дә. Әмма ялгышканмын. Сурәт төшерү минем профессиям икәне мәгълүм булуга, алар арасында абруем артты. Иптәшләрем үз портретларын ясавымны үтенә башладылар, чөнки безнең арада фотограф юк иде. Минем сурәтләрне почта аша өйләренә җибәрәләр иде. Мин, аларның портретларын бик теләп ясадым, чөнки фронт язмышының үзгәреп торуын белә идем. Кешене очратасың, аның белән сөйләшәсең һәм бүтән беркайчан да күрешмәскә дә мөмкинсең: синең белән дә, аның белән дә төрле хәлләр була ала. Шулай ук мин кешеләргә яхшылык эшли алуыма да куана идем».

Яу кырында да рәссам егетнең кулыннан карандашы төшмәгәнгә тагын бер дәлил:

«Сугышчылар һәм авыл халкы сөйләгәннәр буенча тематик композицияләр ясый идем: «Тел» алу», «Разведчиклар һөҗүме», «Тупчылар», «Политзанятиеләр», «Әсирләрне алып баралар», «Ату», «Мародёрлар», «Качаклар һәм танклар», шулай ук «Мәскәүне саклап калыйк!», «Тылга солдат рәхмәте», «Үч ал! » һ.б. плакатлар өчен эскизлар. Кыскасы, иң кыен шартларда һәм хәлләрдә иҗат итәргә туры килде, рәссам хезмәте шуны таләп итә иде».

Гомеренең соңгы елларында, күзләре күрми башлау сәбәпле, Харис Якупов картиналар иҗат итә алмый. Әмма нык рухлы рәссам төшенкелеккә бирелми. Бер көнен дә диванда ятып уздырмый. Ул тулысынча үзен «Жить так» дигән чираттагы китабына

багышлый. Хатыны яки улына әйтеп торып истәлекләр яздыра. «Китабымны күрә алмам, ләкин яңа китапны кулга алгач, типография исен тоярмын», – дип хыяллана, әмма хыялы тормышка ашмый. Зур өметләр баглап әзерләнгән китап бүгенге көнгәчә, типографиядә үз көнен көтеп ята. Әдип-рәссамның 100 еллыгына әлеге хезмәт дөнья күрер, дип ышаныйк.

Бөек кылкаләм остасының түбәндәге сүзләреннән аның яшәеш кредосын, иҗат мәсләген ачык тоемларга мөмкин:

«Рәсем сәнгатендә – живописьтә иң югары һәм ясар өчен иң авыр әсәр булып тематик картина исәпләнә. Әдәбиятта – роман, поэма; музыкада – опера, симфония шикелле. Хезмәтемнең төп өлеше итеп шушы кыен юлга басканыма һич тә үкенмим... Һәр кеше яшьтән үк ил күләмендә барган таләпләр белән тәрбияләнә, формалаша. Һәр шәхес тә, үз заманы баласы буларак, үзе яшәгән чорны сурәтли. Мин дә, күпчелек Татарстан рәссамнары кебек үк, иҗатымны республикабыз кешеләренә, аларның сугышчан һәм эшчән тормышына багышладым...»



ГАДЕЛЛЕК ТАНТАНАСЫ

Әгәр исән булса, бу елның 25 июлендә данлыклы партизан һәм мактаулы игенче Зәки Җәләлиев 100 яшьлек юбилеен билгеләп үтәр иде. Республикабызның Кукмара районындагы Битләнгер (халык телендәгечә әйтсәк – Аксыбы) авылында гомер кичергән әлеге мөхтәрәм ил агасының күргән-кичергәннәре гыйбрәтле бер тарихи кыйссалык.

БЕЗНЕҢ КАҺАРМАННАР

Заманында, Кукмара районында чыгучы «Хезмәт даны» газетасы редакциясендә эшләгән чагымда, миңа әлеге ветеран яшәгән Түбән Өскебаш авыл җирлегендә байтак булырга туры килде. Тукаебыз әйтмешли, «язарыма азык»ны еш таптым биредә. Шушы төбәктә туып-үскән иң яшь Советлар Союзы Герое, гвардия полковнигы, Мәскәүдә үткән Җиңү парадларында кат-кат катнашкан Сабир Әхтәмов, атаклы шахтер – Социалистик Хезмәт Герое Әхмәтша Җиһаншин, моннан 75 ел элек, 1944 елның 27 июлендә, Карелия җирендә дошман амбразурасын күкрәге белән каплаган укчы взвод командиры, шагыйрь җанлы лейтенант Нух Идрисов, 1944 елның 25 августында Германиянең Плетцензее төрмәсендә фашистлар тарафыннан җәзалап үтерелгән җәлилче-кормашчы Әхәт Атнашев, исән калган легионер-макизар, Франциядә фашистларга каршы көрәштә үзен нык танытып, әлеге илнең югары дәрәҗәле бүләкләренә лаек булган Рушад Хисаметдинов һәм башка күренекле шәхесләр байтак кына әдәби-документаль әсәрләремнең төп каһарманнарына әверелде.

Инде Зәки ага Җәләлиевка килсәк, элек дошман кулында тоткынлыкта булуы сәбәпле, һаман да «Ватан сугышы ветераны» таныклыгын һәм тиешле пенсиясен дә ала алмаган әлеге 70 яшьлек аксакалга гаделлекне торгызуда ярдәм итүне үзебезнең уртак төп бурычыбыз, намус эшебез, диеп санадык. Бу эшне без авыл эзтабарлары белән берлектә алып бардык.

АТЛАР КОТКАРА

Туган авылында игенче гаиләсендә туып-үсеп, Ворошилов исемендәге күмәк хуҗалыкта ат караучы булып эшләгән Зәки Җәләлиев 1939 елда Кызыл Армия сафларына алына һәм 136 нчы укчы дивизиянең 541 нче укчы полкында хезмәт итә башлый. Биредә дә полкның атларын карауны аңа ышанып тапшыралар. Бөек Ватан сугышының башлангыч чорында аларның полкы илбасарларга каршы батырларча көрәшә. Әмма көчләр тигез булмый. 1941 елның 2 октябрендә Днепропетровск өлкәсендәге Павлоград шәһәре янында рядовой Зәки Җәләлиев аңсыз хәлдә дошман тырнагына килеп эләгә. 1942 елның июнь азагына кадәр аның кебек хәрби әсирләрне Днепропетровск, Кривой Рог шәһәрләрендәге концлагерьларда тоталар. Аннары, 1942 елның июленнән, Югославиянең Сисак шәһәренә озаталар.

Тоткыннар шахталарда авыр эшләр башкара. Зәки Җәләлиевнең элекке һөнәрен белгәч, немецлар бераздан аны биредә дә ат караучы итеп куялар. Ә бу исә әсиргә киләчәктә тоткынлыктан котылу юлын табарга нык ярдәм итә. Атлар белән эшләүдән оста файдалана Зәки. 1943 елның августында Татарстанның Дөбъяз районының (хәзерге – Биектау) Олы Кавал авылы егете Габделхак Галиуллин белән бер атка атланып лагерьдан качалар һәм Югославия партизаннарына килеп кушылалар. Шулай итеп ике якташабыз партизаннарның 33 нче дивизиясе карамагындагы 10 нчы корпусның 2 нче Масловицкая бригадасында рус ротасы сугышчылары булып китә. Әлеге бригада составында Югославиянең Чазма, Масловина, Беловар, Подравнина, Клугитор, Журжеватц, Белогора, Тополавац торак пунктларын фашистлардан азат иткәндә шәхси батырлык үрнәкләре күрсәтәләр Татарстан егетләре. 1944 елның 11 октябрендә Новый Град каласы янында барган хәлиткеч сугышларның берсендә Зәки Җәләлиев авыр яралана, дусты Габделхак Галиуллин исә шунда һәлак була.

ГАДЕЛЛЕК ТАНТАНА ИТСЕНГӘ...

Зәки Җәләлиевка 1944 елның октябреннән 1945 елның гыйнвары башына кадәр Югославия госпитальләренең берсендә дәваланырга туры килә. Шуннан соң НКВДның фильтрацион пункты аша да үтә, тиешле тикшерү эшләрен уздырганнан соң, аның тоткынлыкта фашистларга хезмәт итмәве, киресенчә, Югославия партизаннары белән бергәләп дошманга каршы батырларча көрәшүе ачыклана.

1945 елның 5 апрелендә медицина комиссиясе Зәки Җәләлиевның хәрби хезмәткә яраксыз дип таба һәм аны туган ягына кайтарып җибәрә...

Боларны без, әлеге төбәкнең сугыш һәм хезмәт ветераннары җитәкчесе, данлыклы хәрби офицер Зиннур ага Җәләлиев, бу төбәктәге Битләнгер, Югары һәм Түбән Өскебаш эзтабарлары белән бергә, СССР Оборона министрлыгының Подольск шәһәрендәге (Мәскәү өлкәсе) Үзәк архивына, илебезнең Дәүләт куркынычсызлыгы комитеты (КГБ) органнарына, шулай ук Югославиянең Мәскәүдәге илчелегенә һәм Белградтагы Архив институтына хатлар язып, тиешенчә ачыкладык...

Иң гаҗәпләндергәне шул булды: Җиңү таңы атканнан соң 45 ел вакыт үтсә дә, мөхтәрәм ил агасы Зәки Җәләлиевка һаман да «Ватан сугышы ветераны» таныклыгы бирелмәгән икән.

Гаделлек ахыргача тантана итсен өчен, 1990 елның маенда Югославия партизаннарының Орёл һәм Брянск шәһәрләрендә үтүче Бөтенсоюз очрашуына Зәки ага Җәләлиевны махсус алып бардык. Ветеран партизанның аягы сынган чак дип тә тормадык. «Юлда чакта үзеңне күтәреп кенә йөртербез!» – дип,

Автор:
Шаһинур Мостафин

Фото автор архивыннан

Зәки аганың Казан каласында яшәүче улы Рәфкать Җәләлиевны, якын туганы – әлеге төбәкнең яшь эзтабарлар төркеме башлыгы, танылган мөгаллим Рифат Җәләлиевны үзебез белән алдык. Истәлекле очрашу мизгелләрен мәңгеләштерү өчен, республикабыз телестудиясеннән документаль фильмнар төшерү остасы Камил Арифуллов белән Түбән Өскебаш урта мәктәбенең «Батырлык» кинофотостудиясе җитәкчесе Гомәр Мөбәрәкшин да барды.

Әлеге сәфәр Зәки ага файдасына тәмамланды. Бирeдә ул үзенең партизан дусты – Брянск каласында яшәүче Борис Гусевны очратты һәм аны шул ук елның июнь аенда Аксыбы Сабан туена чакырды. Олы кунак, өскебашлыларның көчле алкышлары астында, Зәки Җәләлиевка «Югославия партизаны – СССР гражданины» медален тапшырды һәм сугышчан дустының партизанлык иткән чорда күрсәткән батырлыклары турында тәфсилләп сөйләде.

КУНАК АШЫ – КАРА-КАРШЫ

Тагын бер елдан соң – 1991 елның августында – Түбән Өскебаш төбәгенә Югославия Федератив Республикасының Мәскәүдәге илчелегеннән рәсми вәкилләр килде. Илчелекнең матбугат һәм мәдәният мәсьәләләре буенча киңәшчесе, дипломат Радойка Фехимович-Джуракич белән Сербия Республикасының Халыкара мөнәсәбәтләр буенча җәмәгатьчелек советы секретаре, сәяси фәннәр кандидаты Зоран Фехимовичны район җитәкчеләре белән бергә өскебашлылар бик җылы каршыладылар. Кунаклар «Таң» колхозына керүче авыллар белән иркенләп танышканнан соң, Түбән Өскебаш мәктәбендә үткән «Батырлык дәресе»ндә катнаштылар һәм Югославиянең данлыклы партизаны дип саналучы Зәки Җәләлиевка Белградтагы Архив институтында саклануы, аңа кагылышлы кадерле хәрби документларның мөһерле күчермәләрен тапшырдылар; үз хөкүмәтләреннән, илдәшләреннән кайнар рәхмәт сүзләрен җиткерделәр, истәлекле бүләкләр бирделәр.

Кунак ашы – кара каршы дигәндәй, таңлылар да җавапсыз калмадылар – олы кунакларга «Победа» маркалы кул сәгатьләре тапшырдылар. Ике ил – Советлар Союзы һәм Югославия халыклары азатлыгы өчен фашизмга каршы көрәштә җиңү яулашкан мөхтәрәм ил агасы Зәки Җәләлиев та шундый ук бүләккә лаек булды.

Аннары очрашу Аксыбы авылында – ирле-хатынлы Зәки ага белән Марзия апа Җәләлиевларның иркен йортында таңга кадәр дәвам итте. Бирегә аларның Кукмарада, Казан каласында һәм күрше Киров өлкәсендә яшәүче балалары – Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре Миннәхмәт, Россия күләмендә танылган урманчы Рәфкать (алар виртуоз баянчылар, күп кенә музыкаль бәйгеләрнең лауреатлары), бухгалтер булып эшләүче Сәвия, элемтә-почта бүлеге хезмәткәре Гөлсирә дә кайтканнар иде. Очрашу бик җылы килеп чыкты. Зәки аганың серб һәм хорват телләрендә бик иркен сөйләшүе, Югославия халыкларының җырларын һәм үзебезнең милли җырларыбызны да оста башкаруы рухи тугандашлык мәҗлесенә кабатланмас ямь-тәм өстәде…

ХАЛЫК КҮҢЕЛЕНДӘ КАЛДЫ

Брянскидан һәм Югославия илчелегеннән килгән кунакларның йогынтысы зурдан булды. Зәки Җәләлиев тулысынча «акланды»: аңа, ниһаять, II дәрәҗә Ватан сугышы ордены таныклыгы тапшырылды, пенсия акчасы да түләнә башлады. Моңа Өскебаш төбәге эзтабарлары белән бергә, барлык авыл халкы да нык сөенде. Чөнки Зәки Җәләлиев – хөрмәт лаек шәхес, авылның абруйлы мулласы да. Заманында ул, районның һәм республиканың иң алдынгы комбайнчыларының берсе буларак, СССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең Алтын медаленә лаек булган мактаулы игенче дә әле.

Данлыклы партизан Зәки Җәләлиев хәләл җефете Марзия ханым белән.

Менә шуларның барысын чагылдырып, мәктәп музеенда Зәки Җәләлиевка багышланган яңа стенд-экспонатлар пәйда булды. Анда Орёл шәһәрендәге сугыш һәм хезмәт ветераннары советы рәисе урынбасары Иван Булгаков җибәргән «Югославия партизаннары» дигән китап та бар. Анда Зәки аганың «Сражался в русской роте» дип исемләнгән истәлек язмасы да урнаштырылган.

Камил Арифуллов белән Гомәр Мөбәрәкшин исә, данлыклы партизанның һәм хезмәт батырының фидакарьлеген документаль кинофильм тасмаларында чагылдырып, республикабыз телевидениесе аша тамашачыларга кат-кат күрсәттеләр.

Гаделлекнең тантана иткәнлегенә ихластан сөенеп, Зәки Җәләлиев гомеренең соңгы көннәренә кадәр (ул 2000 елның 21 июлендә бакый дөньяга күчте) гел игелекле гамәлләр кылып кына яшәде, үзе турында халык күңелендә якты-яхшы истәлекләр генә калдырды.

Брянскидан килгән Борис Гусев Аксыбы Сабан туенда.

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

1950нче еллар

БУЫННАР

Киләсе елга Татарстан Республикасы төзелүгә 100 ел булачак. Түгәрәк һәм мөһим юбилей – гасыр гына түгел, тулы бер тарихи дәвер! Шул ук 2020 елда 100 еллыгын билгеләп үтәчәк «Татарстан» журналы уртак юбилей хөрмәтенә «Буыннар» проектын эшли. Без анда Татарстаныбыз тарихында эз калдырган шәхесләр, вакыйгалар, күренешләр турында сөйлибез. Бүген сүз 50 нче еллар турында барыр.

ЗУР ҮЗГӘРЕШЛӘР БУЫНЫ

Сугыштан соңгы елларда совет Татариясе ничек яшәгән? Индустриальләшү кем җилкәсенә төшкән? Бөек төзелешләргә ил кемне җибәргән? Авыл хуҗалыгын ничек күтәргәннәр? Торак проблемасын нинди юллар белән хәл иткәннәр?

1 НЧЕ ТАРИХ

КИЛОГРАММЫ – 85 СУМ

Кара уылдык күпме торган?

2 НЧЕ ТАРИХ

50 НЧЕ ЕЛЛАР КАЗАНЫ

Шәһәрдә бу чорда нинди рух хөкем сөргән?

3 НЧЕ ТАРИХ

СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЙЛАРЫ

Җәлил, Девятаев, Гаврилов – бүләкләр үз геройларын ничек тапкан

4 НЧЕ ТАРИХ

БЕРЕНЧЕЛӘР ЧОРЫ

«Икенче Баку» ничек төзелгән

5 НЧЕ ТАРИХ

ДИҢГЕЗ ТӨБЕНДӘ

Куйбышев сусаклагычы кай җирләрне баскан

«Татарстан» журналының махсус проекты

Фото ТР Милли музееннан алынды

1951

Иң атаклы Казан сталинкаларының берсе – Казан финанс-икътисад институты бинасы төзелеше тәмамлана

387 нче Казан заводында илебездә беренче вертолёт – Ми-1 җитештерелә башлый

1952

«Теплоконтроль» заводы сафка баса

1953

Казанда 22 нче авиация заводында беренче стратегик бомбардировщик ТУ-1 серияләп чыгарыла башлый

Шәһәр тибындагы Әлмәт бистәсенә шәһәр статусы бирелә

1954

Казанда яңа аэровокзал ачыла

Киләчәктә дөнья күләмендә танылу алачак композитор София Гобәйдуллина Казан консерваториясен тәмамлый

Казанда Ирек мәйданында – В. И. Ленинга, КДУның төп бинасы каршында студент В. Ульяновка һәйкәл куела

Казанда тагын бер яңа җитештерү – Компрессорлар заводы эшли башлый

1955

Яңа Писмән эшчеләр бистәсе Лениногорск шәһәренә әверелә

1956

Шагыйрь Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме (вафатыннан соң) бирелә

ТАССР нефть табу күләмнәре буенча СССРда беренче урынга чыга

Казанда Ирек мәйданында Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинасы кулланышка тапшырыла

Казанда ТАССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе ачыла

1957

Питрәч районы Әлбәдән авылында туып-үскән Брест крепосте сакчысы Петр Гавриловка Советлар Союзы Герое исеме бирелә

Куйбышев сусаклагычын тутырганнан соң, су Казанга килеп җитә

Казанда яңа елга порты ачыла

Мәскәүдә зур уңыш белән Татар сәнгате һәм әдәбияты декадасы уза.

Очучы Михаил Девятаевка Советлар Союзы Герое исеме бирелә

1958

Кабан күле буендагы скверда Габдулла Тукайга һәйкәл куела

1959

Беренче миллион тонна нефть җир өстенә чыгарыла

Казан телеүзәге үз эшен башлап җибәрә

Яшел Үзәндә Серго исемендәге завод беренче «ДХ-120» – атаклы совет «Мир» суыткычын чыгара

САКСОФОН БЕЛӘН КЕРОСИНКА ӨЧЕН СОЛО

Җәй. Эссе. Ресторанның ачык тәрәзәсеннән исерткеч Moonlight Serenade агыла. Янәшәдә, кинотеатр фойесында, Армстронгның On the Sanny Side of the Street җыры халыкны кыздыра. Якындагы театрдан дәртле дә, талгын да Saint Louis Blues ишетелә. Труба, саксофон, бәрмә уен кораллары... Илленче еллар башы. Америкамы? Хәзер менә сиңа! Казан, СССР...

Заманны тояр өчен, аның тавышын һәм исен сизү зарур. Илленче еллар Казаны джаз тавышына күмелгән. Тарихи парадокс: халыклар юлбашчысы әле үзенең соңгы трубкасын да тартып бетермәгән, аның ярдәмчесе Михаил Суслов, космополитлыкны сүгеп, инде төкереген чәчә, ә Иделдәге провинциаль шәһәрдә – искиткеч музыкаль башбаштаклык! Чит илләрдәгечә стильле егетләр, «шанхайлылар» – галстук-күбәләк, модалы пиджактан – Баумандагы «Русское подворье» ресторанында һәм Горький паркындагы бию мәйданчыгында, «Родина» кинотеатрында һәм Офицерлар йортында ачыктан-ачык, яшеренмичә, «юаннар музыкасын» уйный...

Зыянлы буржуаз музыка әле ныгып җитмәгән җаннарны бик ансат кына яулый: Казан мединституты студенты Вася, бер тапкыр джаз әфьюнын татып карагач, гомергә аның колына әйләнә. Аның яшь дуслары белән дә – шул ук хәл. Аннары, күп еллар үткәч, язучы Василий Аксенов исенә төшерәчәк: аның яшьлеге, «кызыктыргыч ерак төнге дөнья утларыдай, әлеге «шанхайлылар» уты белән өртелгән булган» икән бит.

ШАНХАЙ-БЛЮЗ: СОВЕТ ВЕРСИЯСЕ

Котлы салучы еланнар – «шанхайлылар» – Казанга Кытайдан кырыгынчы еллар азагында кайтып төшә. «Шәрык илләре свингы короле» Олег Лундстрем җитәкчелегендәге унтугыз кеше, тулы бер бигбенд. Лундстрем, Деринг, Бонарь, Баранович, Модин... Гәрчә башта Татарстанда Лундстремның бердәм джаз-оркестры юк дип саналса да (Ленин-Сталин партиясе сәясәтенә ачыктан-ачык каршы чыгып булмый бит), алдынгы карашлы яшьләр әлеге музыкантларны тиздән урамда таный башлаячак.

Әмма татар дипломатия сәнгате гамәлдә бит әле. Музыкантларны чыгыш ясаудан тыймыйлар, мөмкин булганда, аларны эшкә урнаштыралар, маэстро Лундстрем Казан консерваториясендә укый башлый

(СССРда дипломсыз маэстро партбилетсыз коммунистка тиң бит). Һәм биг-бенд, төркемнәргә бүленеп, әкренләп халыкны «буржуаз агу» белән «агулый». Кинотеатрларда, ресторан һәм клубларда. Билгеле инде, чамасын белеп һәм җиренә җиткереп: программада беренче чиратта – «Катюша», «Голубка» кебек һәм башка ышанычлы совет көйләре джаз эшкәртелешендә яңгырый. Һәм икенче чиратта гына – эшче-крестьян дәүләтенә чит-ят булган Глен Миллер, Дюк Эллингтон, Луи Армстронг җәүһәрләре... Дөрес, кайвакыт биг-бенд тулы составта җыела, һәм шул чакта инде иң бәхетлеләр Шанхайдагы кабатлаган диярлек концерт программасын ишетеп кинәнә...

Җирле чекистларның да музыкаль зәвыгы булган, ахрысы. ТАССР Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгында 1952 елның декабрендә Олег Лундстремның сәяси ышанычлылыгын тикшерү өчен ачылган эштә: «Агентура аны советларга хәерхаһлы, дип саный», – дип теркәлгән.

ЗУР ШӘҺӘР ИСЕ

Лундстрем джазы – Иделдән искән саф җил кебек. Киләчәктә булачак үзгәрешләр җиле ул, әмма әлегә бик зәгыйфь. Казан коммуналкаларындагы әчкелтем исләр, Постау бистәсендәге зәһәр амбре һәм шәһәр читендәге пролетарийлар яши торган йортлар тәрәзәсеннән агылган махмыр сулышын басу әлегә аның хәленнән килми.

Илленче еллар башы Казанын чит ил исләре белән гаҗәпләндереп булмый. Татарстан урамын икегә бүлә торган җирле Унтер-ден-Линден – юкә аллеясенең (җитмешенче еллар башына кисеп бетерелгән) июньдә чәчәккә күмелүе генә ил халкының яртысы өчен сабын кайнатыла торган Вахитов исемендәге химкомбинат чыгарган әчегән май исен баса алмый. Стратегик дары заводыннан күтәрелгән күксел болыт Петрушкин разъездындагы һаваны тәүлек буе серкә исенә мана. Сарык тиресе иләү (мутон җитештерү технологиясе өчен Казан мех комбинатына 1951 елда Дәүләт премиясе биреләчәк) шәһәрдәге «хуш» исләр букетына үз «тәмләткечләрен» өсти...

Әмма сәнәгать исләре чәчәк кенә әле – совет классикасы «Шипр» фонында «Красная Москва» ислемае кебек. Казан «Шипры» – керосин ул, аның үзеге дә, кырыйлары да тулысынча шул искә баткан. Бөтен кешенең аш бүлмәсендә керосинка һәм керогаз төтенли; икмәк, тоз һәм шырпыдан соң, керосин иң үтемле товар санала. Аны алу өчен чиратка басу хәтта алдынгы эшчеләр сыйныфы белән ышанычсыз интеллигенцияне дә хокукларында тигезли.

Лундстрем хатыны белән Бауман урамында, театр хезмәткәрләре тулай торагында яши, бүлмә фанера белән бүленгән, уртак коридорда керосинка һәм кер юа торган тагараклар тора. Мөгаен, маэстро һәм башка «шанхайлылар» керосинны якындагы лавкадан – күрше Островский урамындагы тәбәнәк таш бина-бункердан аладыр. Керосин сатып алу – үзе бер могҗиза. Башта, эсседә әлсерәп, бик озак урамда чират торасың, аннары, ниһаять, мавзолейдагы кебек салкын һәм ярымкараңгы кибет эченә эләгәсең. Аермасы бер генә – саркофаг урынына, анда зур корыч чан тора, янәшәсендәге хезмәткәр литры 65 тиеннән ягулык бүлә...

Джаз дигәндә, Бродвей, Манхэттенның күккә ашкан йортлары, Американың куәтле машиналары күз алдына килә. Ерак дөнья утлары... Биредә исә – керосин, коммуналкалар. Моннан йөз ел электәге кебек үк Тукай урамындагы зур базар янында мәңгелек пычрак изгән шыгырдавык арбалар... Совет джазының киләчәге бар микәнни?

ИРКЕНРӘК СУЛЫШ АЛ ҺӘМ ҖЫРЛА

Берничә елдан соңгы Казан. Илленче еллар уртасы. Губернатор сарае каршындагы Кремль бакчасында гранит эскәмиядә бронза Ильич моңсуланып утыра – аңа терәлеп үк утырган мыеклы көрәштәше исә юкка чыккан, әйтерсең, анда беркайчан булмаган да. Һәм, гәрчә керосинкалар кимемәсә һәм дары заводы снарядларга тәмуг катнашмасы тутыруыннан туктатмаса да, хәзер шәһәрдә сулыш алу бөтенләй башкача.

Иркенрәк сулана, тын юллары киңрәк кебек. Һәркемгә. Джазга – бигрәк тә. Казан үзе теләп «шанхайлыларга»бирелә. Инде дипломлы композитор һәм Качалов театры-

Автор:
Әскәр Сабиров

ның сәнгать җитәкчесе булган Олег Лунстрем дан нурларында коена. 1955 елның җәендә шәһәрдә афишалар ябыштырыла: Җәйге театрда джаз оркестры концертлары. Ун концерт булачак, әмма аларга эләгерлек түгел – бөтен билет сатылып беткән. Хезмәтчәннәр соравы буенча, Черек күлдәге иске циркта оркестр тагын бер концерт куя.

Джаз хәзер күңелгә якын, халык диңгез артыннан кайткан җәүһәрләр белән генә түгел, джаз эшкәртелешендәге татар көйләре белән дә хозурлана. Пластинка пәйда була, анда: «Олег Лундстремның Татар эстрада оркестры», дип язылган. Мондый оркестр рәсми теркәлмәгән, диләр, әмма бу хәзер беркемне дә хафаландырмый – хәрби френчтагы мыеклы кеше артыннан идеологик тыюлар да каядыр еракка киткән кебек…

Дмитрий Шостакович, татар композиторларының Лундстрем пластинкасындагы көйләрен тыңлагач, «Советская музыка» журналы редакциясендәге киңәшмәдә: «Совет җиңел музыкасы менә шул юлдан барырга тиеш», – дип әйтеп куя.

Товарищ Абсалямов А. С.
является участником декады татарского искусства и литературы в Москве 1957 года.
Министр Культуры ТАССР (Х. Рахматуллин)
ПФ 05496 от 27 апреля 1957 г. Тираж 1500 Татполиграф, 002622

Товарищ Тарджиманов Д. Д.
является участником декады татарского искусства и литературы в Москве 1957 года.
Министр Культуры ТАССР (Х. Рахматуллин)
ПФ 05496 от 27 апреля 1957 г. Тираж 1500 Татполиграф, 002622

ИЛҺАМ ҺӘМ ПАРТИЯ – ИГЕЗӘК ТУГАННАР

Ирек бацилласы – йогышлы әйбер. Джазга яраган нәрсәләр ни өчен башкаларга ярамый? Мәскәүдәге Татар мәдәнияте декадасына әзерлек башлаган иҗат коллективлары (ул СССР Министрлар Советы карары белән 1957 елда үтәргә тиеш була) да үзләренең импровизациягә хокукын дәгъвалап чыга.

– Безнең эшебез иҗади, аның белән идарә итәргә ярамый, – дип киреләнә язучы Әмирхан Еники республика язучыларының 1956 елның маенда үткән җыелышында һәм мәдәнияткә партия тыкшынуын туктатырга өнди. Сталин бүләге иясе композитор Нәҗип Җиһанов исә бөтенләй аполитизм күрсәтә – декадага партия турында җыр язудан баш тарта! Дәлилли дә: «Тәкъдим ителгән шигырь илһамландырмый, илһамсыз исә мин яза алмыйм». Декадага әзерлекне тикшерү комиссиясендә Җиһанов: «Опера театры составы сәнгатьлелек принцибы буенча түгел, бәлки иҗтимагый эш принцибы буенча расланган», – дип белдерә. Һәм тагын болай дип тә өсти: «Театр яхшы солистларны эшкә алмый, күрәмсең, бөтен кеше дә Мәскәүгә бара алмас, дип шикләнә…»

«Хрущев җепшеклеге» беркатлы, хәйләсез интеллигенциянең башын әйләндерә, аларны буш хыялларга чумдыра. Партия өлкә комитетына агылган хатларда – мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбиятын мәҗбүри укыту, абитуриентларга имтиханнарны туган телдә тапшыру хокукын бирү һәм Казандагы югары уку йортларында татар телендә укыта башлау тәкъдимнәре. Язучылар Нурихан Фәттах, Әмирхан Еники, Шәйхи Маннур совет татарстанлыларының күпчелегенең яшерен хыялын – ТАССРны союздаш республикага әйләндерүне – һәркем ишетерлек итеп яңгыратырга кыюлык таба…

Хыяллар-хыяллар… Мәскәүдә 1957 елның җәендә уңышлы үткән Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы чыныккан партиялеләр белән хыялый интеллигенция бәхәсендә кем җиңүен ачык күрсәтә. Әлеге вакыйгага махсус язылган һәм тиз арада онытылган «Давыл кошының яшьлеге» һәм «Язылмаган законнар» (нефтьчеләр хезмәте

турында) пьесалары, «Татарстан һәм Кытай нефтьчеләре арасында иҗади тәҗрибә уртаклашу» картинасы һәм башка шундый җәүһәрләр,әлбәттә инде, илһам килгәч язылган. Какшамас татар-кытай дуслыгы турында пьеса да шундыйлардан. Дөрес, ул барыбер башкала сәхнәсендә күрсәтелмәгән – совет-кытай мөнәсәбәтләре кисәк начараю сәбәпле, аны КПСС ҮК куярга рөхсәт итмәгән...

Әмма хәтта партия-гегемонда гүзәллек хисеннән мәхрүм түгел. Мәскәүгә милли сәнгатьнең чын җәүһәрләре дә бара: «Шүрәле» балеты һәм «Алтынчәч» операсы, «Зәңгәр шәл» спектале... Соңрак, Декаданы әзерләү һәм уздыру комиссиясе хисабында, уңышның төп илһамчысы һәм оештыручысы кем булуын тыйнак кына билгеләп үтәчәкләр: «Спектакль, концертлар һәм башка чараларның идея һәм сәнгать дәрәҗәсен күтәрү буенча чаралар күрелде...»

Ә джаз ни хәлдә соң? Олег Лундстремның эстрада оркестры – программаның каймагы, Декаданың тулы хокуклы катнашучысы. Дөрес, коллектив хәзер Казанга гастрольгә генә киләчәк...

ЦЫЦ, МЕЛОМАННАР!

«Росгастрольбюроның» Казанда эч пошудан интеккән администраторының Лундстремның иске цирктагы нәкъ менә шул планнан тыш куелган концертына барып элэгүен күр әле син! Тыңлап таң кала һәм, халыкны терсәкләре белән ера-ера, сәхнә артына ашыга: «Егетләр, сез нишләп бу Казанда ятасыз, әйдәгез Мәскәүгә!» – ди. Мәскәүдә исә ярдәм сорап куәтле Сергей Михалков янына барган, диләр. Янәсе, Казанда чын джаз музыкантларын тапкан, шуларга күченергә булышасы иде. Михалков мондый могҗизага бик ышанып бетмәгәч, инандыру өчен каты итеп әйтергә мәҗбүр булган, диләр: «Мин бит сезгә б... тәкъдим итмим инде!»

Казан меломаннарын иреклe Шанхай джазыннан мәхрүм иткән кешенең фамилиясе Цыц булып чыккан. «Цыц, егетләр, джаз – сайлап алынганнар өчен генә», – дип нервланып шаярта бу җәһәттән яраткан концерт ризыгыннан мәхрүм калган Казан публикасы.

Ә калган шәһәр нишли? Казанда хәзер яңа авазлар яңгырый. Соцгород артында һаваны вертолет калаклары выжылдап кисә – бирeдә илдә беренче геликоптерларны җыялар. Яңа елга портында канатлары су астында булган судноларның двигательләре гүли – беренче «Ракета»лар Казаннан Горькийга кадәр йөри. Караваево, Казансу өстендә исә, көне-төне, үрдәкләрне куркытып, әле генә авиация заводында җыелган дәһшәтле стратегик Ту-26 очкычлары гөрелди. Алар инде Американы куркытырга, теләсә кайсы вакытта атом бомбасын төяп юлга чыгарга әзер...

Коммунизмга ышанычлы адымнар белән барыр өчен бер аяктан атлау зарур. Димәк, бернинди дә импровизация булмаска тиеш. Дәртле маршлар, якты киләчәк, бөтен шикләнүләрне кире кагучы идеология бар икән, безгә джаз нәрсәгә соң? «Җепшеклек»? Провинциядә ул башкаладагы кебек сизелми, Мәскәүдәгедән иртәрәк тә төгәлләнер, мөгаен...

Хуш, үзгәреш җиле, булып чыгамыни инде? Илленче еллар Казаны моңа риза түгел. Менә, йомры таш түшәлгән Тельман урамы буйлап, туфли үкчәсен сындырмаска тырышып, кара чәчле, ябык Сонечка Гобәйдуллина консерваториягә йөгерә. Менә Ленин урамында, университет аудиториясендә, мәңгелек күн курткасын һәм чаңгы ботинкаларын кигән Слава Говорухин лекция барышында ук студентлар капустнигы өчен сценарий уйлап таба... Музыка училищесында, оялчанлыгын җиңәргә тырышып, кулларын кая куярга белмичә, кичә генә авылдан килгән Илһам Шакиров моңлана. Мехчылар клубында исә, үзенең яңа төзелгән «Казан утлары» ансамбленә кушылып, татар сандугачы Әлфия Авзалова җыр суза. Ун яшьлек Альберт Әсәдуллин исә, билетсыз килеш трамвай баскычына басып, Постау бистәсеннән төшеп килә. Әнә тагын, ял итәргә көч-хәл белән вакыт табып, авыл хуҗалыгы институтының иң җитди студенты һәм ялкынлы җанатары Минтимер дуслары белән стадионга китеп бара...

Тиздән, кайберләре – иртәрәк, икенчеләре – соңрак, алар яңа музыка, яңа стиль, яңа кино һәм яңа тормыш авторларына әйләнәчәк.

1950нче еллар

ГИДУВ. Уйлап табучы В. А. Новиков үзе уйлап тапкан флюоротомограф янында. 1950 нче еллар. Казан ш.

БЕР КУКУРУЗ ГЫНА ТҮГЕЛ...

Татарстан үсешенең һәр дистә елы тарих битләренә үзенең уңай һәм тискәре күренешләре, үзенчәлекләре белән кереп калган. Авыл халкына кукуруз үстерүне көчләп тагу кебек күңелсез истәлекләрдән тыш, 1950–1960 нчы елларда Татарстанда игелекле һәм истә калырдай үзгәрешләр дә шактый була. Сталинның «шәхес культын» фаш иткәннән соң, НКВД оештырган ялган гаепләүләр белән хөкем ителгән меңнәрчә сәяси тоткын өйләренә әйләнеп кайта. Татарстанда яңа нефть

Фотоларны ТР Милли музее тәкъдим итте

ТАССР Югары Советы депутатына кандидат Х. А. Ибраһимова эш кабинетында. 1950 ел. Казан ш.

Казан. Бауман урамы. «Родина» кинотеатры. 1950 ел.

Казан. Финанс-икътисад институты. 1950 ел.

шәһәрләре үсеп чыга, ә иске шәһәрләрдә яңа фатирлар – «хрущёвка»лар пәйда була. Яңа хастаханәләр, мәктәпләр, балалар бакчалары, клублар, кибетләр төзелә... «Җепшеклек» татар җәмәгатьчелегендә милли сәясәттә үзгәрешләр булачагына өмет уята. Галимнәр һәм иҗат әһелләре халык традицияләрен торгызу турында чыгышлар ясый башлый. 1957 елда Мәскәүдә узган Татарстан сәнгате һәм әдәбияты декадасы ТАССР тормышында зур вакыйгага әверелә, анда Татар академия театры, Татар опера һәм балет театры, Зур рус драма театры, Минзәлә колхоз-совхоз театры, Татар филармониясе коллективлары катнаша. Анда 50дән артык спектакль күрсәтелә, татар язучылары белән очрашулар оештырыла. Беренче тапкыр бөтен илгә татар халык җырлары яңгырый...

ГИДУВ. Акушерлык клиникасында бала ашату. 1950 нче еллар. Казан ш.



Студентларны чирәм җирләрне күтәрергә озаталар. 1956 елның 26 июле. Казан ш.

Телефонисткалар «Бодо» аппараты артында эшлиләр. 1950 ел. Казан ш.



1950 нче елларда СССРда гражданнарның хезмәт хакларына кагылышлы берничә үзгәреш кертелә. Хатын-кыз хезмәтенең роленә зур әһәмият бирә башлыйлар. Яшь чикләре дә үзгәрә: хәзер унсигез яшьтән генә түгел, алтмыштан соң да эшлиләр. Планнарны арттырып үтәгән өчен премияләр, өстәмә акчалата кызыксындырулар барлыкка килә, хезмәт хакына салымнар кыскартыла. Хезмәт хакына авырган вакытлар, чираттагы яллар өчен түләүләр, кызыксындыру акчалары, яхшы укыганга стипендияләр, балалар бакчаларын тотуга, күп балалы гаиләләргә ярдәм итүләр керә башлый. 1953 елда бәяләрнең төшерелүе җитештерүнең барлык тармакларына: азык-төлек, кием-салымга, электр приборларына, төзелеш материалларына, хуҗалык товарларына кагыла.Продукциянең группасына карап, бәяләр 10%тан алып 30% ка кадәр төшә. Бу, үз чиратында, куллану ихтыяҗының үсүенә һәм җитештерү күләменең артуына китерә. Менә 1953 елгы күрсәткечләр:

ТАССР яшьләре фестивале.
1957 елның 14–16 июнь көннәре.
Казан ш.

БЕР КЕШЕ БАШЫНА ИСӘПЛӘГӘНДӘ ЕЛЛЫК АЗЫК-ТӨЛЕК ҺӘМ ТОВАР ЗАПАСЫ:

- 26 кг ит һәм терлек мае,
- 7 кг балык һәм диңгез ризыклары,
- 172 л сөт,
- 60 данә йомырка,
- 172 кг камыр ризыгы,
- 241 кг бәрәңге,
- 8,1 кг шикәр.

Һәм шулай ук:

- 16,47 кв. м тукыма,
- 3 пар оек яки оекбаш,
- 1 пар яхшы күн аяк киеме,
- 4 кг сабын яки башка кер юу катнашмалары.

Сәгать, телевизор, фотоаппарат, велосипед, мотоцикллар, тегү машиналары, пианино иркен сатыла башлый.

АЗЫК-ТӨЛЕК БӘЯЛӘРЕ:

- ак икмәкнең 1 килограммын 3 сумга сатып алып булган,
- кара ипине – 1 сумга,
- 1 кг сыер итен – 12 сум 50 тиенгә,
- 1 л сөтне – 2 сум 24 тиенгә,
- атланмайны – 27 сум 80 тиенгә,
- үсемлек маен – 17 сумга,
- бер дистә йомырка 8 сум 35 тиен торган,
- аракы – 22 сум 80 тиен,
- кызыл уылдык – 1 кг – 36 сум,
- кара уылдык – 1 кг – 85 сум,
- бөртекле кофе – 1 кг – 50 сум.

СӘНӘГАТЬ ТОВАРЛАРЫНА БӘЯЛӘР:

- 1 пар аяк киеме – 188 сум,
- иң кыйммәтле костюм – 1500 сум,
- «Победа» автомобиле – 16 мең сум,
- «Москвич» автомобиле – 9 мең сум.

САЛЫМНАР:

- Хезмәт хакы 800 сум булганда салым 8% тәшкил иткән,
- 800 дән 1000 сумга кадәр – 10%,
- 1000 нән 1500 сумга кадәр – 12%,
- тагын да зуррак хезмәт хакыннан – 13%,
- баласы булмаган 25 тән 50 яшькә кадәрле гражданнардан 6% күләмендә баласызлык салымын түләткәннәр.
- Әрәмтамаклык өчен дә салым булган.

ТОТКЫНЛЫКТАН СОҢГЫ ТОРМЫШ

Җиңүдән соңгы биш ел, ун... Тормыш бал да май түгел, ләкин беркем дә зарланмый: сугыш кына булмасын. Адым саен сугыш китергән кайгы-хәсрәтне күрергә була. Әнә тәгәрмәч беркетелгән тактадан «машина» ясап, шуны йөрергә җайлаган аяксыз гарипләр. Күзләрен сагыш баскан аз сүзле толлар. Тагын – исән калып гаепле булганнар: тоткынлык тәмугын узган солдатлар. «Әсирлектә булган» мөһере – гомерлек тамга. Шулай да 1957 нче елда әлеге тоткыннарның өчесенә Советлар Союзы Герое исеме бирелә...

ҮЛЕМ ЛАГЕРЕННАН КАЧА АЛГАН БАТЫР

Автор:
Әскәр Сабиров

Атаклы Покрышкин дивизиясенең элеккеге очучысы һәм Заксенхаузен үлем лагереның элеккеге хәрби тоткыны Михаил Девятаев илленче еллар башында – Казанда кечкенә генә катерның капитаны. Моны да зур бәхет дияргә була: сугыштан соңгы елларда эшкә урнашырга дип кая гына бармасын, кире боралар. Мордовиядәге үзенең туган авылы Торбеевода балачак дусты, райком секретаре да яңагына суккандай була: «Сиңа монда эш бар дип беләсеңме?! Монда Идел юк, әйдә, бар, үзеңнең Иделеңә кит»...

ГОМЕРЛЕК МӨҺЕРМЕ?

Казанда да элеккеге әсирләрне кочак җәеп каршы алмыйлар. Девятаев баштарак кайда туры килсә, шунда эшләп азаплана, баржаларга утын төйи. Аннан соң елга портында, кызганып, вокзал буенча кизү торырга алалар үзен. Аннан соң менә – катер капитаны. Ләкин ул төп гаделсезлек белән һич кенә дә килешә алмый: аны, фашистлар әсирлегеннән дошман самолётында кача алган хәрби очучыны, хыянәтче дип саныйлар. Һәм һәрвакыт бу хакта искә төшереп торалар: берьюлы берничә вазыйфа башкарганнарга – өстәмә түләү, ә аңа – юк. Затон башлыгы тынычландырырга тырышмак була: «Син әсирлектә булган кеше, эшкә алганга рәхмәт әйт». Хатыны Фәүзияне әледән-әле органнарга чакырып торалар: «Ирең нәрсәләр сөйли?» Девятаев Мәскәүгә хатлар юллый, тикшерүләрен, хыянәтче мөһерен алып атуларын сорый – җавапка тавыш-тын юк.

1956 нчы ел. XX партия съездында Сталинның шәхес культы фаш ителә, ил репрессияләр һәм бер гаепсезгә хөкем ителгән миллионлаган кешеләр турындагы дөреслекне белә. Берничә айдан соң маршал Георгий Жуков ҮК Пленумында чыгыш ясарга әзерләнә: фашистлар белән хезмәттәшлек итмәгән әсирләрнең берниндә дә гаепләре юк, алар хыянәтче түгел... Пленум булмый кала, ләкин шулай да СССРда партия дәрәҗәсендә үк шуны аңлый башлыйлар: тоткынлыкта да үзләрен батырларча тотканнар бар, алар Ватанга хыянәт итмәгән.

ИСТРЕБИТЕЛЬ АВИАЦИЯСЕ «АРТИЛЛЕРИСТЫ»

1956 нчы елның октябрендә «Советская Татария» газетасында бүлек мөдире, журналист Ян Винецкий, язмаларына геройлар эзләп, Казандагы хәрби комиссариатларның бусагаларын таптый. Шуларның берсендә аңа ниндидер башка сыймаслык хәл турында сөйлиләр. Янәсе, фашист самолетында качкан артиллерист бар, җитмәсә, үзе белән бергә тугыз иптәшен дә коткара. Винецкий, үзе дә элеккеге очучы буларак, берниндә артиллеристның да (ә Девятаев фильтрация лагерендагы писарьның ялгышы аркасында «артиллерист» булып китә) самолётны урлап кача алмаганын аңлый. Шулай да бу кешенең адресын ала.

«Артиллеристка» кунакка Винецкий, «Литературная газета»сының үзхәбәрчесе Булат Гыйззәтуллин белән бергә, кичке җидедә килә һәм иртәнге җидегә кадәр сүзләре бетми. Соңрак, Девятаев үзе искә алганча, бу кичтә каенанасына самавырны биш мәртәбә яңартырга туры килә...

Ишеттем һәм яздым гына – бу илленче еллар турында түгел. Очрашудан соң ай-ай ярым вакыт үтә. Шул вакытта гына Винецкий үзе турында искә төшерә – шалтыратып болай ди: «Михаил Петровичка әйтегез, мин органнарга барырга һәм бөтенесен дә тикшерергә рөхсәт алдым». Соңрак ачыкланганча, әлеге эш белән КПССның Татар өлкә комитетының беренче секретаре дә кызыксынган икән...

БӘЙРӘМ ТАБЫНЫ

Ниһаять, очерк языла. Аны турыдан-туры «Литературная газета»га юлларга уйлыйлар. «Бөтен дөнья белсен өчен», – дип дәлилли үз ниятен Гыйззәтуллин. Яңа ел алдыннан бастырырга вәгъдә бирәләр. Аннан соң, 23 февральдә чыгачак, дип хәбәр итәләр... Моның урынына Девятаевка «Патриот» журналыннан полковник килә: «Михаил Петрович, әйдә, берәрне тотып куйыйк әле! Мине монда Винецкий материалын тикшерергә җибәрделәр...»

Ян Винецкийның очеркы «Литературка» да 1957 нче елның 23 маенда басыла. Куанычыннан нишләргә белмәгән Девятаев тимер юл вокзалына йөгерә һәм газеталар сатып ала – ун сумга! Эштә затон башлыгын да алыштырып куйганнармыни... Җитмәсә, тагын Мәскәүдән, СССР елга флоты министры Зосима Шашковтан шалтыраталар: тиз арада – Мәскәүгә!

Мәскәүгә Михаил Петрович «Советская авиация» журналында эшләүче Георгий Евстигнеев белән бергә оча – спиртлы эчемлекләр төялгән Ил-14 транспорт самолётында. Пассажирларының каһарман очучы икәнен

белеп алган летчиклар аны коньяк белән сыйлыйлар. Шулкадәр юмартланалар ки, самолет Мәскәүгә төшеп утыргач, Девятаев мондый кыяфәттә зур түрәләр янына барырга ярамаганлыгын аңлап ала. Министрга герой икенче көннең иртәсенә генә барып җитә, әмма соңга калганга ачулану түгел, йөзләренә дә чыгармыйлар. Киресенчә, министр барысын да чакырып, очучының батырлыгы, әсирлектә булганы өчен эшеннән чыгарылулары турында сөйли. Ә сүзен төгәлләп, болай ди: «Михаил Петрович хәзер кайсыгыз янына керсә дә, ишекне аягы белән тибеп ача ала».

1957 нче елның августында Михаил Девятаевка Советлар Союзы Герое исеме биреләчәк. Бүләк тапшырылганнан соң, ул ай буе Константин Симоновның дачасында кунак була. Язучы аның хөрмәтенә банкет оештыра, шунда Герой беренче тапкыр устрицаларны авыз итеп карый.

Михаил Петрович Девятаев

Гвардия өлкән лейтенанты, очучы-истребитель, Советлар Союзы Герое. 1941 нче елның 22 июненнән – хәрәкәттәге армиядә. Һава сугышларында 9 дошман самолетын бәреп төшерә. Соңгы «фоккер»ны 1944 нче елның 13 июлендә юк итә, шул ук көнне үзен дә бәреп төшерәләр, аңсыз килеш әсир төшә. Лодзь хәрби әсирләр лагереннан качу омтылышы өчен аны Заксенхаузен үлем лагерена күчерәләр. Шундагы яшерен оешма кешеләре үлем көткән Девятаевның номерын башка, үлгән тоткынныкына алыштыралар, бу Девятаевның гомерен саклап кала. Степан Нитенко исеме астында Девятаев Узедом утравына җибәрелә, анда, Пенемюнде ракета үзәгендә, рейхның яшерен коралы – «Фау» ракеталары эшләнә. 1945 нче елның февралендә Девятаев һәм аның әсирлектәге тугыз иптәше немецларның «Хейнкель» самолетын кулга төшерәләр һәм шуңа утырып качалар. Самолетны һавага күтәргән Михаил аны фронт линиясенә кадәр алып барып җиткерә – совет зениткалары белән утка тотылган «Хейнкель» 61 нче армиянең артиллерия часте карамагына төшеп утыра. «Фау» җайланмалары һәм яшерен завод турында Девятаев тапшырган төгәл мәгълүматларга таянып, полигон бомбага тотыла. 1945 нче елның сентябреннән соң, Девятаевны Сергей Королёв эзләп таба, Узедомда элеккеге әсир совет космик техникасының булачак баш конструкторына немец «Фау»лары ясалган урыннарны күрсәтә.

Илленче еллар ахырында ул су асты канатлары булган беренче суднолар – «Ракета» капитаны була, соңрак «Метеор»да шулай ук капитан булып эшли. Башкалабызның мактаулы гражданины Михаил Девятаев Казанның Арча зиратында күмелгән.

МОАБИТ ТӨРМӘСЕ ТОТКЫНЫ

1950 нче еллар башы. Хәрби әсир Муса Җәлил күптән исән түгел. Шагыйрьне һәм аның «Идел-Урал» легионына кергән яшерен оешмадагы иптәшләрен немецлар 1944 нче елның августында ук Берлиндагы Плётцензее төрмәсендә җәзалап үтерә. Ләкин СССР Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгы тарафыннан Муса Җәлил исеменә 1946 елда ук ачылган эзләү эшен беркем дә архивка озатырга җыенмый. Кемнәрнеңдер ялган күрсәтмәләренә нигезләнеп ясалган нәтиҗәләр буенча ул исән һәм яшеренеп ята. Кайдадыр Көнбатышта, бәлки, безнең илдәдер дә. Җәлилне Ватанга хыянәт итүдә һәм дошманнарга эшләүдә гаеплиләр.

ШИКЛӘР ПӘРӘВЕЗЕНДӘ

Вафат булган шагыйрьгә әлеге ялган шикләр авырлык китерә алмый. Ләкин туганнары – Әминә ханым һәм Чулпан «хыянәтче»нең хатыны һәм кызы исәпләнә, аларга бик кыенга туры килә. Шагыйрьнең башкаладагы Столешников тыкрыгындагы фатирына тәүлек әйләнәсе күзәтү оештырыла, хатынын Лубянкага даими чакырып торалар. Җентекләп сөйләвен таләп итәләр: кем килгән, нәрсә турында сөйләшкәннәр. Фашист тоткынлыгында, гаять авыр шартларда язылган шигырьләре әрәм: аларны бастырырга рөхсәт бирелми.

Шунысы да кызык: бу вакытка әсирләрнең тоткынлыкта килеш яшерен оешма төзүләре, үлем көткәндә дә баш имәүләре турында күп нәрсә инде мәгълүм була. Элеккеге хәрби әсир Нигъмәт Терегулов Татария Язучылар союзына Җәлилнең тоткынлыкта язылган дистәләрчә шигыре теркәлгән блокнотны алып килгән була. Шагыйрь белән бер камерада утырган, Каршылык хәрәкәтендә катнашкан бельгияле Андре Тиммерманс та шагыйрьнең соңгы үтенечен инде үтәгән – Брюссельдәге совет илчелегенә Моабит төрмәсеннән алып чыккан шигырьләр дәфтәрен тапшырган.

Ә ЦЕНЗУРА КАРШЫ...

Шагыйрьнең шигырьләре, аларның самимилеге һәм сафлыгы – аның гаепсез булуына, какшамас рухына иң шәп дәлил кебек. Моның шулай булуына 1948–1949 нчы еллар тирәсендә «Моабит дәфтәре» белән беренче мәртәбә танышкан Константин Симонов ихлас ышана – әлеге шигырьләрне аңа бер татар язучысы күрсәткән, дип сөйлиләр. Имеш-мимешләргә, уйдырмаларга игътибар итмичә, ул шигырьләрне «Новый мир» журналында бастырырга карар кыла. Лев Френкель сүзгә-сүз тәрҗемәсен ясый, Симонов кыска гына кереш сүз яза, шигырьләрне җыярга җибәрәләр, тик цензура тик ятмый – рөхсәт юк. Симонов Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгына мөрәҗәгать итә, әмма рөхсәтне барыбер ала алмый...

Кискен борылыш – 1952 нче ел. Июльдә Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгы Татар комитетының дүртенче бүлеге башлыгы подполковник Качалов партия өлкә комитеты үтенече буенча «М.М.Җәлиловнең үлеме фактын ачыклау» максатында Мәскәүгә мөрәҗәгать итә. Якынча бер айдан соң СССР ДКМның Дүртенче бүлегеннән җавап алына. «Эзләнүченең 1944 нче елда вафат булуы сәбәпле, аңа карата ачылган оператив эзләү эше ябыла», дип хәбәр ителә анда.

ҖӘЛИЛ ҖЫРЛАРЫ ЭЗЕННӘН

1953 нче елның апрелендә, Сталинның үлеменнән соң, инде «Литературная газета»ның баш мөхәррире Константин Симонов тагын бер мәртәбә Җәлил шигырьләрен бастырып чыгарырга омтылыш ясый. Бу юлы инде главлит (ягъни цензура), тиешле органнар белән киңәшләшкәннән соң, хәбәр итә: каршы килмибез...

Соңрак «Литературка»да Җәлил шигырьләре һәм илгә аның батырлыгы турында сөйләүче мәкаләләр тагын бер тапкыр дөнья күрәчәк. 1956 нчы елның 3 мартында басма Юрий Корольковның «Җәлил җырлары эзләре буйлап» дигән мәкаләсен бирә. Берничә айдан соң, 1956 нчы елның сентябре башында, Константин Симонов үзе Бельгиядәге Кнокке дип аталган курорт шәһәрендә оештырылган Халыкара поэзия фестивалендә трибунадан Муса Җәлилнең тол калган хатынының хатын укуы турында сөйли. Анда «күренекле татар шагыйренең төрмәдә язган шигырьләренең кульъязмаларын коткарып кала алган, Муса Җәлил белән бергә фашистлар төрмәсендә тоткынлыкта булган Бельгия патриоты Андре Тиммермансның күркәм гамәле турында» язылган була. «Камерадагы күрше» дип аталган мәкаләдә Константин Симонов әңгәмәнең әдәби чигенешләрсез һәм төзәтмәләрсез бирелгән стенограммасы белән таныштыра. Әңгәмәдәш – Андре Тиммерманс – Муса Җәлилнең соңгы көннәренең шаһиты, шагыйрь турында бәяләп бетергесез мәгълүмат бирә алган кеше, язучы аны Бельгиядә эзләп таба.

...Советлар Союзы Герое (вафатыннан соң) Муса Мостафа улы Җәлиловка (Муса Җәлилгә) 1956 нчы елның февралендә бирелә. Немец-фашист басып алучылары белән көрәштә күрсәткән гаять зур батырлыгы һәм ныклыгы өчен.

Муса Җәлил

Муса Мостафа улы Җәлилов. Татар совет шагыйре, хәрби корреспондент. Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты (вафатыннан соң). Армиягә 1941 нче елның июнендә чакырыла. Өлкән политрук буларак, Ленинград һәм Волхов фронтларында көрәшә, «Отвага» газетасының хәбәрчесе була. 1942 нче елның 26 июнендә Мясной Бор авылы янында бәрелештә каты яралана һәм әсирлеккә төшә. Немецлар төзегән «Идел-Урал» легионында яшерен оешма эшендә катнаша. Яшерен оешма әгъзалары легионерларның Кызыл Армия һәм партизаннар ягына чыгуын, хәрби әсирләрнең күтәрелешен оештыра. 1943 нче елның августында, күтәрелеш булырга тиешле датага берничә көн кала, Җәлил һәм аның көрәштәшләре гестапо тарафыннан кулга алына. 1944 нче елның 25 августында Берлиндагы Плётцензее төрмәсендә гильотинада җәзалап үтерелә. Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме (вафатыннан соң) 1956 нчы елның февралендә бирелә. 1957 нче елда шагыйрьнең «Моабит дәфтәрләре» циклы Ленин премиясенә лаек була (вафатыннан соң). Җәлил исеме кече планетага бирелә, Татарстандагы бистә, илдәге күп кенә шәһәрләрнең урамнары һәм проспектлары аның исем белән атала. Татарстанда иң яхшы яшь авторларга Муса Җәлил исемендәге Республика премиясе тапшырыла.

КӨНЧЫГЫШ ФОРТ САКЧЫСЫ

44 нче укчы полкның элеккеге командиры, Брест крепосте сакчысы һәм Хаммельбург, Регенсбург немец концлагерьларының элекккеге тоткыны Пётр Гаврилов илленче еллар башында Краснодарда яши. Шәһәр кырыенда үз куллары белән вак-төяктән салынган тыйнак кына йорт, кечкенә генә хәрби пенсия (аңлашыла ки, әсирлек стажга керми) һәм күршеләрнең кыек карашлары...

ИСӘН КАЛГАНГА, ГАФУ ИТЕГЕЗ

Ярар, болай да яшәргә була. Ни дисәң дә, бу туган авылы Әлбәдәндә аны 1946 нчы елның июлендә авылдашлары каршы алуыннан яхшырак. Анда аны, немец тоткынлыгында булган кешене, халык дошманы кебек кабул итәләр. Урып-җыюда эшче куллар бик кирәк, ләкин аның ярдәменнән баш тарталар. Толлар артыннан каргыш яудыра. Питрәчкә, чүлмәк фабрикасына эшче булып китә. Аннан – бирегә, Краснодарга.

Гавриловка бәхет елмая, дияргә була. 1945 нче елның 2 маеннан соң, аларны, Регенсбург әсирләрен, америкалылар азат итә, майорны урман аударырга түгел, Башкириягә укчы полкына запаска җибәрәләр. Тикшергәннән соң, хәтта званиесен дә кире кайтаралар һәм армиядә калдыралар. Иркутск өлкәсендә аны япон хәрби әсирләре тотылган лагерьга башлык итеп билгелиләр. Партиядән чыгарылган Гавриловның (тоткынлыкта булган, партбилет югалган) хәрби карьерасын дәвам итү шансы, әлбәттә, булмый инде. Бер ел да тотмыйча демобилизациялиләр, хәтта хезмәтендәге рәхмәтләргә дә карамыйча...

Краснодарда Петр Гавриловның ни дисәң дә эше бар – станоклар төзү заводында экспедитор, ләкин алар көчкә очын-очка ялгап яши. Шулай килеп чыга: сугыштан соң ул хатыны Екатеринаны һәм уллыкка алган малаен эзләп таба алмый – алар вафат булгандыр дигән фикергә килә. Тагын бер тапкыр өйләнә, ә еллар үткәннән соң, Брестка баргач, улының исән икәнлеген, армиядә хезмәт итүен ишетә. Екатерина да исән булып чыга, тик нык авырый икән. Гаҗәп, Гавриловлар параличланган хатынны инвалидлар йортыннан үзләренә, Краснодарга, алып кайтырга карар кылалар. Үлгәнчегә кадәр аны карыйлар-тәрбиялиләр.

ҮЛГӘННӘР АРАСЫНДА ИСӘПЛӘНӘ

Ул арада язучы Сергей Смирнов Брест крепостен геройларча саклаучылар турында документаль китап язарга ниятли. Аның кулында Брест крепостеның Көнчыгыш фортын каһарманнарча саклаган кызылармиячеләр турында немец донесениеләре була, ләкин оборонада катнашучылар арасында исән калганнарны тиз генә таба алмый. Ниһаять, Смирнов Брестта Көнчыгыш фортта сугышкан элеккеге лейтенант Яков Коломиец белән очраша. Коломиец Көнчыгыш форты оборонасын оештыручы кеше турында күп сөйли, ләкин аның фамилиясен исенә төшерә алмый. Смирнов аңа сугышчыларның истәлекләре буенча төзелгән командирлар исемлеген күрсәтә. «Мин 44 нче укчы полкның элеккеге командиры майор Гаврилов фамилиясенә җиткәч, Коломиец сискәнеп китте һәм, зур ышаныч белән, Көнчыгыш форт оборонасын майор Гаврилов оештыруы турында әйтте», – дип сөйли соңрак үзенең «Брест крепосте» повестенда Сергей Смирнов.

Смирновның исемлегендә Гаврилов үлгәннәр арасында исәпләнә. Коломиец киресен сөйли: «Гаврилов үлмәде!» Язучы Генштабка запрос юллый һәм ветеранның исән икәнлегенә инана. Гавриловның адресын алганнан соң, Смирнов аңа хат яза. «Мин хатта аны ничек эзләвем турында яздым, минемчә, аның Брест крепостенда, гаять зур каһарманлык күрсәтеп, батырлык кылуын да әйттем. Илнең бу турыда ишетәчәгенә һәм геройның кыюлыгын һәм фидакарьлеген лаеклы рәвештә билгеләячәгенә озак калмаганлыгына ышанам, дип тә өстәдем».

Ике атнадан соң Петр Гаврилов һәм Сергей Смирнов очрашачаклар. Аларның әңгәмәсе берничә көнгә сузыла. Геройның партия сафларына кире кайтырга тырышып та, уңышсызлыкка очравы турында ишеткәннән соң, язучы КПСС ҮКның партия контроле комитетына мөрәҗәгать итә һәм анда майор Гавриловның нинди батырлык кылуы турында белгәннәрен сөйли. Бер үк вакытта Смирнов Петр Михайлович турында үз истәлекләрен сөйләгән барлык ветераннардан да, Гавриловның крепость оборонасында катнашуы турындагы дәлилләрен мөһер сугып үзенә җибәрүләрен сорый.

БӘХЕТ БИЮЕ

Смирнов майор Гаврилов эше тикшерелә торган партия комиссиясе утырышында катнаша, ә аның Мәскәүдәге фатирында Петр Михайлович комиссия карарын көтә.

Гаделлек тантана итүен ишеткәннән соң, Смирнов болай дип яза: «Мин 56 яшьлек олы кешенең кинәт кенә бала-чагадай, сөенечтән нишләргә белмичә, сикер-сикерә биюен күрдем...».

Майор Гавриловның батырлыгы турында язучы Сергей Смирнов беренче тапкыр илгә радиодан сөйли – «Брест крепосте геройларын эзләгәндә» дип аталган тапшырулар циклында. Соңрак Смирнов «Брест крепосте» китабының берничә бүлеген майор Гавриловка багышлый. Бу Гавриловның Көнчыгыш фортны ничек саклаулары турындагы җентекле бәяне булачак. Өзек 1941 нче елның 23 июле – сугышның утыз икенче көнендә Гавриловның соңгы бәрелешкә күтәрелүенә кадәрге вакытны үз эченә ала.

Көнчыгыш фортның соңгы саклаучысының ничек әсирлеккә төшүе турында лагерь табибы хатирәләре китерелә: «Әсир майор командир формасында иде, ләкин бөтен киеме сәләмәгә әйләнгән, битен дары сөреме каплаган, сакал-мыек баскан. Ул яраланган, аңсыз хәлдә һәм соңгы чиккә җитеп ябыккан иде. Тире белән тарттырылган коры сөяккә калган скелет кына...».

Петр Гавриловка Советлар Союзы Герое исемен 1957 нче елның 30 гыйнварында бирәләр. 1941 нче елда Брест крепосте оборонасында хәрби бурычын үрнәк рәвештә башкарганы һәм шул вакытта күрсәтелгән искиткеч зур кыюлыгы һәм каһарманлыгы өчен.

Пётр Михайлович Гаврилов

Майор, Советлар Союзы Герое, Брест крепосте оборонасында катнашучы.Казан губернасы Лаеш өязе Әлбәдән авылында (хәзер Татарстанның Питрәч районы) туган. Кызыл Армия сафларында – 1918 нче елдан. Бөек Ватан сыгышы алдыннан – Брестта урнашкан 44 нче укчы полк командиры. Немецлар Брест крепостена һөҗүм иткәннән соң, берничә подразделениедән җыелган сугышчылар төркемен җитәкли, төркем Кобрин ныгытмасының Төньяк капкалары янында сугыша. 24 июньнән Көнчыгыш форт оборонасын җитәкли. 1941 нче елның 29 июне кичендә Көнчыгыш форт бомбага тотылганнан соң, Гаврилов, төркемендә калган сугышчылар белән бергә, казематларга яшеренә һәм каршылык күрсәтүне дәвам итә. Төркем берничә көн чыгарга омтылыш ясый. 23 июльдә берүзе кала һәм авыр яраланган килеш әсир төшә. Суыштан соң Краснодарда яши һәм эшли. Васыять итеп калдырганча, Бресттагы мемориаль зыяратта күмелә. Казандагы, Бресттагы, Краснодардагы, Иркутскидагы һәм Питрәчтәге урамнар Петр Гаврилов исеме белән атала.

БЕРЕНЧЕЛӘР ВАКЫТЫ

50 нче еллар башы. Татария – илебезнең иң күп нефть запаслары урнашкан төбәге. Кыска гына вакыт эчендә биредә заманча нефть чыгару сәнәгатен булдыру бурычы тора. Республиканың моңа кадәр тыныч кына яшәгән көньяк-көнчыгышында тормыш тамырдан үзгәрә. Тиз арада меңнәрчә белгечләр: идарәчеләр, инженерлар, галимнәр, эшчеләр табарга кирәк була…

70 ел вакыт үткәннән соң «Татарстан» татар җирендә нефть сәнәгате барлыкка килүне үз күзләре белән күргән һәм бу эштә актив катнашкан кешеләр белән очрашты.

1950 ел.
СССРның Министрлар Кабинеты карары нигезендә «Татнефть» берләшмәсе оештырыла. Татарстанда беренче миллион тонна нефть чыгарыла.

1953 ел.
3 ноябрьдә РСФСРның Югары Советы Президиумы Указы белән шәһәр тибындагы Әлмәт бистәсенә шәһәр статусы бирелә.

1955 ел.
Яңа Писмән эшчеләр бистәсе Лениногорск шәһәре дип үзгәртелә.

1956 ел.
Нефть табу күләмнәре буенча «Татнефть» Советлар Союзында беренче урынга чыга.

1957 ел.
Миңлебай газ-бензин заводының беренче чираты сафка баса.

1958 ел.
Кама ярындагы Прости авылы янындагы 68нче скважинадан нефть фонтаны бәреп чыга. Нефть картасында яңа Алабуга ятмалары чыганагы барлыкка килә.

PRESSA

Фото: Александр Ефремов

АКСАКАЛ НЕФТЬЧЕЛӘР
ГАЛИМ

Габдерәшит Габдрахманов, техник фәннәр докторы, ТатНИПИнефть – нефть табу сәнәгатенең Татар дәүләт фәнни-тикшеренү һәм проект институты профессоры.

Габдерәшит Габдрахманов Азнакайда «Перекрыватель» заводындагы коллегалары белән.

БЕЛДЕРҮ ТАКТАСЫ ПЛАННАРНЫ ҮЗГӘРТТЕ

– Мин Ульяновск өлкәсендә җидееллык мәктәпне тәмамлаганда 1951 нче ел бара иде. Әти, мине Ульяновск төзелеш училищесына кертергә дип, документлар әзерләп куйган – миңа аларны тиешле адрес буенча җибәрергә генә кирәк. Шулвакыт почта каршындагы белдерү тактасына күзем төште: анда зур хәрефләр белән «Ишембай нефть техникумы түбәндәге белгечлекләр буенча студентлар кабул итә....» дип язылган, һәр белгечлек өчен стипендия күләмнәре дә күрсәтелгән. Иң күп стипендия – «Скважиналар бораулау» юнәлеше буенча! Язмыш яки бәхетле очрак булдымы икән, белмим – озак уйлап тормадым, документларымны башка конвертка салдым да, тактада күрсәтелгән адресны күчереп язып, хатны техникумга җибәрдем. Бер айдан соң керү имтиханнарына чакыру алдым.

БЕРЕНЧЕ ПРАКТИКА, БЕРЕНЧЕ ҖИҢҮ, БЕРЕНЧЕ ХЕЗМӘТ ХАКЫ...

Бораулаучы хезмәтенең асылына мин 1954 елда, өченче курсны тәмамлап, эшкә урнашканнан соң төшендем. Беренче 10 көнем – тәмуг белән бер булды – буем кыска, күчмә бишек биек, инструмент – 10 дюймлы. Канат кулдан шуа, көчем җитеп бетми – төшерү-күтәрү операцияләрен башкарганда верховой җилкәләренә бик зур авырлык килә. Бер сүз белән әйткәндә, вахта саен һәр мускулым авырта: кулларны күтәреп булмый, аяктан егылырлык булып арам. Ә бораулаучылар сүгенәләр, ашыктыралар – хезмәт хакы скважинаны тизрәк тапшыруга бәйле бит. Бораулаучы ярдәмчесе, изге җан, мине акрынлап эш алымнарына өйрәтте. 10 көннән соң мин чын верховой эшчегә әйләндем – читтән ярдәм көтеп тормый идем инде. Бу минем нефть өлкәсендә беренче җиңүем булды. Ул көннәр турында бары тик күңелле хатирәләр генә сакланып калды. Бигрәк тә ике ай эшләгән өчен беренче тапкыр хезмәт хакын алу шатлыгы истә. Ул кадәрле акчаны минем әле күргәнем юк иде. Хезмәт хакым костюм, пальто, ботинка, сәгать һәм бөтен туганнарыма бүләкләр алырга җитте.

«АРУ ОНЫТЫЛДЫ...»

Техникумны тәмамлаганнан соң, мине «Туймазыбурнефть» трестына бораулаучы итеп алдылар. Армиядән кайтканнан соң, конторада яхшы танышым Бөгелмә егете Равил Вахитовны очраттым. Бу очрашу минем тормышымны тагын бер тапкыр үзгәртте. Ул мине Бөгелмәгә китәргә күндерде, ә анда 1956 елдан соң Василий Еронин җитәкчелегендә ТатНИИ оеша башлаган иде.

Еронин командасы бөтен ил буенча нефть белән бәйле алдынгы галимнәрне үзенә җыя. Аларның һәрберсе – сәләтле һәм максатчан кешеләр. Кичекмәстән хәл итәргә кирәкле сораулар һәм мәсьәләләр дә җитәрлек иде. Безгә көнетөне эшләргә кирәк булды. Институт үзенең белгечләре, нефть сәнәгате белән бергә үсте.

Галимнәрнең бораулау урыннарына барып эшләве аерым игътибарга лаек. Мәсәлән, нефть чыгаручыларның үзләре генә хәл итә алмаган берәр проблемасы бар, ди. Бу очракта сызымнар ясау, исәпләүләр үткәрү, тәҗрибә эшләнмәләрен стендларда сынап карау белән генә чикләнеп булмый, скважинага барырга туры килә. Тәҗрибә эшләрен урында ук үткәрәбез. Ә алар берничә тәүлек дәвам итәргә мөмкин. Ул елларда болай эшләү җиңел түгел иде. Будка бораулаучы остада гына бар. Төннәрен йокы капчыгында яки автобуста үткәрергә туры килә. Өйгә кайтсаң да, тизрәк кибеткә йөгерергә кирәк. Анда да томаттагы килька консервасы һәм прәннек кенә саталар. Башка бернәрсә дә юк... Ә иң мөһиме, бик каты йокы килә, ә йокларга урын юк. Сирәк кенә булса да, бораулаучы остаң өстәле янында бераз черем итеп алу бәхете эләгә. Шулай да, беләсезме, авырлыклар истә калмый икән. Тәҗрибә уңышлы килеп чыкса, алар шул вакытта ук онытыла. Эш уңгач була торган шатлык һәм горурлык хисләре йөз, мең тапкыр кадерлерәк!

Фото: Александр Ефремов

АКСАКАЛ НЕФТЬЧЕЛӘР

БОРАУЛАУЧЫ

Николай Федотов, «Әлмәтбурнефть»нең элеккеге бораулау остасы, Бөек Ватан сугышы ветераны.

– Нефтьчеләр янына мин, үзем кебек үк фронтовиклар белән бергә, 1948 елда эләктем. «Туймазыбурнефть» трестында булды бу хәл, анда безне Валентин Шашин кабул итте. Соңыннан «Татнефть» берләшмәсе җитәкчесе һәм СССРның нефть сәнәгате министры булган кеше. Ә ул чакта Валентин Шашин «Башнефтеразведка»да баш инженер иде. Безне, 12 кешене, кабинетына кертеп утыртты да: «Егетләр, безнең алда зур һәм катлаулы бурыч тора. Әзер булсагыз, без фронтовикларны үз рәтләребезгә бик теләп алабыз. Сез – ышанычлы кешеләр», – диде. Без эшкә тотынырга иртәгә үк әзер, ләкин колхоздан җибәрмиләр, документларны бирмиләр, дибез. Валентин Дмитриевич елмаеп: «Борчылмагыз, хәл итәрбез», – диде.

Берничә көннән без Октябрь шәһәрендәге бораулаучылар өчен махсус оештырылган мәктәптә укый башлаган идек инде. Озак та үтмәде, мин Баулы районындагы Исергәп авылы янындагы разведка бораулау скважинасында легендар шәхес Мотаһар Фатыйх улы җитәкчелегендә эшли башладым. Шул вакытта мин беренче тапкыр «нефтьче» премиясен алдым. Хатынга тегү машинасы алып кайттым. Сүз уңаеннан, бүген яши торган йортым миңа, мирас булып, 1956 елда Мотаһар Фатыйх улыннан калды.

Исергәптә без фатирда яшәдек, ашамлыклар, кирәк–яраклар алырга дип Баулыга кадәр 12 километр ара бара идек. Ул елларда Баулыда бик зур үзгәрешләр башланды – бөтен җирдә нефть вышкалары калкып чыга, факеллар кабына. Утын юк, солярканы бензин белән кушып, керогазда ашарга пешерәбез. Продуктларга кытлык, ярый әле без хатын белән икебез дә авыл кешеләре. Ул мәктәптә укытучы булып эшли, ә мәктәпнең бакчасы бар. Анда бәрәңге, башка яшелчәләр утырттык. Ашарга җитешмәгән авыр чаклар... Бервакыт шулай Баулы бораулау конторасы җитәкчесенең гомуми мәсьәләләр буенча урынбасары һәр бораулаучыга берәр капчык арыш оны алып килде. Иң кирәкле әйбер иде ул!

Исергәптән ерак түгел Кызылъяр авылында әсир немецлар яши иде. Хатын белән минем өйдә бер карават булуын гына белгәч, алар безгә өстәл һәм ике урындык ясап бирде. Ә безнең ул елны бәрәңге унды. Озын сүзнең кыскасы, без аларга капчыкка салып берничә чиләк бәрәңге бирдек, алар шундый бәхетле булып кайтып киттеләр. Үзенә күрә алыш-биреш булды... Ул чакта немецлар белән белән безнең арада бернинди дошманлык калмаган иде. Алар көче белән безнең якларда күп нәрсәләр төзелде: юллар, йортлар һәм күперләр.

КҮЧЕП ЙӨРҮЛӘР – ГАДӘТИ ХӘЛ

Без 8 әр сәгатьлек 3 сменада эшли идек, моннан тыш, өстәмә вахта хезмәте дә бар. Бер скважинаны тапшыруга, икенчесенә күченәсең. Аннары Баулыда эшләдем, анда ике гаиләлек фин йортларында яшәдек. Күршедәге бораулау мастеры Сергей Баклушин мине үзенең бригадасына дәште, һәм без 1952 елда Әлмәткә, Мактама бораулау конторасына күченеп килдек. Тагын шул торак өчен акча түләп тору башланды. Ләкин тиздән бораулаучылар өчен Тихонов товар паркы янында 2 барак төзеп куйдылар. 12 гаиләгә – бер уртак кухня! Шулай да бер генә гауга-кычкырыш та булмады, дус һәм күңелле яшәдек, һәр бәйрәмне бергәләп үткәрә идек.

Әлмәт акрынлап үсте, нефтьчеләр өчен дә торак төзелә башлады. Без анда килгәндә Бигаштан Иске Әлмәткә кадәр буш урыннарга йортлар салынган иде. Бөтен җирдә – бараклар, бараклар, бараклар. Кайбер урыннарда гына ашханәләр, нефтьче конторалары һәм ике катлы йортлар.

Бүгенге Ленин урамы күпкә соңрак барлыкка килде, ул тулысынча Чупай карьерыннан китерелгән таштан төзелде.

ШУНДЫЙ ХӘЛЛӘР ДӘ БУЛГАЛЫЙ...

1954 елда безнең гаиләгә аерым фатир бирделәр. Шул елларда нефтьчеләр өчен махсус кием дә бирә башладылар. Күз алдыгызга гына китерегез, кышка тун бирделәр! Бервакыт бораулау урынында туным юешләнде. Сменадан кайтуга, мин аны киптерер өчен уртак коридордагы баскыч култыксасына элеп куйдым. Иртән торып карасам, тунымнан җилләр искән!

ЛОМ БЕЛӘН КУВАЛДА ЯРДӘМГӘ КИЛӘ

Безнең мастер, Сергей Данилович, танылган булмаса да, үз эшен яхшы белүче һәм киң күңелле фронтовик иде. Скважиналарны бораулауны һәрвакыт иртәрәк тәмамлый идек. Бу – премия дигән сүз. Ләкин акчага алырга әйбер юк – сатуда азык-төлеккә дә, яхшы киемгә дә кытлык. Хатын, бәхет елмайса, берәр кисәк колбаса сатып ала. Аны балаларга ашатырга түгел, миңа эшкә биреп җибәрергә тота.

Безгә барысын да үзебезгә эшләргә туры килде, кул астында – лом белән кувалда гына. Бораулау өчен балчык эретмәсе кулланабыз. Җәй көне күпләп балчык китерәләр, көзен аны яңгыр юешли. Кышын шуны кувалда белән ватып ташыйбыз. Бораулый башлаганчы, болгату машинасында 120 кубометр эретмә ясарга кирәк. Бораулау урыны Әлмәттән 5 километрдан якынрак урнашса, сменага җәяү барырга туры килә иде, бернинди дә вахта автобуслары йөрми. Ашханәләр дә юк. Бу уңайлыклар соңрак кына булды. Аңа карап, берәү дә зарланмады. Без бит ир-атлар.

Белмим инде, тормышыбыз җиңел булмаса да, авырлыклардан курку хисе булмады. Курыксак, балалар да тапмаган булыр идек. Ә алар минем бишәү...



Николай Афанасьевич кызы Надежда белән.

PRESSA

Фото: Александр Ефремов

АКСАКАЛ НЕФТЬЧЕЛӘР ТӨЗҮЧЕ

Шәһит Таипов, «Әлмәтнефть» нефть һәм газ идарәсе җитәкчесе урынбасары, «Татнефть»нең капиталь төзелеш бүлеге җитәкчесе.

ӘНИ, РӘХМӘТ!

– Мин әтисез үстем – ул 1938 елның февралендә репрессиягә дучар була. Әни бөтен көчен безне, биш улын, үстерүгә куйды. Нәкъ менә ул мине унъеллык мәктәпне тәмамларга күндерде, ә ул вакытта өлкән сыйныфларда уку елына 150 сум тора иде. Шундый хәерчелектә яшәп, ничек шулкадәр акча таба алган икән әни, дип шаккатам хәзер. Мәктәптән соң мин нефтьче булырга карар кылдым. Миңа бу вакытта 17 яшь иде, ә бораулаучыга 18 яшьтән генә кабул итәләр. Ләкин эшкә, киләчәктә укырга бару шарты белән, алалар. Шулай итеп, бораулаучы ярдәмчесе курсларын үтеп, мин бораулаучы эшче булып эшли башладым. Ә 1955 елның көзендә, тагын әнинең үгетләве буенча, Уфа нефть институты студенты булдым. Диплом эшен яклаганнан соң, Әлмәткә, «Әлмәтнефть»кә килдем.

МӨНӘСӘБӘТЛӘР КЕШЕЛЕКЛЕ БУЛЫРГА ТИЕШ

Мин эләккән икенче нефть сәнәгате җитәкчесе Геннадий Рябов оста нефтьче, фронтовик иде. Ул мине, яшь белгечне, бик җылы каршы алды. Нефтьчеләрнең хезмәт шартлары, Татарстан нефте барлыкка килү тарихы, нефть чыгару үсеше проблемалары һәм аларны хәл итү бурычлары турында сөйләде. Җитәкче кешенең нинди-дер бер чыгарылыш укучысы өчен шулкадәр вакытын сарыф итүе – хәзерге вакытта сирәк күренеш.

Минем Әлмәттән әни һәм 7 нче сыйныф укучысы булган энем белән килгәнне белгәч, Геннадий Иванович торак белән ярдәм итәргә вәгъдә итте. 2 ай эшләгәннән соң, миңа 2 бүлмәле фатир бирделәр. Ул вакытта мондый хәл гадәти күренеш дип, уйламагыз. Торак алу өчен еллар буе эшләргә кирәк иде. Минем беренче җитәкчем хәйрияче түгел, ә акыллы кеше булган. Шул рәвешле, ул минем тылны ныгытып куйды. Хәзер миңа эш вакытында туганнар турында кайгыртырга кирәкми иде.

Бу очрактан соң мин акыллы һәм алдан уйлап эшләнгән гамәлләрнең, һичшиксез, нәтиҗәле булачагына инандым. Шулай итеп кенә үз тормышыңны яки син ярдәм кулы сузган кешенең язмышын яхшы якка үзгәртергә мөмкин...

АКСАКАЛ НЕФТЬЧЕЛӘР

Безнең чор нефтьчеләренә берьюлы ремонтчы, монтажчы, электрчы, йөк ташучы, слесарь һәм җир казучы да булырга туры килде. Шул ук вакытта безгә техника, торак һәм ашау җитмәде. Юллар да начар иде: кыш көне операторлар – чаңгыда, җәй көне җәяү йөрде, кайбер вакытта юлда машина очрап, утырып бару бәхете елмая иде. Эшкә өйрәнү дә шулай аягүрә генә булды.

Нефть эшенең бөтен нечкәлекләрен яшьләргә «аксакаллар» өйрәтте. Ул еллардагы барлык операторларны да мин исем-отчествовалары буенча хәтерлим. Соңрак бергә эшләгән хезмәттәшләремне онытсам да, өлкән буыннар исемдә. Аларның күбесе арабызда юк инде, хәзер мин геройларның ешрак тыйнак һәм гади булганнары турында беләм.

Алар скважиналарны карап йөреп, бер сменага дистәләрчә километр үтәләр иде. 60 нчы елларда без эшкә төгәллек кертү өчен җир асты трассалары белән скважиналар күрсәтелгән карта-схема төзи башладык, шулвакыт аларның тәҗрибәсе бик кирәк булды. Хәзер генә ул башта проект ясап, аннары аның буенча төзиләр. Элек алай түгел иде. Нефть суыру системасы буенча берминди документация юк – нефть торбалары, нефть үткәргечләре, су һәм газ үткәргечләре каян үткәне билгеләнмәгән. Ә 50 нче еллар нефтьчеләре боларның барысын да белә. Менә шундый оста белгечләр, үз эшенең яхшы мәгънәдәге «монстрлары» хезмәт итте ул вакытта. Фанатизм чигендә эшлиләр иде...



Фото: Солтан Исхаков

PRESSA

Фото: Александр Ефремов

АКСАКАЛ НЕФТЬЧЕЛӘР

НЕФТЬ ТАБУЧЫ

Нәфис Фәйзуллин, «Азнакайнефть» нефть һәм газ идарәсендә нефть табу мастеры, Ленин ордены кавалеры.

– Мин Бөгелмә тимер юлы училищесын бетердем. Фронтовиклар сугыштан әйләнеп кайтуга, тимер юл тулысынча кадрлар белән тәэмин ителгән иде. Ярый әле республикада нефть сәнәгате торгызылды. Тимер юл техникумында укыган берничә егет Лениногорск районы Ромашкинодан иде. Бервакыт алар, чираттагы тапкыр эти-әниләре яныннан килгәннән соң, берсеннән-берсе уздырып үзләренә чакыра башлады: «Безнең авыл янында ук нефть суырталар, әйдәгез шунда урнашабыз. Барыбер тимер юлда безгә эшләргә урын юк», – диләр.

Икенче көнгә үк без училище директоры янына: «Безне Ромашкинога җибәрегез!» – дип кердек. Иртәнге построениедә директор телөге булган 18 кешегә барып өчен машинада урыннар җиһазларга кушты. Алар арасында мин дә бар идем. Бүгенгедәй хәтеремдә: 1949 елның 20 июле иде. Ромашкинода безне 3 нче нефть табу идарәсенең беренче директоры Рәфхәт Миңгәрәев каршы алды. Ерак булмаган барак-конторага озатты. Һәрберебезнең каян килгәне, ата-аналарыбыз турында сорашты. Нефтьнең нәрсә икәнен, аны ничек чыгару турында сөйләде. Бер сүз белән әйткәндә, ике як өчен дә отышлы булды: без икенче көнгә үк легендар 3 нче скважинада эшли башладык.

Кичен – теория, көндез – практика. Көн саен траншеялар казу кебек җир эшләрен башкара алганнарны инде ике айдан соң ук 4 нче разряд буенча эшкә алдылар. Бер елдан соң, 17 яшьтә миңа 5 нче оператор разрядын бирделәр, ә 1951 елның язында мин 6нчы разряд буенча эшли идем инде.

СКВАЖИНА АРТЫННАН СКВАЖИНА...

Шулвакыт мине Азнакай районының Йолдыз авылына 31 нче скважинага өлкән оператор итеп җибәрделәр. Кечкенә булса да, җитәкче идем. Үз бригадамны җыеп, аны эшкә өйрәтергә туры килде. Бораулаучылардан скважинаны кабул итү белән, без калдык-постык такталардан будка ясадык, землянка казыдык – үзенә күрә яшәү өчен урын хәстәрләп куйдык. Ул вакытта бүгенге көндәге кебек йортлар операторларның төшләренә дә керми иде, хезмәт шартлары турында сөйләп тә торасы түгел. Эш авыр – сөялләр канаганчы күтәрергә-төшерергә, скважинаны парафиннан чистартырга туры килә. Һәр ике сәгать саен шулай. Кул белән эшлибез. Көн һәм төн. Шулай эшләмәсәң, торба тыгыла, димәк, аннары җир астында ремонт үткәрергә һәм эшне туктатып торырга туры киләчәк. Яшь операторларны өйрәтеп бетергәч, мине Азнакайдагы әле генә бораулаган 543 нче скважинага күчерделәр. Тагын күчену, тагын шулай ук кабатлана...

1954 елдан башлап без көн саен диярлек бораулап бетерелгән скважиналарны кабул итә, аларны эшләтеп җибәрә идек... Җитәкчелеккә бу хакта хәбәр итеп тордык. Бернинди ял, бәйрәм юк. Ул вакытта минем эш һәм тормыш, башка бөтен нефтьчеләрне кебек үк, каторгага тиң иде. Аеруча кыш көннәре авыр булды. Өйдән алган чәй тутырылган шешә, күп очракта суына, бозланыпката. Еш кына ашап-эчеп алырга да онытыла.

НЕФТЬ ӨЧЕН КӨРӘШ

Бервакыт Азнакайдан Карабашка 40 атмосфера басымы белән нефть куучы скважинада насос эштән чыкты. Эшләми генә бит! Эзләгәч, сәбәбен таптык – насос эчендәге поршеньнең манжеты тузган. Урамда 30 градус салкын, ләкин башка чара юк. Скважинаны вакытлыча туктатып тордык. Зур ачкычлар белән эшләргә туры килде. Сүтеп-ремонтлаганчы 2 сәгатьләп вакыт үтте. Кулда юка гына бияләйләр, калыны белән эшләп тә булмый. Шулвакыт минем куллар өшеде дә инде.

Хастаханәгә килгәч, хирург: «Бармакларсыз каласың», – дип әйтте. Ул вакытта миңа тормыш беткән кебек тоелды. Әни килде. Бармакларыма каз мае, тагын әллә нинди мазьлар сөртте, үләннәр эчерде. Бармакларым, кәкре булса да, исән калды. Куллар да эшли. Әле дә көчләре бар әле!

Мондый тарихлар күп булды. Иң кызыгы, шундый мизгелләрдә, киләчәктә нәрсә булачагы турында уйлап та карамаганбыз. Нефть өчен фидакарьләрчә көрәштек. Иң мөһиме – туктарга ярамады. «Булдыра алмыйм», «куркам», «мин моны эшләргә тиеш түгел» дигән сүзләр – безнең буынга бөтенләй туры килми.

Фото: Солтан Исхаков



СУ БАСЫМЫ АСТЫНДА

Куйбышев гироэлектростанциясе илне арзанлы энергия белән тәэмин итү максатында төзелә. Әмма аның төзелеше Идел буе өчен ул бик кыйммәткә төшә. ТАССРда гына да 149 торак пункт тулысынча яки өлешчә су астында кала. Алар белән бергә никадәр чәчәкле болыннар, печән җирләре, уңдырышлы чәчүлекләр әрәм була...

Автор:
Катерина Котова

БАШКАЛАНЫ САКЛАП

Аяклар тубыктан комда, кулларда көрәк, башларда – ак яулык, миһербансыз кояштан башкача ничек сакланып булсын тагын? Хезмәт бик авыр, хатын-кызлар монда бөтенләй булмаска тиеш кебек. Әмма хәбәрченең объективы нәкъ менә аларга төбәлгән. Казан дамбасы төзелешендә эшлиләр. Әйе, әйе, су басу республикабыз башкаласын да читләтеп үтми! Шәһәребезнең бер өлеше су астында калмасын өчен, дамбалар системасын булдырырга, дренаж каналлары төзергә, яңа насос станцияләрен сафка бастырырга туры килә...

Төрле чыганакларга караганда, шәһәрне саклау өчен 300 миллионнан алып 1 миллиард сумга кадәр акча бүлеп бирелгән булган – аз түгел! 14 миллион сум тирәсе – Казан Кремле, һәлак булган сугышчылар һәйкәле һәм башка тарихи объектларга зыян килмәсен өчен карала. Моннан тыш, сүүткәргечләр, канализация челтәрен, трамвай юлларын, меңнәрчә йортны һәм башка корылмаларны күчерергә туры килде! Аларның барысына да су басу яный. Өстәвенә, су күләме Иделдә генә түгел, кече елгаларда да артырга мөмкин. Әйтик, Казансуның биеклеге аерым бер урыннарда 11 метрга күтәрелә, ә Горький исемендәге парк янындагы суның киңлеге 2 километрдан арта.

Бу эшләрдән соң тышкы кыяфәте шактый үзгәргән Казанга берәр файда каламы соң? Беренчедән, шактый зур акватория, аны хәзер республика мөмкин кадәр үзенә отышлы итеп куллана ала. Яңа Казан порты Иделнең әйдәп баручы предприятиеләренең берсенә әйләнә. Фаразланган план күрсәткечләрен ул 1962 елда ук үтәп, тоткан чыгымнарын 6 ел эчендә каплый ала. Шәһәрдә пристаньнар саны өч тапкыр арта.

Икенчедән, Идел шәһәргә кадәр килеп җитә, ә моңарчы елга белән башкала арасында ераклык 4 километр булган! Хәзер инде Казан – судагы шәһәр, һәм моның икътисадый гына түгел, ә эстетик яктан да файдасы зур.

БӨЕК КҮЧЕНҮ

Зоя Лешеваның туган авылы Болгар* бу көннәрдә туздырылган умарта оясын хәтерләтә. Туган җирләре, өлешчә булса да, «су басу зонасы»на кертелә. Бөтен кеше йөгерә, ыгы-зыгы килә, бүрәнәләп йортларын сүтәләр һәм булган мал-мөлкәтләрен җыйныйлар. Тату халык яши бирәдә. Күченү дә бергә бара. Ләкин туган җирләрдән берсенең дә китәсе килми. Хәер, гади кешенең теләкләре, уй-фикерләре берәүне

ФАКТЛАР ГЫНА. СУ БАСУ ЕЛЬЯЗМАСЫ

Кайбер мәгълүматлар буенча, 1952 ел башына су басу зонасы исемлегендә тулысынча суга батачак – 4511, өлешчә су керәчәк 2137 йорт булган. Соңрак инде башка саннар күрсәтелә: республикага 12 меңгә якын йортны күчерергә туры килә – бу 50 мең кеше дигән сүз. Бу теманы өйрәнүчеләр фикеренчә, ул чакта су басуның реаль масштабларын аңлаучылар аз булган. Кайбер мәгълүматларга караганда, Татарстанда 290 мең гектардан артык мәйданны су басарга тиеш булган. Аеруча Лаеш, Куйбышев һәм Алексеевск районнары җирләре зыян күрер, дип фаразланган. Мәсәлән, Лаеш районында колхоз печән җирләренең 93 проценттан артыгын су астында калдыру күздә тотыла. 16 райондагы йорт яны участоклары да куркыныч астында тора. Ничек кенә булмасын, күченү эшләре 149 авыл торак пунктында башкарыла. Гадәттә, күченү өчен яңа урыннар яшәүчеләр ризалыгы белән сайлана. Әмма башкарма комитетлар тарафыннан еш кына бу шартлар үтәлми.

Кешеләрне һәм хуҗалыкларны күчерүдән тыш, су басу алдыннан урманнарны да «чистартырга» кирәк. Бу мәсьәләләр буенча аңлашылмаучанлыклар күп була. Су киләчәк мәйданнарның төгәл күләме билгеле булмаса да, ел саен Татарстанда урман кисү һәм аны ташу эшенә меңләгән кеше җәлеп ителә.

дә артык кызыксындырмый. Авыл сусаклагыч сулары астында калырга тиеш булганга, иртәме-соңмы барыбер күченергә кирәк.

Борчылу, чарасызлык, каушау – күченеп китүне көткән кешеләр арасында шундый кәеф хөкем сөрә ул вакытта. Хәер, үзгәрешләрне җиңел кабул итүчеләр дә була. Махсус комиссия милекне бәяли, аннан соң күченүчеләргә акча һәм яңа урын бирелә, еш кына ул – чиста кырда, кече Ватаннан егерме-утыз километр ераклыкта урнаша. Йортларын сүткән кешеләргә бүрәнәләрен күчереп бирәләр, башкаларга яңадан өй салырга кирәк була. Кайсыбер материалларны бушка бирәләр, ләкин күп очракта чарасын үзеңә күрергә туры килә. Бүрәнәгә дә акча җитмәгән чак – йорт салам дип терлек суючылар күп була.

Бик күп архив документларын өйрәнгән тарихчы Евгений Бурдин күченеп китүнең авырдан башлануы турында әйтә. 1952 елның 20 июненә су басу зонасыннан бер генә гаилә дә күчеп китми. Аларның берсенә дә дәүләт тәкъдим иткән яңа урыннар ошамый чөнки. Әйтик, Алексеевск районының Бурцево авылында яшәүчеләр Кече Кызыл Яр авылына күчәргә каршы тора. Лаеш районының Татар Агайбашы халкы 35 километр ераклыктагы Державиногa күчүдән баш тарта. Аларның балалары хәзер кайда яши икән? Архивларда бу турыда мәгълүмат юк.

Шулай ук су басу зонасына эләккән Ново-Мордово авылында, нигездә, оста котельщиклар, столярлар, слесарьлар яши. Шуларның берсе – Василий Еремин. «Яшьләр заводта эшләде, исерекләр булмады», – дип сөйли ул. Зур күченү елларында бөтен Идел буйлап вербовщиклар йөри башлый. Эшчеләр, завод белгечләре, алар белән килешүләр төзеп, даими яшәү өчен башка районнарга китә башлый, Самара астындагы

Биш ел эчендә Куйбышев ГЭСнең гидроузелын гына түгел, плотинасын да төзергә, гаять зур территорияне су астында калдырырга әзерләргә дә кирәк була. ТАССРда 149 торак пункттагы халыкны башка җирләргә күчереп утыртырга туры килә.

1950нче еллар

Хәбәрченең объективында – хатын-кызлар. Казан дамбасын төзүдә катнаша. Шәһәрнең бер өлеше су астында калмасын өчен, саклану корылмалары системасын төзергә туры килә.

Поджабный, Саратов өлкәсенең Алексеевка эшчеләр бистәсенә, Куйбышев өлкәсенең Сухая Речка җирлегенә... Шулай итеп Татарстан акрынлап кадрларын югалта.

Сүз уңаеннан, су басу зонасына авыллар һәм бистәләр генә түгел, кайбер шәһәрләр дә эләгә. Шуларның берсе – Куйбышев (элеккеге исеме – Спас). Анда яшәгән Сара Миличихина истәлекләре буенча, яңа урында бернәрсә дә булмый, шул исәптән – хастаханәләр дә. Мондый хәл халыкны күчүдән баш тартырга этәрә. «Еладык, китәргә теләмәдек. Тол хатыннар күп иде, аларга бигрәк тә куркыныч, ялгызларга кем ярдәм кулы сузар? Төп кыенлык кешеләрне күченергә күндерү булды. Моның өчен хакимият кызыксындыру чарасы уйлап тапты: яшь укытучыларны җыеп, аларга шарт куйды: әгәр барырга ризалашсагыз, ике айдан соң яңа урында фатир бирәбез, диделәр». Түрәләр нәрсә эшләгәнен белә: укытучылар – хөрмәтле кешеләр, алар күченсә, башкалар да ияречәк.

Күченү эше эзлекле бара, урам артыннан урам китә. Нәтиҗәдә, Куйбышев бөтенләй бушап кала. Кешеләр белән бергә яңа урынга йортлар, кибет, мәктәп кенә түгел, хәтта юллардан һәм урамнардан ташлар, биналарны сүтүдән калган иске материаллар да ташыла. Барысының да кирәге чыга.

Куйбышев халкы яңа урынга килеп карагач, шакката: тирә-якта кыр, берән-сәрән йортлар күренә. Сара Миличихина сүзләренә караганда, кешеләр яңа урынга 30 августта килеп җитә, ә 1 сентябрьдә мәктәптә дәресләр башланырга тиеш була. «Мәктәп төзелеп бетмәгән иде – түбәсе дә, тәрәзәләре дә юк. Бу типлаштырылган мәктәп бинасы иске шәһәрдән күчерелгән була. Яшәргә урын юк, укытучылар өчен каралган кечкенә бүлмәдә төн кунып йөрдек. Анда диван бар, берничә кеше шунда йоклый».

Хакимият кешеләрне күченергә күндерү өчен әллә нинди хәйләләргә бара. Туган якны өйрәнүче Леонид Абрамов еш кына Ржавец авылын искә ала, анда, Болгар тирәсендәге су басу зонасына эләккән авыллардан җыелган барлык борынгы иконалар саклана. Бу гына да түгел. Ново-Мордово авылында 1861 елда төзелгән Троицк чиркәве дә су басу зонасына эләгә. Авыл халкы бу турыда белгәч, Ржавец шәһәрендә үзләренең изге урыннары хөрмәтенә Троицкий

ФАКТЛАР ГЫНА.
СУ БАСУ ЕЛЪЯЗМАСЫ

Менә 1955 елның 31 октябре килеп җитә. Идел инде ябылган. Куйбышев сусаклагычын тутыру башлана. 29 декабрьдә ГЭСның беренче гидроагрегаты эшли башлый; соңгысы, егерменчесе, 1957 елның октябрендә эшкә керешә. Су тиз тула, әмма аңа дип исәпләнгән мәйданнар бик зур. Планлаштырылган күләменә сусаклагыч 1957 елның июненә генә ирешә. 1958 елның 9 августында Хрущев рәислегендәге Хөкүмәт комиссиясе тантаналы шартларда гигант корылманы кабул итү актына кул куя. Бу турыда әйдәп баручы совет массакүләм мәгълүмат чаралары гына түгел, ә дөньякүләм журналистика да хәбәр итә. Генсек тонналаган суның 25 метр биеклектән аска ыргылуын күрсен өчен, плотинаны ачканда махсус 250 тонналык кран кулланыла. Сүз уңаеннан, шаһитларның истәлекләре буенча, төзүчеләрне генсекның сәламләү сүзе гаҗәпкә калдыра: анда биш ел эчендә башкарып чыккан гаять зур, бик авыр хезмәт өчен бер генә рәхмәт сүзе дә булмый. Идел ГЭСлары каскадында әһәмиятле урын алып тора, илебезнең мәйданы 6 мең квадрат километрдан артып киткән иң зур сусаклагычларының берсен төзү елъязмасы әнә шулай тәмамлана.



гыйбадәтханәсен төзергә рөхсәт сорый. Хакимият ризалаша.

СУ АСТЫНА КҮМЕЛГӘН

Ул төнне Анастасия Трусованың мәңге онытасы юк. Аңа бушап калган туган авылы Пичкассыга әйләнеп кайтырга туры килә – сарайда мал-туар калган була. Төн кунарга дип ниятләсә дә, булдыра алмый. «Шулкадәр курку басты, кире йөгереп кайттым», – ди ул. Тирә-юньдә яңгырап торган тынлык – ә кайчандыр тормыш кайный иде! Зур су ташуын көтеп барысы да катып калган. Монда елганың биеклеге 28 метрга күтәрелергә тиеш иде.

Су күтәрелгәч, өскә сусаклагыч урынын әзерләү җитешсезлекләре генә түгел (кешеләр хәтта зиратлардан юылган табутларның Идел буйлап йөзеп йөрүен дә искә ала), проект ясаучыларның хаталарын да өскә чыгара. Пичкассы авылын беренче елларда гына су баса, аннары китә. Су килеп тә җитмәгән күпме ташландык җирләр кала! Бу хакта белгәч, кешеләр таланган, бушаган туган якларына кире әйләнеп кайталар. Әйтик, Спас район газетасында Куйбышевның иске өлешен су басканнан соң коры калган урында төпләнеп яшәгән ике «робинзон» турында материал дөнья күрә. Алар землянкаларда көн итә, балык белән туклана, хәтта мал-туар да асрый... Шунысы кызык: Евгений Бурдин архивларда «робинзоннар» турында мәгълүматларны эзләп таба һәм аларның су басу зонасыннан куәтдән баш тарткан элеккеге Куйбышев кешеләре булуын ачыклый. «1957 елның кыш һәм яз айларында, аларны мәҗбүри рәвештә күчерергә теләгәндә, иске шәһәрдә инде беркем дә булмый, биналарның күбесе күчерелгән, калганнары яндырылган яки җимерелгән, аеруча нык биналарның кирпеч диварлары гына торып калган була. Гомер буе шушында гомер иткән кешеләргә туган җирләренең һәлак булуын күреп тору никадәр авыр булуын күз алдына да китереп булмый», – дип яза туган якны өйрәнүче. Сүз уңаеннан, су басмаган ташландык авыллар, бистәләр, шәһәрчекләрнең кайберләренә бүген дә килүчеләр бар, алар – кайчандыр бирегә яшәгәннәрнең балалары, оныклары.

БАТЫРЛЫК НӘТИҖӘЛӘРЕ

Зур төзелеш нәтиҗәләренә карата бүген мөнәсәбәт төрле. Бер яктан, мондый зур су күләме Татарстанны диңгез ярына әйләндерде диярлек. Уңай яклар арасында икътисадый файда да, узган гасыр башында ук шактый зур зыян китергән су ташуларының булмавы да бар. Моннан тыш, кайбер экологлар су биеклеген күтәрү елгаларыбызны төрле индустриаль пычрануылардан саклый дигән фикердә.

Икенче яктан, күп кенә белгечләр ГЭС эшләтеп җибәрүнең һәм зур күләмдәге коры мәйданнарны су басуның нәтиҗәләре тискәре булган, дип уйлый. Күчеп китәргә мәҗбүр ителүчеләрнең яшәү рәвеше бозылуга, зур территорияне су басуга бәйле экология һәм микроклиматның үзгәрүе дә яхшы түгел. Авыл һәм урман хуҗалыгы, терлекчелек өчен дә кыйммәтле җирләр су астында кала. Ярлар юыла. Иделдә агым тизлеге кими, бу акрынлап аның ләмләнүенә китерә. Елганың төр ягыннан флорасы һәм фаунасы үзгәрә, өстәвенә плотиналар уылдык чәчү өчен йөзүче балыкларга киртә булып тора. Моннан тыш, кайбер галимнәр сейсмик активлыкның артуы турында да сөйли... Әйе, кешенең табигатькә шул рәвешле нык тыкшынуы сирәк очракта гына көтелгән нәтиҗәләргә китерә. ■

Бүген әлеге гигант төзелешнең нәтиҗәләрен бер яклы гына бәяләмиләр. Кешенең табигатькә мондый көчле йогынтысының нәтиҗәләре бик аз очракта гына көтелгәнчә һәм бертөрле генә була...

* А. Черкасовның «Спасск-Куйбышев-Болгар – свидетель времен и судеб» эше өчен тупланган истәлекләре файдаланылды.

ГАБДЕРӘХИМ УТЫЗ ИМӘНИ ӘЛ-БОЛГАРИ: МИЛЛӘТНЕҢ РУХ САГЫНДА

«ТАТАРСТАН» журналы өчен МАХСУС

Казан ханлыгы алынганнан соң (1552 ел) татарларга каршы Россия дәүләте тарафыннан алып барыла торган сәясәтнең төп максаты ислам динен генә түгел, бәлки халыкның үзен, беренче чиратта, аның гасырлар буена тупланган, калыплашкан рухи мәдәниятен дә юкка чыгару иде. Шул максатны тормышка ашыруда рус хөкүмәте бик тырышып эшләде: татарларның иң алдынгы, бай һәм зыялы катламын юк итте, мәчет-мәдрәсәләр җимертелде, мөселманнарны көчләп христианлаштыру процессы башланды. Бу шартларда татар милли культурасының үсеше турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде. Бераз җанлану кабат XVIII йөзнең икенче яртысында гына башлана.

Күренекле шагыйрь, мәгърифәтче, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Габдерәхим Утыз Имәни иҗаты XVIII–XIX гасырлар татар әдәбиятында аерым бер урын алып тора. Утыз Имәнинең иҗат мирасы зур һәм күпкырлы. Ул барлыгы 100дән артык исемдә хезмәт язган. Безгә шуларның 60 исемдәгесе генә килеп җиткән. Аларның яртысыннан күбрәге, ягъни 31е – шигъри әсәрләр, калганнары – төрле өлкәләрдәге фәнни хезмәтләр, сүзлекләр һәм үз кулы белән күчереп язылган китаплар.

ТОРМЫШ ЮЛЫ

Габдерәхим 1754 елда хәзерге Чирмешән районы Утыз Имән авылында ярлы игенче гаиләсендә туган. Әтисе Госман (хәзерге Лениногорск районындагы Тимәш авылы кешесе) улы туганчы ук үлеп киткән. Ярдәмчесез калган әнисе Гафифә үзенең туган авылы Утыз Имәнгә әйләнеп кайткан. Габдерәхим шунда дөньяга килгән. Әмма әнисе дә бик иртә үлеп китә, ятим бала туганнарында тәрбияләнә.

Автор:
Әнвәр Шәрипов, филология фәннәре докторы, профессор

Укуга дәрт Габдерәхимдә бик иртә уяна. Башта авыл мәдрәсәсенә йөреп укый. Зирәклеге, үткен зиһене белән сабакташлары арасында «укымый белә торган шәкерт» буларак таныла, озакламый яшьтәшләренә хәлфәлек итә башлый. Мәдрәсәдә бирелә торган белемнәрне, гарәп, фарсы телләрен үзләштерә. «Белем алырга комсыз» булган бу яшь шәкертне туган авылындагы мәдрәсә, андагы гыйлем дөньясы, аралашу сферасы гына канәгатьләндерми, һәм ул күрше авыл мәдрәсәләренә китеп белем ала, яңа мөгаллимнәр белән аралаша.

Тиздән Габдерәхимне тирәяк авыл мәдрәсәләре дә канәгатьләндерми башлый. Ул, гаиләсен дә алып, эре гыйлем үзәге саналган данлыклы Оренбург Каргалысына килә. Монда Вәлид бине Мөхәммәд Әмин Каргалый мәдрәсәсенә укырга керә, әлеге дин белгече аның остазына әйләнә.



Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы 1839 елда беренче тапкыр Утыз Имәни редакцияләгән текст буенча басылып чыккан.

Әмма бераздан Габдерәхимне Оренбург Каргалысында алган белемнәренең генә җитмәвен аңлый. 1788 елда ул гаиләсе белән Урта Азия якларына чыгып китә. Башта Бохарада туктала, исеме еракларга таралган мәдрәсәләрдә белем ала, күренекле галимнәр, укымышлы кешеләр белән аралаша. Бераздан үзе дә мәдрәсәдә укыта башлый. Бохарадан соң Габдерәхим Сәмәркандта, Урта Азиянең башка шәһәрләрендә була. 1796 елда, 42 яшендә, Әфганстанга сәяхәт кыла: Бәлех, Һират, Кабул шәһәрләрендә яшәп ала, белемен арттыру белән шөгыльләнә.

1798 елда Габдерәхим туган ягына кайтырга чыга. Туган авылында төпләнеп калырга тели, әмма аңа: «Синең атаң Тимәш кешесе иде», – дип, йорт салырга җир бирмиләр. Шуннан соң ул үзенең ерак туганнары яшәгән күрше авылга – Кара Чишмәгә китә, анда бер ел яши. Ләкин Кара Чишмәдә дә озак торырга рөхсәт итмиләр. Шуннан соң хәзерге Чистай районының Исләй авылында бер ел чамасы мәдрәсәдә укыта. Аннан хәзерге Лениногорск районының Сарабиккол авылына күчә, анда өч ел мәдрәсәдә белем бирә. Куакбаш авылы тарихында беренче мәдрәсә салдыра, шунда ук шәкертләр укыта. Ниһаять, әтисенең туган авылы Тимәшкә килеп урнаша һәм үзенең соңгы көннәренә кадәр шунда яши.

Тимәштә аның кечкенә генә йорты, аз гына җире була. Ул маллар асрамый, байлык җыймый. Картлык көннәренә кадәр иҗат эшен дәвам итә. Габдерәхим Утыз Имәни 80 яшенә кадәр яшәп, 1834 елның 8 апрелендә вафат була. 1994 елда шагыйрь һәм галим Габдерәхим Утыз Имәни кабере өстенә Шәрык стилендә таштан эшләнгән, ак гөмбәзле зур гына төрбә-мавзолей төзеп куела. Мавзолейның эчке ягына, түр стенага шагыйрьнең «Мөһиммәт эз-заман» поэмасыннан түбәндәге шигырь юллары язып куелган:

Егет булсаң, егетлек күргәз илгә,
Мәхәббәтлек путасын багла билгә.
Гаделлек кыйл, ул имди әһле вафа,
Берәүгә бер тузан тик кыйлма
җәфа.

Бу – татар әдибенә куелган беренче мавзолей.

УТЫЗ ИМӘНИ – ШАГЫЙРЬ

Габдерәхим Утыз Имәни – әдәбиятыбыз тарихында иң беренче мәгърифәтче шагыйрьләрдән. Гомере буе гыйлемнең чиксез тирәнлегенә омтылган шәхес буларак, аның иҗатында да төп мотив булып замандашларын белем алырга чакыру тора. «Гыйлем» төшенчәсен шагыйрь бертөрле генә аңламый. Бер яктан, ул аны тормышның нигезе, кешеләргә тормыш авырлыкларын җиңәргә, аның серләрен ачарга ярдәм итә торган гаять куәтле чара дип саный. Шагыйрь фикеренчә, гыйлем тормыштагы бар нәрсәдән – байлыктан да, алтын-көмештән дә, кешеләрнең йөз матурлыгыннан да өстен. Алтын-көмеш, кешеләрнең матурлыклары – вакытлы нәрсәләр: вакыт үтү белән, аларны кулланган саен, алар кими, азая, шиңә, тоныклана, ә гыйлем исә вакыт үтү белән арта, күбәя генә бара. Шуңа күрә шагыйрь гыйлемне кешедән дошман да, угры да тартып ала алмаслык кыйммәтле хәзинә, кеше күңеленең нуры дип атый:

Гыйлем – нурдыр,
нурлыйдыр күңелләри,
Җәһел – нардыр,
йандырыр һәп дилләри.

«Гыйлем» төшенчәсен шагыйрь дини мәгънәдә дә куллана: «гыйлем белән дөнья да, ахирәт тә алыныр; икесендә дә хөрмәт һәм дәүләт булыр». Барлык кешеләр дә дини өйрәтмәләрне үзләштерсәләр, шул өйрәтмәләрне көндәлек тормышларында җитәкче итеп куллансалар, җәмгыять тормышы савыгыр, бар кешеләр гомуми бәхеткә ирешер иде, дип саный.

«Әл-карзы микъраз әл-мәхәббәт» («Бурыч – мәхәббәтне кисү кайчысы») поэмасын шагыйрь инде иҗатының соңгы чорында иҗат иткән…Бер остаз белән аның шәкерте кырык ел буе тугрылыклы дус булалар. Бәла чыгып, шәкерте төрмәгә эләккәч, остазы аны бик тырышып, аннан коткара. Икенче тапкыр, шәкерте бәлага таргач, остазы аңа акча биреп, ул казадан да коткара. Шактый гомер үтә, ә шәкерт остазына бурычын түләми. Остазы, аның күңелен бозмыйм дип, сорамый йөри. Берничә ел үтә. Бик мохтаҗлангач, остаз шәкертеннән әлеге акчаны сорарга мәҗбүр була. Ә шәкерте кинәт кабынып китә, халык алдына остазын сүгеп ташлый. Халык остазның хаклы икәнлеген белә, аны яклап чыгалар, шәкертнең үзен гаеплиләр. Автор әсәрне «Яхшылыкка көт яманлык» дигән сүзләр белән тәмамлый.

Балачактан ук ислам дине нигезендә тәрбияләнеп, әсәрләрендә дини карашларны үткәрсә дә, Габдерәхим реаль тормышка ачык күз белән караган. Мәсәлән, ул татар халкын русларга каршы куймаган, андый карашлардан югары торган, замандашларын русча өйрәнергә чакырган, еш кына «Русиядә тереклек кылучы мөселманнарга кырык бер фарыз, кырык беренчесе – урысча белмәк кирәк», – дип әйтә торган булган.



Утыз Имәни кульязмалары җыентыгында буләк язуының факсимилесы.

Утыз Иманинең ун поэмасы барлыгы мәгълүм. Шәкертлек чорында язылган беренче поэмалары – «Ахирәтнамә» һәм «Нәшер эт-тәкъриб» – дини эчтәлектә. «Ахирәтнамә»дә үлгән кешеләр тереләсе көн – ахирәт һәм шул чакта булачак хәл-вакыйгалар турында ислам дине өйрәтүенчә бәян ителә. Утыз Имәни аны күренекле ислам галиме Мөхәммәд әл-Газалиның «Дөррәт әл-фахирә фи кәшфе гомум әл-ахирә» («Ахирәт хәлләрен ачу юлында мактаулы энҗе») исемле әсәреннән файдаланып язган. Рифмалы проза белән язылган «Нәшер эт-тәкъриб» әсәрендә исә шул чордагы шәригать кануннарына туры килми торган күренешләр тәнкыйтьләнә.

Поэмаларының берничәсе шагыйрь тормышындагы вакыйгалар белән бәйле. Мәсәлән, «Горбәтнамә» («Читтә яшәүченең хаты») әсәрен ул үзенең төрмәгә утыртылуы уңае белән, 1785 еллар тирәсендә язган. Шагыйрьнең, «гавам халкы хәдисләрне дөрес укый белмәгәч, нәфел, сөннәт намазларын да уку дөрес түгел», дигән фикере татар дөньясын шаулаткан, руханилар арасында, «дингә ревизия ясаучы кеше чыккан», дип гауга таралган, ахыр чиктә Габдерәхимне төрмәгә яптырганнар. Шагыйрь монда үзенең төрмәдәге авыр хәлен сурәтли; төрмәдән котылуга булган бөтен өметен Аллаһның мәрхәмәте белән бәйли.

Урта Азиядә чакта шагыйрь өч поэма иҗат иткән. Аның берсе «Төхфәтел-гораба вә ләтаифелгазаэ» («Горбәтлектә йөрүчеләргә бүләк һәм аларның хурлыкка калу вакыйгалары») дип атала. Тормыштан алынган вакыйгаларга нигезләнгән бу әсәрдә автор Бохарага Идел буеннан килгән тәҗрибәсез шәкертләрнең, Бохара хәлфәләренең хәйләмәкерләренә алданып, ничек

итеп кешелектән чыгуларын, адәм хурына калуларын сурәтли. Реаль тормыш күренешләрен рәхимсез чыбыркылаган бу әсәрне татар әдәбиятында иң тәүге сатирик поэмаларның берсе итеп бәяләнә.

Икенче поэма – аллегорик әсәр, «Би-хаб эндәр мәкер муши шөтер шод» («Йокы эчендә тычкан хәйлә белән дөягә әверелде») дип атала. Автор кешеләрдәге фикер чикләнгәнлегенә каршы чыга. «Үзеңне «мин беләм» дип уйлама, башкалар белән чагыштырып кара», – дигән нәтиҗә ясый.

Өченче поэмасы фәлсәфи эчтәлектә – «Җенахел-фәлях фи зәмми мөбах» («Мөбахны шелтәләү –гөнаһлардан котылу юлы») дип атала. Шагыйрь кешедә тумыштан дүрт төрле сыйфат була, ди; алар – ерткычлык, шәйтанилык, хайванилык һәм илаһилык. Автор кешеләрне беренче өч сыйфатка бирелмәскә, ә дүртенче сыйфатка – илаһилыкка юнәлергә чакыра. Илаһилык сыйфаты кешедәге барлык яхшы сыйфатларның нигезе, ди. Өч начар сыйфатның чыганагы – мөбахка бирелү. Мөбах ул – шәригать тарафыннан кушылмаган да, тыелмаган да гамәлләр, аларны үтәү кешенең үз ихтыярында. Утыз Имәни кешеләрнең шул мөбах гамәлләр белән артык мавыгып китеп, үзләрендә хайвани сыйфатлар булдыруларын тәнкыйтьли.

«Гавариф эз-заман» («Замана бүләкләре») поэмасының беренче ике бүлеге автобиографик характерда: беренче бүлектә ул үзенең «егетлек дәверендә» күп илләрне гизүе, төрле авырлык-җәфалар кичерүе, «олы затлардан» белем алуы, хөрмәткә ирешүе хакында сөйли. Икенче бүлектә күпъеллык сәяхәттән кайткач, үзләрен дин әһеле дип, чалма чалып йөрүчеләрнең шактый надан булуларын күреп, шәригать кануннарын белмәүләрен, максатлары байлык туплау, кунак булып, тәмле ашап йөрү икәнлеген тәнкыйтьли. Шуннан соңгы бүлекләрдә автор ислам изгеләренә хас сыйфатларны тасвирлый, алардан үрнәк алырга чакыра, дин гыйлемендә югары дәрәҗәгә ирешкән галимнәрнең китапларыннан гына белем алырга өнди.



Утыз Имәни мавзолее.

«Тәнзиһ әл-әфкяр фи нәсаих әл-әхъяр» («Фикерләрне пакьләндерүче игелекле үгетләр») поэмасында шагыйрь эчкерсез дуслык мәсьәләсен күтәрә. Үз дусларының икейөзле булуларыннан, бер төрле сөйләп, икенче төрле гамәл кылуларыннан зарлана.

Поэмаларның иң зурысы һәм иң популяр булганы – энциклопедик характердагы «Мөһиммәт эз-заман» әсәре – 1820 елда язылган. Үгет-нәсихәт алымы кулланылган, барлыгы 27 бүлектән торган бу әсәрдә автор шул чордагы татар тормышының күп якларын чагылдыра, әхлак һәм мәгърифәт темаларын күтәрә. Һәр бүлектә бер әхлак сыйфаты яки мактала, яки тәнкыйтьләнә. Шагыйрь биредә замандашларын илгә-халыкка хезмәт итәргә, тугрылыклы, гадел, тату, түбәнчелекле, сабыр, инсафлы, сак булырга, гамьсез яки явыз холыклы, хәйләкәр, икейөзле булмаска, заманага ияреп яшәргә, балаларны укытырга, инсафлы итеп тәрбияләргә, гаиләне сакларга, галимнәрне, кабер әһелләрен хөрмәтләргә, Аллаһка гыйбадәт кылырга чакыра.

УТЫЗ ИМӘНИ – ТЕКСТОЛОГ

Утыз Имәни татар текстологиясе фәненә нигез салучы булып та санала. 1824 елда ул Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасының унга якын кульязмасын үзара чагыштырып чыккан, әсәрнең фәнни чагыштырма текстын барлыкка китергән һәм ахырга «Һәркем бу рисаләне язарга теләсә, шушы нөсхәдән канәгать итсен: күп нөсхәләрдән чагыштырылды... Әмма, зинһар, моннан башкадан язмагыз, зур хатага очрарсыз... Габдерәхим Болгари. 1824» дип язып та куйган. «Кыйссаи Йосыф» поэмасы 1839 елда беренче тапкыр нәкъ менә Утыз Имәни редакциялəгән текст буенча басылып чыккан һәм дөньяга таралган.

ГАБДЕРӘХИМ УТЫЗ ИМӘНИ – ДИН ГАЛИМЕ

Яшьтән үк гарәп һәм фарсы телләрен, Коръәнне, тәфсирләрне, шәригать хөкемнәрен тирәнтен өйрәнү Габдерәхимне әкренләп фән дөньясына алып килгән. Башта ул үзе өйрәнә торган гарәпчә китаплардагы авыр аңлаешлы сүзләргә, дини терминнарга аңлатмалар язу, аларны татарчага тәрҗемә итү, гарәпчә-фарсыча сүзлекләр төзү белән шөгыльләнгән. Ә соңга таба ислам диненең гамәли һәм теоретик мәсьәләләре хакында гыйльми трактатлар да яза башлаган.

Гарәп теле белгече, галим Рамил Әдһәмов 2005 елда Утыз Имәнинең әлеге трактатларын анализлап, рус телендә «Габдрахим Утыз-Имяни» дигән монография бастырып чыгарды. Ә инде 2007 елда Утыз Имәнинең 9 дини трактатын русчага тәрҗемә итеп, аларга 78 битле фәнни аңлатмалар язып, бастырып чыгарды. Бу китапта Утыз Имәнинең шәригать хөкемнәре һәм суфичылык турында язылган фәлсәфи трактатлары, алардагы фикерләр җентекләп анализлана. Шулай итеп, күренекле мәгърифәтче шагыйрь һәм ислам галиме Утыз Имәнинең күпкырлы иҗат мирасы бүгенге укучыга шактый тулы булып килеп җитте. ■

МАХСУС ПРОЕКТ

— 45нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

«Татнефтехиминвест-холдинг» ААҖ
быел 25 еллык юбилеен билгеләп үтә

ТАТНЕФТЕХИМИНВЕСТ ХОЛДИНГ

Республика үсеше хакына фидакарь хезмәт

Павел Кочнев,
«КМТТУ» ЮББ ФДББУнең «Союзхимпромпроект» ПИ директоры

– Рафинат Саматович, «Союзхимпромпроект» проект институтының бөтен коллективы исеменнән һәм шәхсән үз исемемнән Сезне һәм Сез җитәкләгән коллективны 25 еллык юбилеегыз белән котлыйм!

Сез үзегезгә республиканың глобаль үсешенә турыдан-туры бәйле гаять мөһим миссияне алдыгыз. «Татнефтехиминвест-холдинг» эшли башлаган вакытыннан ук Татарстанның нефть-газ химиясе комплексын яңарту, оптимальләштерү һәм эшенең нәтиҗәлелеген күтәрү буенча гаять көчле инновацион стратегияләр тәкъдим итте һәм башкарып чыкты.

Компания тарафыннан көн саен башкарыла торган фидакарь хезмәт нәтиҗәсендә республиканың нефть-газ химиясе предприятиеләренә заманча фәнни-техник эшләнмәләрне гамәлгә кертергә мөмкин булды. «Татнефтехиминвест-холдинг» ярдәмендә Татарстанда нефть-газ химиясе комплексы предприятиеләрен үзара бәйләүче бердәм система барлыкка килде. Экологик һәм социаль сәясәтне формалаштыру өлкәсендә башкарылган югары квалификацияле эш Сез контрольлек иткән тармаклардагы хезмәтнең абруен һәм нәтиҗәлелеген күтәрә.

Бүген Татарстанның химия заводлары һәм нефть-газ табу компанияләре дөнья күләмендә лаеклы урын тота, һәм бу юнәлештә «Татнефтехиминвест-холдинг»ның актив һәм эзлекле эшчәнлеге мөһим рольне уйный.

Республика иминлеге хакына көн саен башкарылган гаять зур хезмәтегез өчен тирән ихтирамымны һәм рәхмәтемне белдерергә рөхсәт итегез. Яңа, инновацияле идеяләр, бөек казанышлар һәм туктаусыз үсеш юлдаш булсын. «Татнефтехиминвест-холдинг» коллективының һәр хезмәткәренә сәламәтлек һәм иминлек насыйп булсын!

Фото «Союзхимпромпроект» ПИ алынды

Реклама

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

Реклама бүлеге:
тел: (843) 222-09-76,
8-9272-483-384
e-mail: 89272483384_pr@mail.ru

Реклама 16+

ТАРИХ ТАКТАСЫНА – ШАКМАК, ЯКИ КУРЧАКЛАР КЕМ КУЛЫНДА?

Яз–җәй сезонындагы кызыклы китаплар арасында жанр ягыннан да, тематик колачы буенча да гаять төрле булган, әмма бер-берсен логик яктан шулкадәр камил тулыландырган ике китапка юлыктым. Шулар белән бүлешергә дә булдым.

Автор:
Луиза Янсуар

ДӨНЬЯНЫ АКЛАРГА КИРӘКМЕ?
РОЗЕЛЛА ПАСТОРИНО. ДЕГУСТАТОРШИ.

Бу авторны Россия укучысы үзе өчен әле яңарак ачты. «Дегустаторши» – Розелла Пасторинонын рус телендә дөнья күргән беренче әсәре. Аны язарга язучыны чын тормышта булган тарих этәрә. Аннан да бигрәк, реаль шәхес. Ул да булса – Марго Вёльк.

Кем соң ул Марго Вёльк? Моннан берничә ел элек кенә әлеге ханымның барлыгы хакында берәү дә белми иде. Әмма 2012 елда, 95 яшендә, ул кинәт, көтмәгәндә-уйламаганда, яшьлегендә булган вакыйгалар турында интервью бирергә карар кыла. Интервью дөньяны шаулата.

Тарихи җирлеккә килсәк, Икенче бөтендөнья сугышы барган елларда Марго Вёльк фюрерның «Волчье логово» дип аталган Вольфшанцтагы яшерен лагерендә (штаб-квартирасында) эшли. Ул үзе кебек үк тагын 14 хатын-кызны туплаган «Агулы бригада» әгъзасы була.

«Агулы бригада»ның (сүз уңаеннан, аны шулай дип СС офицерлары атый, туташ вә ханымнарны фюрер тирәлегендә «дегустаторша» дип зәвыкле исем белән олылыйлар), аңлашыла инде, бик мөһим вазыйфасы була. Ул вазыйфа – фюрер өстәленә әзерләнгән тиешле ризыкны, эчемлекләрне, Гитлерга кергәнче, авыз итү. Ашаганнан соң дегустаторшаларны гадәттә тынычлыкта калдыра торган булалар. 1–2 сәгать эчендә берәү дә агуланмаса, ризыкны фюрерга ашарга кертәләр.

Марго Вёльк болай искә ала: «Гитлер вегетарианлы иде. Кан күренешен күтәрми. Мин аңарда эшләгән вакыт арасында беркайчан да ит ашамады. Димәк –

Фотолар: www.livelib.ru сайтыннан алынды.

без дә. Чын параноик иде: үзен инглизләр агулап үтерергә җыенуында шиге юк иде аның. Без зур банкет залында эшләдек. Агач өстәлләр экзотик җиләк-җимештән, макарон, соуслардан сыгылып тора. Бигрәк тә – баллы тәм-томнан. Ул чын баллы яратучы, дисәм, һич тә ялгыш булмастыр. Пироженоелар, чикләвек, сгущенка өчен үлеп китә иде фюрер. Без, әлбәттә, авызга алганда, аларның тәмен тойсак та, куркудан шунда ук оныта идек: һәр капкан ризыгың соңгысы булырга мөмкин бит...»

Кайнатам белән кайнанам икесе дә, артымнан ишекне ябар өчен, сабыр гына чыгып киткәнемне көтте. Күрәсең, мин чыннан да бу дөньяга Гитлер өчен ашарга гына яратылган, башка берни өчен дә түгел. Германия өчен ашарга. Башкалар ачтан тораташ катып үлгәндә мин аның сыгылып торган өстәлендәге тәм-томнарын шыплап корсагыма тутырам. Мин Гитлер ризыгын тыгынам, мин башка нәрсә өчен ярамыйм да, башкага лаек та түгел, димәк...

Марго Вёльк Икенче бөтендөнья сугышының ике ел ярымын кухняда уздыра. Иң деликатес ризыклардан гына авыз итеп. Һәм – һәр капкан ризыгыннан соң нәрсә булачагын күз алдына да китерә алмыйча.

Шунысын да әйтергә кирәк: Вёльк раславынча, Гитлерның дегустаторшалары арасында барысы да арийкалар була. Түбән раса вәкилләренә үз исәнлеген кайгыртуны ышанып тапшыра алмый фюрер.

«Нигә моңарчы бу серне ачмадыгыз?» – дигән сорауга 95 яшьлек Вёльк: «Нацистларга хезмәт итүемне әйтергә хурландым, әмма вакыт үзенекен итә, яшь бара, хәзер инде моны яшереп калырга, хакыйкатьне үзем белән алып китәргә теләмим», – ди.

Кешене камераларга ябып юк итүнең, атып, шартлатып үтерүнең коточкыч булуы аңлашыла, ә менә ашатып үтерүнең? Вёльк сугыштан соң озак еллар ашаган ризыгын ашказанында тота алмый җәфалана. «Ашарга яңадан өйрәнергә туры килде», – ди.

«Волчье логово»дан 1944 елда качып китә ул. Яшь ханымга гашыйк булган бер офицер ярдәм итә. Вёльк качканда, фюрер һәм ул төзегән империянең соңгы мизгелләре генә калган икәнлеген офицерлар үзара инде ачыктан-ачык диярлек сөйләшә торган була. Шуларның берсе сөйгәнен яшерен юл белән качырырга һәм Берлинга озатырга да кирәк дип таба. Соңга калганчы...

Совет гаскәрләре, Гитлерның әлеге ставкасын алганда, бөтен офицерларны кырып сала, шул исәптән – персоналны да. Марго Вёльктан тыш, «Логово»да тагын 14 кыз була. Аларның берсе дә исән калмый. Качып чыккан Марго исә берара ташландык мәктәп бинасында, баш чыгарырга да куркып, яшеренеп яши. Аннан Берлинга качып китә.

«Дегустаторши» әсәрен, китап киштәләрендә пәйда булуга, Бернхард Шлинкның «Чтец»ы белән янәшә куйдылар. «Мине Шлинк белән чагыштыру гаҗәпләндерми дә, борчымый да, киресенчә, сөендерә, бу – зур горурлык...» – ди Пасторино үзе.

«Азбука-Аттикус» китапны минималистик рухта зәвыкле һәм күркәм итеп бизәп чыгарган – укырга рәхәт. Тар форматтагы бу сериясе, гомумән, эстетик ләззәт бирә аның.

Китапны рус телле укучылары форумнарда «а жор здесь тихий» дип тамгаларга өлгерде инде. Аның слоганы да шактый ирониялe, хәтта сарказмлы, диярга дә буладыр: «Они ели за Гитлера».

Инде китап сюжетына килик. Ире сугышта чакта аның әти-әнисе янына кайтып яшәргә мәҗбүр булган яшь ханым – әсәрдә ул Роза Зауэр исеме белән бирелгән – авыл тормышында яшәр өчен яратылмаган була, әлбәттә. Кара эш белән аскеза, ялгызлык өчен дә. Бу җәһәттән көннәрдән бер көнне аны: «Син Гитлерга хезмәт итәчәксең», – диеп алып китүләре, бер яктан, шактый уңайлы очрак була. Җитмәсә, кайнанасы белән кайнатасы йортына, аз булса да, акча керәчәк. Файдасы тиячәк. Әмма «Волчье Логово»ның бусагасын атлап керүгә, Роза аңлап ала: мондагыны ул беркайчан да, хәтта иң якын кешеләренә дә сөйли алмаячак. (Асылда Марго Вёльк сөйләме дә, аның сугыш вакытында ни белән шөгыльләнүен ире белмичә дә дөнья куя).

Язучы асылда куркыныч булган хәлләрне көндәлек, гадәти тон белән сурәтли. Ханымнарның берсе агулангач, аларны бер бүлмәдә өерләре белән бикләп калдыруларын да, кыйнауларын да. Розаның, СС офицеры белән араларында мөнәсәбәтләр барлыкка килгәч, дәрт белән укшу арасында бәргәләнүен дә. Әйе, ул мәхәббәтнең мондый шартларда натуралистик детальләрдән ерак йөри алмавын мәрхәмәтсез рәвештә ассызыклый.

Дөнья афәт кичергәндә, тыштан караганда, чагыштырмача тыныч шартларга куелып та, һәр мизгелен «кайчан?!» дип уздырган кешенең ни дәрәҗәдә зур хәсрәт кичерүен нечкә һәм бер үк вакытта тупас итеп күрсәтүгә ирешә алган Розелла Пасторино. Үзен аклый алырмы бу героиня? Ә аклый алмаса, нишләр, дигән уй тынгы бирми китапның ахырынача. Әйе, бу режимны ул төземәгән. Әйе, ул нибары көчсез бер хатын-кыз гына. Әйе, аның барысы шикелле үк исән каласы килә.

Әйе, ул барысы өчен дә түләргә кирәк икәнен яхшы белә...

Дөнья буйлап бомбалар коела, кешеләр үлә. Гитлер кешелекне юк итү машинасын камилләштерүен дәвам итә. Ә без ул арада сарайда Альберт белән бер-беребезгә шулкадәр нык сыеныпбыз ки, әйтерсең, яшәр, сулар, чистартыныр өчен, параллель дөньяга күчәбез. Без бер-беребезне шулкадәр ваемсыз ярата идек. Югыйсә, җир йөзендә мине нацистны кочакларга, назларга мәҗбүр итәрдәй бер генә сәбәп тә юк лабаса, аңардан балага узарга да... Бу дөньяда күптәннән бернәрсәне хуплар өчен дә, хурлар өчен дә, аклар өчен дә сәбәпләр юк инде...



НӘРСӘ КУРКЫНЫЧРАК?! ВАДИМ КАРТУШОВ. СТАЗИС.

«Эксмо» укучыларын яңа серия белән куандыра башлады: «Сломанный миф. Современная российская фантастика». Стругацкийлар белән Лукьяненкодан соң, үзебезнең Россия фантастикасы дөньясында, жанрында әллә ни тетрәнгеч ачышлар ясамасам да, бу әсәр беренче битләреннән үк җәлеп итте. Бәлки, фәлсәфи катламнарының, нәкъ менә совет һәм постсовет фантастикасының иң яхшы үрнәкләренә хас булганча, лирик-романтик башлангычка алып чыгуына бәйле рәвештә, ә бәлки кинәт кенә бездә бик үк җиренә җиткереп эшләнмәгән постапокалипсис юнәлешен ярыйсы гына тулыландыра алуы беләндер.

Вадим Картушов бастырган китап рус теленә бик үк хас булмаган «Стазис» дигән исемгә ия. Аннотациясенә үк уен-ребус, квест элементлары салынган:

Стазис безнең дөньяга каян килгән? Моны берәү дә белми. Теге якта ни барын шулай ук берәү дә белми диярлек. Әмма һәркем өч канунны яхшы белә.

Беренчесе – тере кешеләрдән беркем дә Стазис территориясендә, аның бер өлешенә әверелмичә, озак тора алмый.

Икенчесе – әгәр сине Стазис эмиссары утка тота икән, беркайчан да аның күзләренә карама. Син аларда күргән нәрсәдән баш тарта алмаячаксың.

Өченчесе – Стазис һәрчак янәшәдә генә.

Дүртенче канун да бар, ди кайберәүләр. Имеш, ул исән калырга ярдәм итә ала. Әмма дүртенче канунны белгән кеше аның хакында беркайчан да һәм берәүгә дә әйтмәячәк.

Бу китап әле нәширләр кулына килеп кергәнче үк, Фантлаб («Лаборатория фантастики» сайты турында сүз бара. – Л.Ш.) челтәр ресурсының укучылары симпатиясе призына лаек булган иде. Фантлаб версиясе буенча «Ел китабы» дип тә игълан ителде ул.

Кәгазь версиядә Картушовның дебюты – бу китап.

Танылган блогер һәм язучы Вадим Картушов Мәскәүдә яши һәм публиканы искиткеч популяр, кызыклы блогы, блогыннан һич кенә дә калышмый торган әсәрләре белән куандырып килә.

Әдәби тәнкыйть аны, шушы соңгы романыннан соң, Гейман, Лазарчук белән янәшә куеп бәяләде. Нәрсәсе беләндер әсәр «Сталкер»га якын, «Гадкие лебеди»гә. Кормак Маккартиның атаклы «Дорога»сын да хәтерләтеп куя.

Сюжетка килик. Нindидер глобаль афәттән соңгы Мәскәү һәм Россия. Мәскәүне тулаем Стазис йотып алган. Бу зонада адәм балаларын яшәтә алырдай физик һәм кешелек кануннары инде юк. Алай гына да түгел, Стазиста вакыт һәм пространство төшенчәсе үзе үк бөтенләй юк: аңарга эләгүгә, алар икесе дә тораташка әверелә. Стазис җәелгәннән-җәелә бара, яңа территорияләрне яулый. «Мәскәүдә инде кешеләр яшәмиләр, – ди исән калган кабиләләрдән берәү, – Мәскәү күптәннән – эмиссарлар белән курчаклар кулында».

Картушов кайчакта шундый гади генә, асылда үтә сискәндергеч символик штрихлар, детальләр сирпеп куя: ирексездән, тел шартлатасың. Шулай итеп, Мәскәү Стазис хөкемендә булса, калган кешелек кабат кабиләләргә бүленеп беткән.



Кабиләләр бер-берләре белән туктаусыз бәрелештә, кан коюда. Автор бик кызыклы һәм колоритлы итеп, әмма маңгайга артык бәрмичә генә, кенәзлекләр чорындагы таркаулыкны калкытып күрсәтә. Ул тарихи элементларны постпанк чалымнары белән аралаштырып, бик тә үзенчәлекле коктейль ясауга ирешә.

– Йә, нәрсә үзгәрде инде? – дип сорады кенәз һәм иснәнеп куйды.

– Күп нәрсә, – дип кырт кисте Синклер. – Мин үз күзләрем белән күрдем. Мәскәү урамнарын. Курчаклар урам саен, чат саен тора. Балалар кибете, диярсең. Меңләгән курчак, аңлыйсыңмы?! Тулы бер армия...

– Мәскәүдә, әйтерсең, эмиссарлар электән дә булмаган, – дип, аптырамады кенәз, – әйтерсең, алар кинәт кенә пәйда булган...

– Һәрчак бар иде, – дип килеште Синклер. – Әмма колонналап түгел ләбаса! Һәм алар барысы да тораташ булып басып тора. Көн чыгышка карап. Һәм җырлый. Сиңа соң җиткермәделәрмени бу хәбәрне? Мин шаккатам. Коршун үз ипиен юкка ашый...

– Син соң миңа нәрсәгә килдең?

– Чөнки синең кабиләң – иң эреләрдән...

Синклер һәм аның юлдашлары, әйтерсең, Тарих тактасына шакмак чөеп уйный, курчаклар белән кем идарә иткәнен ахыргача ачыкларга тели. Асылда, әйе, тели дә. Синклер инде Стазисның бер мәртәбә ни икәнен белеп, анда булып кайткан зат, аның югалтыр нәрсәсе юк... Киресенчә, ул үзен кайтарып алырга, яңадан табарга өметләнеп, кабат афәтнең эченә үк бара. Бу юлы үзе белән юлдашлар да ала.

Кабиләләрнең берсендә риваять йөри: имештер, Стазис ул – кемнеңдер озын-озакка сузылган куркыныч, яман төше генә. Ул Затны табып уятсаң, төштән котылырга мөмкин. Кайберәүләр бу әкияткә чын-чынлап ышана башлый. «Әгәр эмиссарлар, курчаклар төш икән, димәк, без дә – төш кенә...» – кинәт әнә шундый логика өтеп ала бер каһарманны.

Әсәрне совет фантастикасы элементлары белән турыдан-туры бәйли торган тагын бер нәрсә – ул төп геройның бирелеше. Ярымэмиссар, ярымкеше чигендә калган Синклерны автор яратып, психологик яктан тирән итеп сурәтли, аңарга интеллигентлык чалымнарын өсти.

Яңа шәһәргә барып эләккәч тә, Синклер, беренче эш итеп, китапханә эзләп таба торган иде. Нигездә, бу ташландык хәлгә килгән шәһәр китапханәләре була. Кайчакта эзләгәнен ул Күчмәннәрдә дә таба. Кайбер күчмә кешеләр китапханәне үзләре белән йөртергә ярата. Әмма Күчмәннәрнең китапханәсенең рәте-башы юк, аларда нигездә беллетристика һәм түбән сыйфатлы китаплар гына очрый. Ә менә ташландык зур шәһәр китапханәләрендә ул сәгатьләр буена утыра ала: ни генә юк аларда...

Постапокалиптик дөньяда да кеше булып калу турында сүз бара Картушов әсәрендә. Аның Стазисы да өшеткеч, чиркандыргыч түгел, ә гламурга тартым оеткыч томаны белән йола һәм буйсындыра торган алдавыч көч. Ул һөҗүм иткәндә корал да кулланмый хәтта – дулкыннар белән генә акылдан шаштыра. Роман дөньясы Fallout, Rage уеннары галәменә тартым, ди кайбер геймерлар.

Әсәрнең архитектоникасы, структурасы да уен элементларын хәтерләтә. Шулай ук – борынгы китапларны, лабиринтларны. Ахыр чиктә, Стазисны юкка чыгара алырдай көчне эзләп, Мәскәүгә барып чыккан каһарманнар нәкъ менә шул лабиринтка эләгәләр дә. Һәм Стазис лабиринтына эләккәч кенә, үз аңнарының лабиринтында инде бик күптәннән йөргәннәрен абайлап алалар...

Асылда, икенчесе – күпкә куркынычрак. **Т**

ТАРИХЛЫ, СЕРЛЕ ОЛЫ КАРИЛЕ

Татарстанда искитмәле гүзәл урыннар бар, матурлык эзләп диңгезгә барасы да түгел. Кама Тамагы районына сәфәргә чыккач, шулай дип сөйләшеп бардык. Андагы матурлык! Тау астында Идел елгасы җәйрәп ята. Ул урман, таулар, дисеңме... Иксез-чиксез булып күренгән офык... Шушы сихри матурлыкка таң калып, Олы Кариле авылына килеп җиткәнебезне сизмәгәнбез дә.

«ӘЙДӘ, КАРАЛЕ БАБАЙ ЯНЫНА!»

Олы Кариле заманында районның иң зур авылы саналган. Мондагы эш урыннарын санап китсәң... Урманчылык идарәсе, участок хастаханәсе, сөт-май комбинаты, йон тетү цехы, пекарня, тегермән. Моңа өстәп, райпо кибетләр челтәренең үзеге дә Олы Кариледә булган, миллионер саналган колхоз, почта бүлекчәләренең үзеге һ.б. уңайлыклар. Бүген, кызганычка, болар инде юк – хастаханә урынына ФАП эшли, колхозны агрофирма алыштырган. Калганнары заман шаукымына каршы тора алмаган, дистә еллар элек үк ябылган. Халык бигрәк тә хастаханәне сагына.

– Хәтта хатын-кызлар бәбине дә үзебездә таба иде. Өлкәннәр өчен дә ул – бер дигән урын, барып системалар куйдырып, рәхәтләнеп дәваланып кайта идек. Бөтен күрше-тирә авыллар да безгә йөрде, – дип сөйләделәр авылда.

Әйе, Олы Кариледәге кебек комплекслы хастаханәләр совет заманында һәр районның зур авылларында бар иде. Шунда теш тә дәвалыйлар, башка медицина ярдәме дә күрсәтәләр. Тик бүген андый үзәкләрнең күбесе ябылып бетте. Кама Тамагы районы да искәрмә түгел. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында моны: «Район үзәгендәге хастаханәләр заманча дәвалау аппаратлары белән җиһазландырылган, халык югары дәрәҗәдәге медицина ярдәме алырга тиеш», – дип аңлаталар.

Бүген Олы Кариледә 376 кеше яши, 127 хуҗалык бар. Мәктәп яшендәге балаларның саны – 40, ә балалар бакчасында 9 бала икән. Бүгенге вазгыять белән чагыштырганда, авыл өчен бу бик начар сан түгел үзе. Шулай да заманында Олы Кариле мәктәбендә 500 бала укыганын исәпкә алсак, уйланырга була. Бүген мәктәптә 70 укучы белем ала. (Тагын өч авылдан йөреп укыйлар.) Җирлеккә, Олы Кариләне санамаганда, өч авыл – Чаллы, Кече Кариле, Бәби керә.

Олы Карилегә баргач, берничә җигүле атны очраттык. Бирелә атлар күп икән, утыз баштан артык исәпләнә. Халык алар белән басудан печәнен, саламын ташый, җирен эшкәртә. Ир-атлар үз атлары белән фермада эшли. Сыерлар саны да шактый – 115 баш.

– Авылда барлыгы 376 баш мөгезле эре терлек исәпләнә, – диде Олы Кариле авыл җирлеге башлыгы Фарук Гарифуллин. – Халык нигездә шул терлекне асрап көн күрә.

– Фермер булып теркәлеп эшләүче гаиләләр юкмы? – дим.

– Бар, бер гаилә. Барып килербез. Әйдә әле, башта Карале бабай янына барып килик.

Кызык, авыл исеменә бәйләп кушканнар икән. Кем икән ул Карале бабай, дип уйлап куйдым.

Җиде-сигез йортлы урамга кердек, шуның икесендә генә кеше яши икән.

– Йортлар кими шул, – диде Фарук абый.

– Күп авылларга хәзер шәһәрләрдән күченеп кайталар. Сезгә дә кайтучылар юкмы? – дим.

– Бар. Кайткалыйлар. Әле менә Үзбәкстаннан балалары белән өч гаилә кайтты. Тәртипле кешеләр. Мәчеткә дә йөриләр.

– Килеп җиттек, – диде авыл җирлеге башлыгы. – Кунакларны еш кына монда алып киләбез.

Бер каберлек янына тукталдык. Бактың исә, бу Карале бабай каберлеге дип атала икән. Ташны тимер рәшәткә белән әйләндереп алганнар. Ташка уелган язулар да бар, тик аларны укып кына булмый.

Кабер ташы янында Карале бабай истәлегенә зур гына тагын бер истәлек ташы тора.

Фото: Александр Ефремов

Автор:
Руфия Фазылова

Ачык һавада музей эшләү – авыл мәдәнияте йорты директоры Илсур Кәримуллин инициативасы булган.

– Күрше авыл егете, тарихчы Җәүдәт Миңнуллин да укып карады, – диде Фарук абый. – Таш бик борынгы булу сәбәпле, аерым хәрефләрен генә таный алды.

– Ә алайса ташның Карале бабайныкы икәнен каян беләсез? – дим.

– Бабайлар шулай сөйли иде. Аларга бабалары күрсәтеп калдырган. Авылга нигез салучы кеше менә шушында күмелгән, диеп. Һәрхәлдә, без моңа ышанабыз.

– Ташка ничә гасыр дип уйлыйсыз?

– XVI гасырда куелган – шулай исәпләргә кирәк, диделәр. Кариле авылы Казан ханлыгы җимерелгәннән соң барлыкка килгән булырга тиеш.

Кабер ташы янында Карале бабай истәлегенә зур гына тагын бер истәлек ташы тора. Анысын 1992 елда Казаннан авылга кайтып йөрүче Әһлиулла бабай эшләткән. Хәзер инде мәрхүм икән. Ә исән чагында ул Карале бабай каберлегендә еш булган.

АЧЫК ҺАВАДАГЫ МУЗЕЙ

Олы Кариледә тагын бер кызыклы урынны күрсәттеләр. Быел авыл мәдәният йорты каршысына ачык һавадагы музей эшләп куйганнар. Хәер, аның исеме бар: «Крестьян» музее. Авыл тормышын белмәгән кеше мондагы экспонатларны күргәч, аптырап та калырга мөмкин. Ни өчен дигәндә, биредә булган эш кораллары, өй кирәк-яракларының күбесе инде кулланылышта юк: уфалла арбасы, мичтән таба ала торган табагач, күмер ала торган кыскычлар, шикәр ваткыч, май атлый торган кисмәк белән тубыл, кер юа торган тукмак, йон эрли торган җайланмалар, тагын әллә ниләр...

Ачык һавада музей эшләү – авыл мәдәният йорты директоры Илсур Кәримуллин инициативасы булган. Тынгысыз җанлы бу кеше гомере буе балаларга белем биргән, мәктәп директоры булып та эшләгән. Лаеклы ялга чыккач, мәдәният йортын җитәкли башлаган.

– Нигездә, безнең якларда халык игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнгән бит, – диде Илсур абый. – Заман алга киткән саен кул хезмәте акрынлап кими барган. Шуның өчен бүгенге яшь буын аларны белми дә. Мәктәп директоры булганда, «Туган якны өйрәнү» музее эшләгән идем. Мондый эшләрне яратам. Менә мәдәният йортында да шундый урын булдырасы килде. Санаулы көннәр эчендә экспонатларны тупладым. Монда күбесе үзебезнең авылда кулланылган эш кораллары. Берберсеннән күреп, авыл кешеләре аларны үзләре үк китереп бирде.

– Кышка нишләтәсез музейны? Экспонатларыгыз кар астында калып әрәм булмасмы? – дим.

– Урын табылыр, дип уйлыйм. Район администрациясе вәкилләре дә музейны күреп китте. Хәл итеп бетерербез, диделәр.

Олы Кариле мәдәният йорты Сабир Өметбаев исемен йөртә. Бу да Илсур абыйның тырышлыгы нәтиҗәсендә булган.

– Ни өчендер Кама Тамагы дигәч, Туфан ага Миңнуллинны гына телгә алалар, – диде әңгәмәдәшем. – Ә бит безнең авылдашыбыз, атаклы режиссер, Минзәлә дәүләт театрына нигез салган күренекле шәхесебез – Сабир Өметбаев та бар. Туфан абый истәлекләрендә язып калдыра: «Мине театр дөньясына Сабир абый алып керде», – дип. Үзем эшләгән вакытта Олы Кариле урта мәктәбенә Сабир Өметбаев исемен бирдертәсем килде, тик барып чыкмады. «Ул режиссер, эшчәнлеге мәктәп белән бәйле түгел», – диделәр. Инде менә мәдәният йортында эшли башлагач, телләгемә ирештем. Без бүген рәсми рәвештә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Сабир Өметбаев исемен йөртәбез.

Мондый мәртәбәле исемне йөрткән мәдәният учагында театр да эшли икән. (Башкача була да алмыйдыр!) Авыл халкы, араларында яшьләр күбрәк, кичләрен репетицияләргә җыела. Спектакль белән авылларга да чыгалар. Республика күләмендә узган конкурсларда катнашалар, урыннар яулыйлар.

– Халык театры исеме бирелергә тиеш безгә, менә рәсми җавап көтәбез, – диде Илсур абый.

Галимҗановлар авылның бердәнбер тәҗрибәле фермерлары.

– Һәр бала үз ризыгы белән туа, – ди Зыятдиновлар.

ТӘҖРИБӘЛЕ ФЕРМЕР

Олы Кариле авыл җирлеге башлыгы белән Галимҗановлар гаиләсенә юл алдык. Алар авылның бердәнбер тәҗрибәле фермерлары. Эшләрен сигез ел элек башлаганнар. Бүген инде барысы да җайланган, һәркем үз урынын белә.

– Ничек итеп фермер булырга уйладыгыз? – дигән соравыма гаилә башлыгы Мансур Галимҗанов болай дип җавап бирде:

– Агрофирмада ферма мөдире булып эшли идем. Барам, малларны ашатырга азык юк, ат җигүчеләр исерек. Аптырагач, үз балаларымны чакырып китерәм, бергә эшлибез. Эшләгәч акчасын да аларга язгаладым. Соң, бушка йөрмәсләр бит инде. Мансур малайларына да акча эшләп бирә, дип ишеткәч, кул селтәдем. Мин әйтәм, ник болай азапланып йөрим соң? Буй җиткән ир балаларым бар, хатынның энесе дә янәшә яши. Бергә-бергә тотынсак, дидем. Менә шулай үзебезнең пай җирләрен алдык та печән чәчтек. Мал-туар санын арттырдык. Шулай акрынлап җайга салынып китте инде…

– Беренче елны нәрсә булганын сөйлә, – дип сүзгә кушылды янәшәдә торган тормыш иптәше Сания апа.

– Нәрсә булды? – дим.

– Басуы белән печәнебез калды. Техникабыз юк, агрофирманың үз басуы, ярдәм сорап бара торган түгел. Фәлән гектар җирне кул көче белән генә чабып бетереп булмый. Менә шулай җәфаландык инде.

Бүген Галимҗановларның карамагында 200 гектардан артык җир бар. Җир эшкәртү өчен бөтен төр техниканы да сатып алганнар. Сезон вакытында үз көчләре белән чәчәләр дә, урып-җыялар да. Унлап сыерлары, шуның кадәр үк үгезләре бар.

– Сыерлар егерме баш иде, – диде Сания апа. – Узган ел сөтлебикәләрдә лейкоз авыруы чыкты, бөтен сыерларны иткә тапшырырга туры килде. Өйдә таналар бар иде, шуларны үстердек.

– Сыерларны кем сава? – дигәч:

– Үзем, – диде Сания апа. – Әле бит баш саны күп түгел, егерме сыерны да үзем саудым. Аның бер авырлыгы да юк, фермада да сыер савучы булып эшләдем мин. Өч саву аппаратыбыз бар.

Сания апа «Ана даны» медаленә лаек булган ана, биш бала табып үстергән. Аның кебекләр турында: «Баскан җирдән ут чыгара», – диләр. Фермерлык эшенең документларын да алып бара, малларны да карый, өйдә, бакчада да өлгерә…

Без барганда Галимҗановлар хуҗалыгында урак өсте иде. Һава торышы әйбәт торса, сентябрь башына урып-җыю эшләрен тәгәлләргә уйлыйлар. Быел уңыш әйбәт икән.

– Олы улыбыз өйләнеп авылда калды, – диде Мансур абый. – Күп балалы гаиләдән булганга, дәүләт аларга йорт салып бирде. Кече малай да диплом алып авылга кайтты әле. Эшчеләр күп. Мин хәзер контрольдә тотучы гына, дилбегәне балалар кулына тапшырдым.

АВЫЛНЫҢ УҢГАННАРЫ

Авылларга баргач, еш кына уңган хуҗабикәләр белән танышабыз. Кемнеңдер ишек алды тулы чәчәк үсә, икенчеләре бәйли, чигә. Олы Кариледә исә камыр ризыкларына бик оста ханым бар икән. Ул Илсур Кәримуллинның тормыш иптәше – Фирая апа. Без киләсен белеп, кабартма, гөбәдия пешереп куйган. Шуны гына әйтәм: моңа кадәр андый тәмле кабартманы ашаганым булмады!

– Заказлар бик күп, – диде Фирая апа. – Инде кайберләренә: «Эшли алмыйм», – дип тә әйтәм. Вакыт җитми бит. Әле бит кибетебез дә бар, көне буе шунда сату итәм. Камырны исә төнлә пешерәм.

Фирая апа Арча районының Яңа Ашыт авылында туып-үскән. Олы Карилегә килен булып төшкәндә унтугыз яшендә генә була ул. Тормыш иптәше Илсур абый белән дүрт малай үстерәләр.

– Аш-суга яшьтән остамы сез? – дим.

– Юк, наным, без бит шәл бәйләп үстек. Аш-су әзерләү әни өстендә иде. Илсур абыеңа кияүгә чыккач, камыр ризыкларын икәү бергә пешердек. Һич онытасым юк: берсендә рулет әзерләргә булдым. Камырны җәеп, варенье сыладым да, түгәрәкләдем. Хәзер вареньем ага да ага, кәстрүлдән камыр алам да, аккан җирен «ямап» куям. Шулай ялгый-ялгый рулетым табага сыймас булды. Өстәвенә, мичтә утын да янып бетмәгән иде. Мич әзер булганын көтеп, рулетым табадан ташып чыкты. Кыскасы, ашарлык булмады ул.

Фирая апа ризык әзерләргә әнә шулай өйрәнгән. Пешереп карап. Беренчесендә килеп чыкмаса, икенче юлы уңган. Бүген ул ниләр генә әзерләми!

Олы Карилеенең тагын бер тырыш ханымы – Венера Зыятдинова белән таныштык. Тормыш иптәше Илшат абый белән сигез бала үстерәләр. Иң олы балаларына – 25, кечесенә 5 яшь. Бүгенге күзлектән караганда, сигез бала табу, үстерү бер батырлыкка тиң кебек. Тик Венера апа моны бик табигый, шулай булырга тиеш кебек кабул итә:

– Сигез бала табабыз дигән максат юк иде, – дип, тыйнак кына елмайды күп балалы ана. – Һәр бала үз ризыгы белән туа. Аннан мин аларны үзем генә үстермәдем. Кайнанам, кайнатам бик булышты. (Кайнанасы ике ел элек мәрхүм булган инде. – Авт.) Бала карап өйдә утырмадым, эшкә чыктым. Шуңа да ул-кызларым тиз генә үсте кебек.

Венера апа авыл китапханәсе мөдире булып эшли, тормыш иптәше Илшат абый машина йөртә икән. Биш ел элек, күп балалы гаилә буларак, дәүләт программасы нигезендә ике катлы зур йорт төзеп биргәннәр. Бүген шунда гөр килеп яшәп яталар. Хуҗабикәгә 2009 елда «Ана даны» медале дә тапшырганнар.

– Ә дәүләттән тагын берәр ярдәм булдымы? – дим.

– Юк, – диде Венера апа. – Без ярдәм көтеп утырмыйбыз да. Ирем белән пар канатыбыз каерылмасын. Яшь чагында бала үстерүнең тәмен бик аңлап бетермисең икән. Хәзер аеруча бер рәхәтлек белән шушы вазыйфаны үтибез.

...Җылы тәэсирләр белән кайттык Олы Кариледән. Халык аралашучан. Мәчеттән чыккан бер бабай, каршыбызга килеп: «Мине дә фотога төшерегез әле», – дип елмайды. Төшердек. Куанды. Гомумән, кем белән генә аралашсак та, барысы да елмаеп, чын күңелдән сөйләште. Озын гомер телим Олы Карилегә һәм анда яшәүче гади кешеләргә.

– Мине дә фотога төшерегез әле, – дип елмайды мәчеттән чыккан бабай.

– Илсурга кияүгә чыккач, камыр ризыкларын икәү бергә пешердек, – ди Фирая Кәримуллина.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Олы Кариле авылы Казан ханлыгы җимерелгәннән соң оешкан. Әби-бабайлар шулай дип сөйли иде. 1552 нче елларда авылга җиде ир-ат килеп төпләнгән булырга тиеш. Аларның берсе Карале исемле булган. Ир-атлар, ягъни безнең бабаларыбыз, башта моннан бер-ике чакрым читтәрәк урнашканнар. Инде төпләнеп, яши башлагач, янгын чыккан. Бөтен ихаталары янып беткән. Шуннан соң Карале бабай, улын ияртеп, бу урынга килгән. Елга бар икәнен күреп, иптәшләрен дә чакырган. Алар да яңа урынны бик ошаткан. Карале бабай хөрмәтенә авылга Кариле дип исем биргәннәр.

Бу тарихны мин авылыбызның аксакалы Вазыйх абый Гыйльмиевтан язып алдым. Әнием 106 яшенә җитеп дөнья куйды. Ул да шулай сөйли торган иде. Авыл тарихы буенча шактый күп мәгълүмат җыйдым. Тик, ни кызганыч, китап итеп бастырырга алынучы кеше әлегә юк.

Тәнзилә Галимҗанова, Олы Кариле авылында туып, дистә еллар колхозда хисапчы булып эшләгән ханым.

ШАРЛОТКА ҖИҢДЕ!

Самолётлар, Татарстан күген сайлап, һава шоуларын яратучылар сөенеченә аны аркылы-торкылы гизгәндә, Красновидовода алмалар өлгерде. Шуңа күрә «Татарстан» Алма Спасына шул якка юнәлде. Һәм үкенмәде. Программа, көтелгәнчә, иң-иң алмалы булып чыкты: алмаларны һәм истәлекле урыннарны яратучылар данлыклы Юрьев мәгарәләре, иске штольнялар буйлап йөрделәр, маркиз Паулуччиның Наримандагы утарында өрәкләрне куркыттылар, Тенештәге борынгы Идел буе йортларының йомык сыр-бизәкләренә сокландылар... Тагын әле туйганчы фольклор җырларын тыңладылыр, әйләнбәйләнән уйнадылар, француз сырлары белән сыйландылар, «Алмасына тидер!» конкурсында катнаштылар – һәм тидерделәр дә бит!

Алма бәйрәменең кульминациясе алмалардан пешерелгән тәм-томны татып карау иде. «Татарстан»ның шәхси кулинар рейтингында француз Шарлоткасы җиңеп чыкты! Аның белән француз сырларының берсе дә тиңләшә алмый!

Фото: Александр Ефремов

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

Лениногорск. 2017 ел.

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

Лениногорск шәһәре төзелешенең гомуми күренеше. 1953 ел.

Фото предоставлено Национальным музеем РТ